МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№5-6 ⁄ август 2012

30 август – Татарстан Республикасы көне

Ураза гаете

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Журнал «Татмедиа» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов

Иҗат төркеме:
Рамил Ханнанов
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ № М-833.
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 15.08.2012

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№5-6 / август 2012

Эчтәлек

ТАРИХ

6 **Киләчәккә карап.** *Марат Галиев*
13 **Татарстан.** *Ренат Харис*
14 **Тарих сабаклары.** *Разил Вәлиев*
19 **Азатлык.** *Рәшит Әхмәтҗан*
20 **Мөстәкыйльлек юлында: өч сораууга — егерме җавап.** *Илдус Заһидуллин, Ленар Гобәйдуллин*
29 **Аран.** *Газинур Морат*
30 **1812 елгы Ватан сугышында беренче Типтәр полкы.** *Рамил Рәхимов*
43 **Без дә бөек.** *Рифат Сәлах*
44 **Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70 нче елларына кадәрге күчешләре.** *Арзу Кылынч*
63 **Шигырь генә...** *Рөстәм Мингалим*
64 **Галимҗан Баруди һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе.** *Альта Мәхмүтова*
77 **«Мәдрәсәи Мөхәммәдия» программасы. Кушымта**
88 **Милли музей проекты.** *Ленар Гобәйдуллин*
95 **Татар иле.** *Зөлфәт Хәким*
96 **Александров пассажы.** *Хаҗи Абдулла Дубин*
99 **Өмет белән язны көтеп алдык.** *Бикә Рәхимова*

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

102 **Рамазан...** *Әнвәр Хәйри*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторлар, В.Зотов, Д.Бунтуков, А.Эшкинин, Р.Сафиннарның шәхси архивларыннан һәм ТР Үзәк дәүләт архивыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1, 4 нче битләрендә — Татарстан Республикасы көненнән күренешләр. *В.Зотов фотолары;*
2 нче биттә — Татарстан Республикасы Конституциясе көненә багышланган митинг.
В.Мартинков фотосы;
3 нче биттә — Җәлилчеләргә куелган барельеф.
Л.Гобәйдуллин фотосы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

ӘДӘБИЯТ

109 **«Мин — Идел кешесе».** *Тәлгат Галиуллин*
123 **Иртәгә...** *Рөстәм Мингалим*
128 **Хакыйкать.** *Габдулла Буби*
135 **30 нчы август, ягъни сүз урлау.** *Рәниф Шәрипов*
136 **Ике бәет: уртак һәм аермалы яклар.** *Флёра Сәйфуллина*
145 **Идел ярында.** *Ринат Мәннан*
146 **«Дөнья ярып атлап киләмен...»** *Радик Сабиров*
155 **Мирас.** *Нур Әхмәдиев*
156 **Тукай энциклопедиясенә.** *Резеда Ганиева*
159 **Каһарманнарга мирас — мәхәббәт.** *Рәдиф Гаташ*
162 **«Илгә тугрылыклы булып калам!..»** *Шаһинур Мостафин*
165 **Шигырьләр.** *Рәхим Саттар*

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

168 **Дастани мирасыбыз чичәннәр иҗатымы?** *Лилия Мөхәммәтҗанова*
175 **Казаным.** *Фәйрүзә Мөслимова*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

178 **Идел эче — имин йорт.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*

181 **Үпкәләрмен кебек.** *Рөстәм Мингалим*
182 **Яңа китаплар.** *Илдус Заһидуллин*
188 **Тарих сәхифәләреннән.** *Ленар Гобәйдуллин*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНЛЫГЫ ТУРЫНДА ДЕКЛАРАЦИЯ

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югары Советы, республиканың күпмилләтле халкы язмышы өчен тарихи җаваплылыкны аңлап; Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республикалар Союзында яшәүче барлык халыкларның суверен хокукларына ихтирам белдереп; автономияле республика статусының аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, экономик, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтеп үтеп; татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашырып; демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып,

1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны Татарстан Совет Социалистик Республикасы – Татарстан Республикасы итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга, нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, политик инанулары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешегә тигез хокуклар һәм ирек гарантияли. Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.

4. Киләчәктә Конституциядә, башка хокукый норматив актларда, дәүләт тормышында дәүләтнең рәсми исемен «Татарстан Совет Социалистик Республикасы» (Татарстан ССР яки Татарстан Республикасы) дип кулланырга. Республика дәүләт властеның югары органын – «Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы» дип, ә ул кабул итә торган актларны – «Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы актлары» дип исемләргә.

5. Бу Декларация Татарстан ССР Конституциясен эшләү, Татарстан ССР законнарын үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз договорын РСФСР һәм башка республикалар белән договорлар әзерләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен, Татарстан ССР дәүләт төзелешенең аеруча мөһим мәсьәләләрен һәм аның ССР Союзы, РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсәбәтләрен аның халкы тикшерүенә чыгару өчен нигез булып тора.

Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле.

6. Татарстан ССРның яңа Конституциясен, башка законнарны һәм норматив актларны кабул иткәнгә кадәр Татарстан ССР территориясендә Татарстан ССРның, РСФСР һәм ССР Союзының Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килми торган законнары һәм закон актлары гамәлдә булуны дәвам иттерә.

Бу Декларация аны кабул итү вакытыннан көченә керә.

Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы Рәисе
М.ШӘЙМИЕВ

Казан, 1990 ел, 30 август

КНИГИ
КЛИМОВЪ

ТАРИХ

Ә чокырдан тарих чыга,
Җилкәсеннән балчык коела,
Таш коела,
Ватык-сынык
сөяк коела,
һәм ком коела.
Еллар коела,
Елтыр-елтыр
чорлар коела,
алтын коела.

Рөстәм Мингалим

30 АВГУСТ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ

КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

МАРАТ ГАЛИЕВ,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе

БЫЕЛГЫ РЕСПУБЛИКА КӨНЕ БӘЙРӘМЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 20 ЕЛЛЫГЫ, «РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ АРАСЫНДА ЭШЛӘР ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘР БҮЛЕШҮ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ» ТӨЗЕЛҮНЕҢ БИШЬЕЛЛЫГЫ БЕЛӘН ТӘҢГӘЛ КИЛӘ.

2007 елның 26 июнендә Мәскәү каласында имзаланган, хәзерге көнгә кадәр төрле бәхәсләр объекты булган Шартнамәнең шактый кызыклы тарихы бар. Бу Шартнамәнең кирәклеге хакында төрле фикерләр әйтелә: кайберәүләр аны беркемгә дә кирәк түгел һәм бернинди әһәмияте юк дип саный, ә икенче төркем сәясәтчеләр ни өчен бары тик Татарстан гына Федераль үзәк белән шартнамәгә нигезләнгән мөнәсәбәтләрен саклый дип аптырыйлар. Бу Шартнамәне аңлау һәм бәяләү өчен, Россия Федерациясе дәүләтчелеге тергезелү тарихына, ягъни узган гасырның азакларына әйләнеп кайту сорала. СССР барлыкка килү һәм аның таркалу сәбәпләренә тукталмыйча, сүземне Россия Федерациясе Парламенты СССР кысаларында Дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация кабул иткән вакыттан, ягъни 90 нчы елның җаеннән башлыйм.

Россия Федерациясе Дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациянең

4 нче маддәсендә Россиядә яшәүче халыкларның үзләре сайлаган милли дәүләт һәм милли мәдәни формаларында үзбилгеләнү хокукы беркетелде. Шуңа нигезләнеп, 1990 елның 30 августында Татарстан Парламенты Татарстанның республика буларак статусын биргән беренче хокукый докумет — Республика суверенлыгы турындагы Декларацияне кабул итте. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында республикабызның статусын ачыклау белән бәйле мәсьәлә килеп туды. Чөнки, Татарстан Совет Социалистик Республикасы суверенлыгы турындагы Декларациядә дә Федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрне билгеләгән Шартнамә булырга тиеш, дип язылган иде. Шул сәбәпле, СССРның җимерелүенә китергән мәгълүм вакыйгаларга бер атна кала, ягъни 1991 елның август аенда, Мәскәү белән сөйләшүләр башланды. Сөйләшүләрнең беренче этабында ук ике як та республикабыз статусы вәкаләтләрне чикләү һәм бүлешү турындагы Шартнамә белән билгеләнәчәк дип килеште. Сөйләшүләр барышында Россия ягы, бу юнәлештәге бер этап буларак, республиканың статусын билгеләү һәм республика хакимияте кабул иткән суверенлыгы турындагы Декларациягә карашны ачыклау өчен, безнең республикада референдум уздыру кирәклелеге турындагы мәсьәләне күтәрде. Мәгълүм булганча, бу референдум 1992 елның 21 мартында үтте. Анда халык Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында мөнәсәбәтләрне тигез хокук нигезендә үзара бүлешү турындагы фикерне яклады.

Җәмгыятьтә төрле фикерләр булды, әмма референдум «Әйе!» дигән төгәл һәм ышанычлы җавабын бирде. Референдумның уңышына Татарстан Республикасы Парламенты тарафыннан кабул ителгән, бу референдумда Россия Федерациясенең территориаль бөтенлеге мәсьәләсе каралмый, дигән карар уңай йогынты ясады. Шуңа күрә Татарстанны сепаратизмда гаепләү нигезсез. Кызганычка каршы, кайбер сәясәтчеләр тарафыннан андый гаепләүләр бүген дә әйтелә. Чынлыкта сүз республиканың вәкаләтләрен чикләүгә нигезләнгән статусы турында барды, чөнки республикага тәкъдим ителә торган киметелгән хокуклар безне канәгатьләндерми иде. Ягъни Татарстан җитәкчелеге республиканы Россиядән аеру турында сүз алып бармады. Моны да Татарстан Республикасы Парламенты карары раслап тора. Сүз республиканың нәкъ менә вәкаләтләрен чикли, республика вәкаләтләренең вариантларын үз эченә алган яңа статусы турында бара иде.

Зур дәүләттә кискен үзгәрешләр барган вакытта, конституцион киңәшмә җыелышы булды. Киңәшмә барышында Татарстан Федераль дәүләт кысаларында республика дәүләтчелеген ныгытуга юнәлдерелгән берничә тәкъдим белән чыкты. Бу тәкъдимнәр халыкара хокукый актларга, шул исәптән СССР тарафыннан ратификацияләнгән һәм аннары Россия Федерациясе тарафыннан расланган 1966 елгы Дөнья халыкларының хокукы турындагы халыкара Пактка да нигезләнгән иде.

Бу Пактның беренче маддәсендә халык яшәгән җир һәм табигый ресурслар шул территориядә гомер итүче халыкның милке булу турында әйтелә. Бу беренче маддә турында дискуссияләр булды, алар хәзер дә дәвам итә. Күп шәхесләр бу Пакт колониаль система җимерелгән вакытта кабул ителгән һәм хәзерге заман тарихына бернинди дә катнашы юк, дип белдерәләр. Әмма бу Пактның 1 нче маддәсендә язылганнар турыдан-туры федератив дәүләтләргә карый, дигән 50 нче маддәсе бар. Россия таныган әлеге халыкара документка нигезләнеп, Татарстан конституцион киңәшмә кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә җиргә һәм табигый ресурсларга ия булу хо-

кукын беркетү турында тәкъдим белән чыкты. Тәкъдим киләчәктә бу өлкәдәге мөнәсәбәтләрне закон нигезендә көйләүне күздә тотты.

Конституцион киңәшмә эшендә Татарстан актив катнашты, әмма аның тәкъдимнәре, инкарь гына ителеп калмыйча, хәтта өйрәнү өчен дә кабул ителмәделәр. Нәтиҗәдә, Татарстан тәкъдимнәрен бөтенләй исәпкә алмаган конституцион нормалар тәкрарлана башлады. Шул сәбәпле, Татарстан шактый драматик һәм трагик вакыйгаларга бай булган, Россия Парламентында атышулар белән төгәлләнгән 1993 елның октябрь аенда конституцион киңәшмәне ташлап чыгарга мәҗбүр булды. Татарстан 1993 елның декабрендә булган Россия Федерациясе конституциясен илкүләм референдумда кабул итүдә катнашмаска мәҗбүр булды, 1993 елда Беренче Дәүләт Думасы сайлауларында катнашмады һәм, шуларның нәтиҗәсе буларак, Татарстан Россиянең хокукый кырыннан читтә калды.

Шушы шартларда федераль үзәк Татарстанны Россия хокукый мәйданында канунлаштыру өчен, озакка сузмыйча, Шартнамә буенча сөйләшүләрне төгәлләргә риза булды. 1994 елның 15 нче февралендә 2000 еллар башына кадәр гамәлдә булган барыбызга мәгълүм беренче Шартнамә төзелде. Татарстан, икътисади кыенлыкларына карамастан, Россия хокукый кырында Шартнамә нигезендә шактый уңышлы яшәргә сәләтлелеген исбатлады. Бу чорда кара алтынның бер баррелена бәя 9-10 долларга кадәр төште. Әмма Татарстан икътисади һәм сәяси тотрыклылыкны саклап калды һәм 1991-1992 елларда базар реформаларының түбән тәгәрәвеннән соң, 1994 елда барлык Россия Федерациясе субъектлары арасыннан икътисад өлкәсендә уңай күрсәткечләргә иреште. Гомумән алганда, ул елларда Республика үзенең сәясәте һәм эшчәнлеге өчен җавап бирергә сәләтле икәнлеген, тотрыклылыкка һәм икътисади үсешкә гарантия бирә алуын күрсәтте. Болар барысы да Россия Федерациясенең дә, аның субъектлары җитәкчеләренең дә безнең республикага мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртте. Шунысын да яшермичә әйтергә кирәк: бу еллар дәвамында республикага каршы бик җитди пропаганда һәм тискәре мөнәсәбәт тудыру эше алып барылды. Минем уйлавымча, тискәре мөнәсәбәттә күбрәк эмоцияләр өстенлек итте, республикада үткәрелгән сәясәткә, шулай ук Россия Федерациясе җитәкчеләре белән бәйләнешләр өлкәсенә карата хокукый яктан нигезләнгән дәлилле позиция булмады. Ике арадагы мөнәсәбәтләр шактый конструктив һәм тигез булды. Массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан үзгә бер җәмәгатьчелек фикерен формалаштырырга тырышу да һәм хакимият органнары арасында барган процессларга бәйле каршылыклар да булды.

Ул елларда, Татарстанны Россия Федерациясе бюджетына налог түләми дип, моны сепаратизм күренеше буларак бәяләргә омтылдылар. Ә чынбарлыкта республика Шартнамәдә күрсәтелгән килешү нормалары буенча, ягъни бирелгән вәкаләтләр өчен (хокук саклау органнарын, армия һәм башка федераль функцияләрне һәм вәкаләтләрне тәэмин итәр өчен) федераль бюджетка салымны вакытында түләде. Салымның суммасы ел саен төзелгән хакимиятара килешүләрдә билгеләнде.

Шул ук вакытта республика федераль бюджеттан бернинди дә дотация, субсидия алмады, ягъни үз-үзен тәэмин итеп яшәде. Бу күренеш югары бәяләнергә лаек. Республикада, үз финанс мөмкинлекләреннән чыгып, чыгымнар сәясәтен билгеләгән, кеше хисабына яшәмәүгә нигезләнгән менталитет барлыкка килде. Татарстан, Россия Федерациясе кысаларында субъект-донор булып калган хәлдә, үзенең җаваплы сәясәт үткәрә алуын күрсәтте.

Төрле хисаплаулар буенча, Россия Федерациясендә субъект-донорларның саны төрле елларда 18 дән артмаган (соңгы мәгълүматлар буенча аларның саны 11 дән алып 15 кә кадәр). Федераль бюджетка җыелган салымның 50 % тан артыгы субъектлар арасында бүленә. Мондый алым субъект ресурслары һәм аның нәтиҗәле эшләве арасындагы бәйләнешне бетерә. Бу дәүләт төзелешендәге федератив принципларны ныгыту түгел, ә, киресенчә, субъектларның мөстәкыйль үсешкә стимулын юкка чыгару дигән сүз.

Б.Н.Ельцинның китүе белән бәйле рәвештә, «вертикаль хакимиятне формалаштыру» дигән исем астында урнашкан яңа идарә структурасы федератив төзелешкә үзенә күрә бер һөҗүм булды. Федерациядән бигрәк, унитар дәүләткә хас булган күп кенә принципларның яңаруы 2000 еллар башындагы админстратив реформалар белән бәйле иде. Алар бер үк вакытта яңа Шартнамә төзү өчен яңа сөйләшүләр кирәклеген билгеләделәр. Шунысы мөһим: Шартнамә нигезендә мөнәсәбәтләр инде калыплашты, тарихи яктан бу мәсьәләне кире кагу, инкарь итү мөмкин түгел. Алар кануннарда чагылыш тапкан вәкаләтләрне чикләүнең яңа принципларын реаль тормышка ашырды.

Татарстан белән Шартнамә мөнәсәбәтләре Россия Федерациясенең үзенә дә кирәк, Шартнамә булмаса, ниндидер хокукый вакуум барлыкка килер иде. Инде әйтелгәнчә, күпмилләтле Татарстан халкы үз вакытында Россия Федерациясе Конституциясе өчен тавыш бирмәде, аннан алда, 1992 елны, Татарстан федератив килешүгә кул куймады. Татарстанның Россия Федерациясе кысасындагы халәтен билгеләү өчен, ниндидер хокукый документ кирәк иде. Бу документ булып 1994 елгы Шартнамә тора. Әмма бу Шартнамә яңа сәяси цикл вакытында, 2001 елдан соң кабул ителгән законнар белән каршылыкка керде, аның яңа, төзәтелгән варианты кирәк булды.

Инде 2007 елда кул куелган Шартнамәнең әһәмиятен билгеләгән ике моментны ассызыклап үтик.

Беренчедән, ул ике як өчен Россия хокукый кырында Татарстанны тану, киләчәктә дә аның урынын билгеләү өчен кирәк. Моны аңлау берничә елга сузылган сөйләшүләр аша ирешелде.

Икенчедән, бу Шартнамәнең уңышы булып Татарстан статусын республика халыклары тарафыннан референдумда билгеләнүен рәсми тануы исәпләнә. Бу, һичшиксез, әлеге тарихи референдум нәтиҗәләрен ихтирам итү генә түгел, ә хокукый кырда, шул исәптән халыкара хокукый кырда, демократиянең гомуми принциплары кысаларында халыкларның үзбилгеләнү хокукын таныган федераль хакимиятнең авторитетын шактый күтәрде.

Шулай итеп, минем уйлавымча, Шартнамәдә барыннан да бигрәк Россия һәм Татарстан хөкүмәте органнарының хокук нормаларын беренче урынга куюны тануы иде. Шушының белән Республиканың статусына бәйле бәхәсле сорауларга нокта куелды. Бер яктан, монда Татарстанны нинди дә булса сепаратизмда гаепләргә урын калмады, икенче яктан, Шартнамә дәүләтчелекне, төгәлрәк әйтсәк, федератив дәүләт кысаларында шундый рәвештәге дәүләтчелек элементлары булуын таный. Монда бернинди каршылыклар юк, чөнки теләсә кайсы федератив дәүләттә субъектлар теге яки бу дәрәҗәдә дәүләтчелек элементларына ия. Аларның үз бюджетлары, кануннары, вәкаләтләре, ассызыклап әйтәм, федераль һәм республика кануннары, Конституция белән билгеләнгән дәүләт вәкаләтләре бар. 2002 елгы яңа редакциядәге Татарстан Республикасының Конституциясен тану да 2007 елгы Шартнамәнең уңышы булып тора. Ул 199-ФЗ номерлы федераль закон буларак хокукый көчкә ия.

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ АРАСЫНДА ЭШЛӘР ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘР БҮЛЕШҮ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары,

Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә эш итеп;

1992 елның 21 мартында уздырылган Татарстан Республикасы референдумы нигезендә төзелгән «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында» 1994 елның 15 февралендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсен куллану тәҗрибәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә;

Татарстан Республикасының тарихи, мәдәни, икътисадый, экологик һәм башка үзенчәлекләреннән чыгып, түбәндәгеләр турында килештеләр:

1 статья

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Шартнамә белән гамәлгә ашырыла.

2 статья

1. Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы (дәүләт) – Россия Федерациясе субъекты, Россия Федерациясе карамагындагы эшләрдән һәм Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы эшләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең бөтен тулылыгына ия.

2. Татарстан Республикасы территориясендәге җирдән, җир асты байлыкларыннан, су, урман һәм башка табигать байлыкларыннан файдалануның һәм аларны саклауның Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының тормыш һәм эшчәнлек нигезен тәшкил итүен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының икътисадый, экологик (углеводородлар чыгаруның тау-геология шартларын исәпкә алып, нефть ятмаларыннан озак вакытлар файдалану нәтиҗәсендә), мәдәни һәм башка үзенчәлекләренә бәйле мәсьәләләрне уртак хәл итүне күздә тота торган килешүләр төзиләр. Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге пунктта күрсәтелгән проблемалар буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына тиешле закон проектлары кертәләр.

3. Татарстан Республикасы чит дәүләтләрнең субъектлары һәм административ-территориаль берәмлекләре белән үз вәкаләтләре чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра, шул максатлар өчен махсус төзелгән халыкара оешмалар органнары эшчәнлегендә катнаша, шулай ук халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында килешүләр төзи һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы белән килештереп, чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары белән шундый багланышларны гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән килештереп, ватандашларына көнкүреш үзенчәлекләрен саклап калуда, милли мәдәниятне һәм телне үстерүдә дәүләт ярдәме күрсәтә һәм булышлык итә.

5. Татарстан Республикасында рус һәм татар телләре дәүләт телләре булып тора, аларның статусы һәм аларны куллану тәртибе Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль закон һәм Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасының иң югары вазифаи заты вазифасын биләүгә федераль законда каралган тәртиптә кертелүче кандидатуралар өчен Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белүне күздә тота торган өстәмә таләп билгеләнә. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белү игълан итү тәртибендә билгеләнә.

3 статья

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы дәүләт телендә (татар телендә) өстәмә бите булган, Татарстан Республикасы дәүләт гербы сурәте төшерелгән шәхесне таныклаучы төп документ (Россия Федерациясе гражданының гомумграждан паспорты) алырга хокуклы.

4 статья

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Мәскәү шәһәрендә Россия Федерациясе Президенты каршында тиешле вәкиллеге була.

5 статья

1. Әлеге Шартнамәнең гамәлдә булу чоры — ул үз көченә кергән көннән 10 ел.

2. Әлеге Шартнамәнең гамәлдә булуын озайту тәртибе, шулай ук аның гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату (өзү) тәртибе һәм нигезләре федераль закон белән билгеләнә.

6 статья

Мәскәү шәһәрендә 2007 елның 26 июнендә ике нөсхәдә, һәркайсы рус һәм татар телләрендә төзелде, ике текст та бер үк көчкә ия.

Россия Федерациясе Президенты
В.В.ПУТИН

Татарстан Республикасы Президенты
М.Ш.ШӘЙМИЕВ

Шартнамәнең 1 нче маддәсе һәм 2 нче маддәнең 1 нче пункты гамәлдә булган республика Конституциясен тануын, республика Россия Федерациясе карамагында булмаган эшләрдән һәм, Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы эшләр буенча дәүләт хакимиятенең бөтен хокукларына ия булуын таный.

Шунысын да искә төшерү урынлы булыр: Татарстан Республикасы Президенты вазифасы, Россия Федерациясенең башка субъектларыннан аермалы буларак, Россия Федерациясе Президенты вазифасы белән бер үк көндә барлыкка килде. Россия Конституциясендә, республиканың дәүләтчелеген тану нигезендә, бу вазифа, шул исәптән аның исеме, читтән торып беркем тарафыннан да тагыла, үзгәртелә алмый. 1991 елда Татарстан Республикасы Президентының барлык халык тарафыннан сайлануы берүк вакытта бу вазифаны гамәлгә куюда гомумхалык референдумы булды. Әлбәттә, бу мәсьәләдә башка федерация субъектлары карарларын хөрмәт итәргә кирәк. Кайсыдыр субъектта президент вазифасыннан ваз кичкәннәр икән — бу аларның карары. Мин шәхсән үзем, Татарстан Президенты вазифасы бөтенхалык тарафыннан кабул ителгән булуын исәпкә алып, хакимиятнең аны юкка чыгарырга хокукы юк, дип саныйм.

Бу Шартнамә кысаларында республика өчен әле тагын аерым вәкаләтләр каралган. Аның эчтәлегенә җентекләп тукталмыйча, йомгаклау урынына шуны әйтәсе килә: Шартнамә, хокук тантанасы чагылышы буларак, Татарстан Республикасы өчен дә, Россия Федерациясенең үзе өчен дә бик мөһим. Ул билгесезлек һәм ике якның да дәүләт органнары арасында киеренкелек белән бәйле булган тарих сәхифәләрен япты, яңа тотрыклы мөнәсәбәтләр атмосферасын тудырды. Үткән биш ел шуны раслый: Татарстан Республикасы һәм шулай ук Россия Федерациясе дәүләтләре органнары башкарган эшләр — сәясәт, икътисад, социаль мәсьәләләр өлкәсендә булсын — барлык юнәлешләрдә дә конструктив характерда булды. Моны ике арадагы мөнәсәбәтләрнең үсеше генә түгел, ә, беренче чиратта, республикабызның үсеше раслый. Россия Федерациясендә Татарстан — күп кенә субъектлар өчен үсеш планкасын билгеләүче республикаларның берсе.

Ил күләмендә катлаулы проблема булып икътисад өлкәсендә инновацияләр үсеше тора. Без инновацион үсешне икътисадыбыз, гомумән алганда, республикабыз өчен өстенлекле итүнең бөтен юлларын таптык, дип әйтмәс идем. Әмма бу өлкәдә конкрет эшләр һәм аларның, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендәге кебек үк, билгеле нәтиҗәләребез дә бар. Бу дөньякүләм проблема соңгы елларда күп илләрдә, беренче чиратта, Европада кискенләште. Европадагы мультикультурализм сәясәтенең кризисы әлеге концепциянең киләчәге турында хәзергә төгәл фикерне әйтергә мөмкинлек бирми. Әмма, минем шәхси фикеремчә, глобализациягә бару тенденциясендә капма-каршы характердагы агымнар булса да, болар дөньякүләм күренеш булып кала. Татарстан Республикасында күпмилләтле халыкларның толерантлык шартларында бергә яшәүләре, халыкара күзлектән караганда, бик тә отышлы.

2007 елгы Шартнамәнең күп аспектлары бар. Бер сүз белән әйткәндә, ул — төрле цивилизация һәм мәдәни кыйммәтләргә корылган, этник һәм конфессиональ аерымлыклар шартларында үзара хезмәттәшлекне өйрәнү өчен һәм киләчәктә куллану өчен файдалы документ.

А.Эшкинин фотосы

ТАТАРСТАН

РЕНАТ ХАРИС

Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың.
Син — рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның...

Күп иллардән калыштың син,
Күрдең алар узганны...
Әкрен генә күмә барды
Сине тарих тузаны.

Һәм син яңадан калыктың...
Иртә чыктылар ясин...
Әй, Бөек Болгар оныгы,
Тарихлы да, яшь тә син,

Көчле дә син, җитез дә син, —
Атлан акбүз атыңа
Һәм куа чык алга киткән
Ил-дәүләтләр артыннан.

Яшелле, аклы, кызыллы
Әләмең җилфердәсен, —
Әй, Казан ханлыгы улы,
Тарихлы да, яшь тә син!

Олпат та син, горур да син,
Ниятең пакьдин пакьтер —
Син шатлыктан елый белгән
Баһадир кебек матур!

Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың,
Син — рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның!

ТАРИХ САБАКЛАРЫ

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф
һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе,
Татарстанның халык шагыйре

ТАТАР ХАЛКЫ ЯЗМЫШЫНДА ТАРИХКА УЕЛЫП КАЛГАН ВАКЫЙГАЛАР ШАКТЫЙ КҮП. АЛАРНЫҢ КАЙБЕРЛӘРЕ ХАЛКЫБЫЗ ЯЗМЫШЫН УПКЫН КЫРЫЕНА КИТЕРЕП ҖИТКЕРГӘН ОЛЫ ФАҖИГАЛӘРДӘН ГЫЙБАРӘТ БУЛСА, ИКЕНЧЕ БЕРӘҮЛӘРЕ МИЛЛИ АЗАТЛЫК ХӘРӘКӘТЕНӘ КУӘТ ӨСТӘП, ҖИМЕРЕЛГӘН ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕБЕЗНЕ ЯҢАДАН ТОРГЫЗУ ӨМЕТЛӘРЕ УЯТКАН. НӘКЪ МЕНӘ ШУНДЫЙ ХӘЛИТКЕЧ ТАРИХИ ВАКЫЙГА ДИП МИН 1990 ЕЛНЫҢ 30 АВГУСТЫНДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН ДЕКЛАРАЦИЯНЕ АТАР ИДЕМ. ХЫЯЛ, ӨМЕТ ҺӘМ ЫШАНЫЧ РУХЫННАН ЯРАЛГАН ДӘҮЛӘТ МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕГЕ ТУРЫНДАГЫ ДЕКЛАРАЦИЯ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЯҢА ТАРИХЫНА САЛЫНГАН ТӘҮГЕ НИГЕЗ ТАШЫ, ХАЛЫКАРА ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ ДОКУМЕНТ БУЛДЫ.

Декларациядә игълан ителгән таләпләр нигезендә, озакламый Татарстанның беренче мөстәкыйль Конституциясе кабул ителде, «Татарстан халыклары телләре турында»гы гаҗәеп актуаль канун дөньяга килде. Республикабызның икътисади һәм рухи нигезен ныгыткан законнар, программалар кабул итү дә гамәлгә керә башлады, дәүләтчелегебезне тергезү юлында җитди талпынышлар булып алды. Болар һәммәсе дә халкыбызның ныклыгын, көрәшкә әзерлеген сынау баскычлары, тарих сабаклары иде.

Бүгенге көн каланчасыннан торып узган елларга, 90 нчы еллар

ТР Президенты М.Ш.Шәймиев 1992 елда референдумда тавыш бирү вакытында.
М.Козловский фотосы. ТР Президенты аппараты. ТР ҮДА

вәзгыятенә күз салганда, күңелгә төрле уйлар килә. Хәзерге тормышыбыз, республикабызның, дәүләтчелегебезнең хәле һәммәбезнең күз алдында. Шуңа күрә бу хакта тәфсилләп, җәелеп сөйләү кирәк тә түгелдер. Ә моннан ике дистә ел элек без бүгенге көнебезне ничек күзаллаган идек икән? Безнең ул чактагы хыялларыбыз, өметләребез чынга аштымы, киләчәккә ышанычыбыз акландымы?

Ул елларның шаһиты гына түгел, әлеге тарихи вакыйгаларның эчендә кайнаган татар баласы һәм халык депутаты буларак, мин бу хакта бик еш уйланам. Бүген исә уй-фикерләремне журнал укучылар белән дә бүлешү максатыннан, үземнең Татарстан парламенты мөнбәреннән ясаган ике чыгышымнан өзекләр тәкъдим итәргә ниятләдем. Аның беренчесе — 1990 елны Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул иткәндә яңгыраган өмет һәм ышаныч тулы чыгыш булса, икенчесе инде бераз соңрак, Декларацияне гамәлгә ашыру юлларында шактый «борын канатып», ачы тәҗрибә туплагач яңгыраган аптырау һәм рәнҗү хисләре белән сугарылган җан авазы иде.

Ә инде безнең өмет-хыялларыбызның ни дәрәҗәдә тормышка ашу-ашмавы хакында һәммә кеше үзенчә уйланыр, үткәнебезгә һәм бүгенгебезгә — 22 еллык тарихи мирасыбызга үзенчә бәя бирер дип уйлыйм.

ХӨРМӘТЛЕ ДЕПУТАТЛАР! МӨХТӘРӘМ ҖӘМӘГАТЬ!

«Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе киләчәктә инде хәзергечә яши алмаячак», — дисәм, күпләрегез минем белән килешер. Ләкин гасырлар буена кешеләр аңына сеңдерелгән империячел фикерләү үзеннән-үзе генә юкка чыкмый. Нәкъ менә шуннан бездә дә, башка милли республикаларда да Россияне һәм СССРны яңарту һәм деколонизацияләү процессының киләчәктә дә дәвам

итүенә ышаныч юк. Безнең сәяси һәм экономик суверенитетка омтылуыбыз менә шуннан килеп чыга. Бу мәсьәләдә зыялыларның максаты Татарстаннның мөстәкыйльлеген яклап чыгучы сәяси көчләрнең фикеренә туры килә. Һәм бу максатны республикада яшәүче барлык милләт кешеләре дә аңларга тиеш. Ә 150 миллионлы рус халкы белән 7 миллионлы татар халкының көчләр нисбәте республикада «азчылык» саналган рус халкының хокуклары чикләнер дип шикләнергә урын калдырмый. Шушы уңайдан ТАССР Югары Советы Президиумы тарафыннан тәкъдим ителгән Декларация проекты турында берничә сүз әйтәсем килә. Аның хокукый асылын халык әле аңлап та бетермәде, бу исә җәмгыятьнең билгеле бер өлешендә каршылыклы фикерләр тудырды. Декларациянең беренче статьясы — Татарстанны Россия һәм СССР субъекты дип игълан иткән статья безгә дә аңлашылмый. Киләчәктә Югары Советка андый мөһим карарларны әзерләгәндә ашыгучанлык күрсәтмәскә, иң элек аларны юридик яктан исбатларга, нигезләргә кирәк. Татарстанның мөстәкыйльлеген мин аның төзелеше демократик нигездә булганда гына мөмкин дип саныйм. Шул ук вакытта безнең шартларда Татарстанның мөстәкыйльлегеннән башка җәмгыятебезне демократияләштерүгә өметләнү дә беркатлылык булыр иде. Миңа калса, мөстәкыйль дәүләтчелеккә баруның хәзерге этабында, беренче чиратта, Татарстан Республикасының яңа Конституциясен эшләү мәсьәләсен күтәрергә кирәк. Аны бөтенхалык тикшерүе, референдум аша кабул итү дөрес булачак.

Депутатларның күпчелеге үзләренең сайлау алды программаларында Татарстанның союз статусы өчен

ТР Дәүләт Советы рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин (үзәктә). 1992 елда ТР Конституциясен кабул иткән көндә.
М.Козловский фотосы.
ТР Президенты аппараты. ТР ҮДА

көрәшергә ныклы ниятләре барлыгы турында белдерде. Димәк, сайлаучылар, безне яклап тавыш бирүләре белән, республикабызның суверенитеты өчен дә тавыш бирделәр, дигәнне аңлата бу.

Референдум юлы белән кабул ителгән Төп Закон республика халкының ихтыярын башка дәүләтләрнең аны, халыкара хокук традицияләренә таянып, танырга мөмкинлек тудырыр иде. Шуның белән бергә, мөстәкыйльлек алуның дәвамлы процесс булуын да онытырга ярамый. Бирредә, юридик нигез белән беррәттән, экономик һәм социаль шартларны да булдырырга кирәк, чөнки чын дәүләт мөстәкыйльлегенә ирешү өчен, сәяси акт кабул итү генә җитми.

Әйе, халык әлегә безне консерватив Югары Совет дип саный. Ниһаять, яңа сайланган Парламент корпусы бүген халыкка үзенең чын йөзен күрсәтер. Һәм без көчләр нисбәтен белербез,

үзебезнең арада чын демократларның, интернационалистларның һәм шулай ук консерваторларның, торгынлык чоры тарафдарларының күпме икәнлеген аңларбыз. Үз республикасының патриотлары һәм бөек державачылык шовинистлары, империячел фикерләү һәм сталинизм варисларының да күпме булуы ачыкланыр.

Мин бу сессиядә нәрсә өчен тавыш бирәчәкмен соң? Беренчедән — мөстәкыйльлек өчен. Икенчедән, мин исемләп тавыш бирү, аны матбугатта игълан итү ягында. Өченчедән, мин суверенитет һәм базар мөнәсәбәтләре шартларында яшәү өчен, хөкүмәт программасын ашыгыч рәвештә төзүне яклап тавыш бирәчәкмен. Әгәр безнең хөкүмәт мөстәкыйль экономик сәясәт юлларын күрмәсә, отставкага китәргә тиеш.

Кайбер иптәшләр, безнең Татарстанда суверен республика белән идарә итәргә сәләтле кешеләр юк, диләр. Әйе, моңарчы бездә андый лидерлар бик аз иде, чөнки безгә ирек бирелмәде. Республиканың мөстәкыйльлеге булмады, шуңа күрә, лидерларга да ихтыяҗ юк иде. Суверен республикабыз булса, бездә, һичшиксез, менә дигән җитәкчеләр үсеп чыгачак.

Үзен хөрмәт иткән теләсә кайсы халык иреккә һәм тигезлеккә омтылырга тиеш, бу — дөньяда бөтен тереклек иясенең табигый теләге. Ә башка халыкларның законлы хокукларын танырга теләмәү — элементар цивилизациялелекнең булмавы, халыкара хокукны санга сукмау һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетү турында гына сөйли.

27 август, 1990 ел

МӨХТӘРӘМ ХАЛЫК ВӘКИЛЛӘРЕ!

Без, үзебезнең иманыбызны, халкыбызның, республикабызның тоткан юлын ачыклап, 1990 елның 30 августында Дәүләт бәйсезлеге хакында Декларация кабул иттек. Без, кая барганыбызны бик яхшы аңлап, үзебезнең беренче Президентыбызны сайладык, без, нишләргә ярамаганын бик яхшы аңлап, заманында Россия Президентын сайлауда катнашмадык. Татарстан халкының күпчелеге аңлы рәвештә референдумда республикабызның мөстәкыйльлеген, тәрәккыяткә ирешкән башка милләтләр һәм халыклар белән тигез вәкаләтле булуны дәгъва кылып тавыш бирде.

Бу җиңүләрнең берсе дә җиңел генә бирелмәде. Әгәр дә без соңгы елларда, бөкрәйгән билләребезне турайтып, бераз тураеп басканбыз, әгәр дә без үзебезне тигез хокуклы кешеләр итеп хис кыла башлаганбыз икән, монда әче суыкларда, көзге яңгырларда Азатлык мәйданында көн үткәргән әбиләр һәм бабайлардан башлап, бернинди кыенлыкларга да карамыйча, безнең табыннарыбызга нигъмәт иңдерүче игенчеләрнең дә, күпме мәсхәрәле сүзләр ишетеп тә, күңелләре сү-

релмәгән, рухлары сынмаган туры Кыйблалы милләтпәрвәрләрнең һәм депутатларның да, иң авыр һәм катлаулы хәлләрдән дә исән-сау чыккан һәм әле моңа кадәр республика халкын да исән-сау алып чыга алган җитәкчеләребезнең дә өлеше бик зур. Болар инде барысы да тарихка кергән һәм аларны берәү дә оныта да, оныттыра да алмаячак.

Без Татарстанда ике телне — татар һәм урыс телләрен дәүләт теле дип игълан иттек. Безгә җавап итеп булса кирәк, озакламый Россия дә үз дәүләтендә икенче дәүләт теле итеп дөньядагы иң аңлаешлы телне — танклар һәм бомбалар «телен» кабул итте. Һәм тезгеннән ычкына башлаган субъектлар бу «телнең» мәгънәсенә тәрҗемәсез дә бик тиз төшенделәр һәм ашыга-ашыга, берсен-берсе уздыра-уздыра, моңа кадәр кабул иткән мөстәкыйль карарларын һәм законнарын яңадан сүтәргә, моңа кадәр кылырга өлгергән «ялгышларын» төзәтергә тотындылар. И-их, беркатлы сабыйлар! Имештер дә безгә яхшы патша ирек вәгъдә итте, имештер дә без, ниһаять, үз җиребездә үзебез хуҗа булдык! Татарстанны урап алган мари урманнарындагы атакага ташланырга әзер торган Рәсәй танклары турында ишеткәч, безнең күңелләрне тагын шом басты, ә инде Ичкериядәге вәхшилекләрне күргәч, бөтен хыялларыбыз яңадан чәлпәрәмә килде. Кешеләрнең күңеленә яңадан шикшөбһә, икеләнү, өметсезлек, курку кереп оялады.

Милли хәрәкәт, дәүләтчелегебезне торгызу, милли рухыбызны уяту өчен барган көрәш хәрәкәте соңгы елларда сүрелеп, сүлпәнләнеп калган кебек булды. Әмма бу читтән караганда гына шулай. Ә чынында исә мәйданнарда, митингларда кешеләр күңеленә кереп оялаган очкын эчендә җаны булган һәр милләт баласының рухи дөньясына гомер буе сүнмәслек ут салды. Соңгы елларда ирешкән уңышларыбызның иң зурысы, минемчә, халыкның милли аңын уяту, милли рухы, милли горурлыгы йоклаган халыкны кузгатып, аны бер олы максат — дәүләтчелегебезне торгызу максаты белән яшәргә чакыру булды.

Болары инде эшләнгән эшләр, кылган гамәлләребез, болары әле юл башындагы беренче казыклар гына. Ә алда безне нинди эшләр көтә, без кая барабыз соң әле?

Милләтне — республиканы мөстәкыйль итү өчен, милләтнең күпчелеген шушы уй, шушы өмет, шушы хыял белән яшәтү, шушы максат тирәсенә туплау кирәк. Бу максатка ирешү өчен, бүген бездән халкыбызның рухи мирасын барлап, аларны тәртипкә салу, телебезне, динебезне яклау, милли мәгариф системабызны аякка бастыру, мәдәниятебезгә җан өрү, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны яңарту таләп ителә. Әгәр дә безнең балалар бакчасыннан башлап югары уку йортларына кадәр эзлекле мәгариф системабыз булмаса, әгәр дә безнең һәммә дәүләт оешмасында, һәммә кибеттә һәм хастаханәдә, автобуста һәм трамвайда, Президент сараенда һәм Парламент залында татар теле тулы хокуклы хуҗага, чын мәгънәсендәге дәүләт теленә әверелмәсә, әлеге хыялыбыз мәңгегә матур хыял гына булып калачак.

1996 ел

АЗАТЛЫК

РӘШИТ ӘХМӘТҖАН

Ташчы егет! Күтәр башкаеңны,
Авыр ташларыңны куеп тор.
Исән рухыңны кылычлардан
Үткенрәк итеп чыныктыр.

Бар нәрсәгә җаның әзер булсын:
Онытa күрмә, элек ни булды —
Игенчеләр илдә ачтан үлде,
Ә ташчылар йорттан куылды…

Гел бөгелгән килеш яшәмә син,
Башыңны бер күтәр, игенче!
Синең икмәгеңне ашаучылар —
Беләсеңме, синнән ник көчле?..

Яши башлыйк, дисәк — баш кыелды,
Ә яшәсәк — күздән яшь тамды.
Сөякләрдән торган тауны ишеп
Тарихыбыз бүген уянды!

Мәңгелеккә бүген уянды ул,
Уяныгыз сез дә, кешеләр!
Сез йоклаган чакта өстегезгә
Шул тау чаклы кайгы иштеләр.

Каберегез халык каберенә
Әйләнмәсен… Тарих уята!
Кулларыңны кылы итеп күтәр,
Кисәтеп уз — йоклап кем ята.
Илләр безне шулай гына таныр,
Электән үк татар тамгалы:
Һәркем җирдә таный ул тамганы —
Язмышыңда, халкым, кан табы.

Кыйнадылар, илдән куа-тибә,
Тик башыңны имә — Ил исән!
Ил яши ул — әгәр иманыңны
Каның аша аңа иңдерсәң.

Кулларыңны кылыч итеп күтәр,
Баш игәннең көне кыскара.
Үз халкына бүген кем бала да
Ил гомере булып кем кала?
Кем кала?!

Күрә алмас идек бүгенгене —
Җиңалмаган булсак үлемне.
…Офыклардан кояш чыгып килә —
Безнекеләр каны түгелме ул,
Безнекеләр җаны түгелме?!

Фидаилар белән бу дөньяны
Пычрагыннан күпме тазарттык.
Шушы җаннаргамы тиеш түгел
Гамәлдәге бөек азатлык!
Азатлык!
Азатлык!!
Азатлык!!!

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ЮЛЫНДА:
ӨЧ СОРАУГА – ЕГЕРМЕ ҖАВАП

1990 ЕЛНЫҢ 30 АВГУСТЫНДА ТАССР ЮГАРЫ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА ДЕКЛАРАЦИЯ КАБУЛ ИТТЕ. ШУШЫ УҢАЙДАН «ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ГАЛИМНӘРЕНӘ, ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕНӘ ТҮБӘНДӘГЕ ӨЧ СОРАУ БЕЛӘН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕ.

1. Татарстан суверенитеты — сәяси, иҗтимагый, икътисади, мәдәни күренеш — республиканың күпмилләтле халкына, татарлар һәм сезнең үзегез өчен кайсы ягы белән әһәмиятле булды, нинди яңалыклар алып килде?

2. Ике дистә ел — шактый күп вакыт аралыгы, ул кеше гомере өчен дә, ил тормышы өчен дә күпмедер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Суверенитетның җимешләре бүген тормыш-яшәешнең кайсы өлкәләрендә күзәтелә дип саныйсыз?

3. Сезнеңчә, суверенитет мәсьәләсендә Россия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да үстерү-киңәйтү мөмкинлекләре бармы яки бу инде үтелгән этапмы? Узган вакыйгалардан нинди сабак алырга кирәк?

Азат ЗЫЯТДИНОВ,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, техник фәннәр докторы, профессор

1. Татарстан мөстәкыйльлеге турындагы Декларация — ул «үзгәртеп кору» сәясәтенең җимеше. Чөнки СССР барлыкка килгәндә үк күпмиллионлы татар халкы бик чикләнгән хокуклы автономияле кысаларында калдырылды. Бу тарихи гаделсезлек яшәешнең һәр өлкәсендә үзен сиздерә килде. Шуның өчен СССРның һәр яңа Конституциясе кабул ителгәндә Казан тарафыннан ил җитәкчелеге алдында Татарстан-

га союздаш республика статусы бирү мәсьәләсе куелды. Әмма 70 ел буе бу тәкъдимнәр исәпкә алынмады. Ә Яңа союз килешүенә Татарстанның союздаш республикалар белән тигез хокукта кул куярга теләве — ул үз дәрәҗәбезне белү һәм шуны тануны гына таләп итү иде. Кызганыч, аңламадылар. Ә инде Декларацияне бертавыштан кабул итү һәм аны референдум нәтиҗәләре белән ныгытып кую — Татарстанның цивилизацияле юл белән алга баруын күрсәтте. Республикабызга татулык, иҗади хезмәт, алгарыш хас. Киләчәгебез өметле.

Шәхсән үзем өчен бу вакыйгалар бик истәлекле, чөнки мин Түбән Камада милли хәрәкәтне оештыручыларның берсе һәм аның җитәкчесе булдым. Ул — Татарстанда беренче булып рәсми теркәлгән (январь 1989) ТИҮ бүлеге иде һәм бик нәтиҗәле эшләде.

Татарстан Югары Советына депутатлар сайлауда һәм аларның актив эшчәнлеген тәэмин итүдә ТИҮнең роле тәэсирле булды. Милли хәрәкәттә актив эшләгән замандашларыма, депутат фикердәшләремә, республика җитәкчеләренә бик рәхмәтлемен. Без тарихи мөмкинлекне булган кадәр дөрес файдаланырга омтылдык.

Шушы урында фикердәшләремнең, үзләрен авыр хәлгә куеп, «милләтче» исемен алып, республикабыздан гына түгел, чит өлкәләрдән, регионнардан Казаныбызга килеп, милләт таләбен саллы, масштаблы, үтемле итүдә хәлиткеч рольне уйнауларын ассызыклап үтүне кирәк саныйм. «Милләтче» исеме, әйтеп тә торасы юк, авыр исем, тормышта «дивиденд» бирми. Әмма «милләтче»ләрсез, аларның катгый таләпләреннән башка милләт проблемаларын чишеп булмый. «Милләтче»ләрсез халыкның дәүләте була алмый.

2. Иң сөенечлесе — Татарстаныбыз игътисади күтәрелештә: ел саен 30 миллион тонна нефть чыгарабыз, аның 14 млн тоннасын үзебездә эшкәртәбез. Бүген республикабыз нефтехимиясе Россиядә иң алдынгы һәм дөнья базарында лаеклы урын тота. Татарстан мөстәкыйльлеге турындагы Декларация безгә Фәннәр академиясен булдырырга мөмкинлек бирде, һәм ул республикабыз алгарышына хезмәт итә. Татарстанда төзелеш эшләре зур масштабта алып барыла. Якын елларда Республикада гомуми продукция җитештерү күләме ике триллион сумга җитәргә тиеш.

3. Иң борчыганы — туган телебезнең язмышы. Без аны дәүләт теле итә алмадык, хәтта аны белүне мәҗбүри итеп дәүләт органнарында эшләүче чиновникларга да куя алмадык. Нидән куркабыз?

Татар сыйныфлары шәһәр мәктәпләрендә юк дәрәҗәсендә, рус сыйныфларында, әйтүләренә караганда, татар һәм рус телләрен өйрәнүгә сәгатьләр тигез күләмдә бирелә. Нәрсәгә өйрәтәләр — билгесез. Мин яшьләр лагеренда, Болгардагы музейларда, кабул итү комиссияләрендә рус балаларына татарча сорау биреп карыйм. Бер генә дә татарча җавап ишетмим. Җавап: «Не понимаю», сирәк кенә: «Понимаю, но не могу говорить». Ә бит Декларация кабул ителүгә 22 ел була. Кем гаепле? Ни өчен акчаны юкка сарыф итәбез?

Туган авылым Балтач районы Таузар авылына кайткан саен миңа авылдашларым: «Җирне кире кайтарып булмасмы?» — дип сорау бирәләр. Чөнки авылымның ярты болыны, ярты җире колхозларны бүлгәндә башка авылга бирелгән. Авылдашларның ризалыгын алыр өчен җыелыш үткәрелмәгән. Хакими-

ят күз буяу өчен беркетмә тотырган да — вәссәлам… Мин узган елның 29 декабрендә шушы хаталарны күтәреп, чыгыш ясаган идем. Инфарк ала яздым, кызыксынган кеше юк. Кая ул җавап бирү? Мондый очраклар Татарстаныбызны бизәми. Без бит кеше ихтыяҗларына җавап бирердәй гадел, хокукый дәүләт төзү юлына бастык. Россиядән дә без шуны көтәбез, үзебез дә шуңа омтылырга тиеш.

Үзен чын халык итеп тоючы халык телен, гореф-гадәтләрен саклый, үз дәүләтен булдырырга тырыша һәм ул дәүләт, гаделлеккә, гыйлемгә нигезләнгән булып, алгарышка хезмәт итүе белән дөнья халыклары алдында абруй яулаячак.

Виктор ДИЦ,
Татарстан һәм Казан алман иҗтимагый оешмалары җитәкчесе

1. Суверенитет, СССРда үзгәртеп кору процессының дәвамы буларак, татар халкына киләчәктә үсү мөмкинлеге бирде. Республика суверенитеты башка этник төркемнәргә артык әллә ни дә бирмәде. Шул исәптән минем үземә дә.

2. Суверенитет нәтиҗәләре татар халкы тормышының күп кенә якларында чагылыш тапты. СССР таркалганнан соңгы унъеллыкта Татарстан чын мәгънәсендә татар милли республикасына әйләнде.

3. Мин үземне федерализм идеяләре тарафдары дип саныйм. Россия — унитар рәвештә идарә итәр өчен артык зур, артык күпкырлы һәм катлаулы ил. Кешеләрнең акылына ышанырга, аларның үзләренә йөкләнгән бурычларны өстән кушмыйча да яхшы башкара алуларына шикләнмәскә кирәк. Ләкин федерация фәкать аның субъектларының хокуклары тигез булганда, аларның хокуклары киңәйтелгәндә кенә, бигрәк тә икътисади хокуклар арттырылганда гына нәтиҗәле һәм озын гомерле булачак.

Субъектларның сәяси һәм хокукый статуслары тигез булырга, шул исәптән рус регионнарының да хокуклары милли республикалар дәрәҗәсендә булырга (кайбер кеше аз яшәгән «федераль җирләрдән» тыш), барлык субъектларның да җитәкчеләре сайлап куелырга, аларда хакимиятнең өч тармагы, үз уставлары, символикасы һәм башка атрибутлар булырга тиеш.

Россиянең этник һәм мәдәни төрлелеге, күптелле ил булуы яңа Конституциядә чагылыш табарга, Россия каннунары һәм халыкара килешүләр белән сакланырга тиеш.

Федерация субъектларының икътисади һәм финанс хокуклары бюджет керемнәрен һәм салымнарын гадел бүлү хисабына шактый киңәйтелергә, субъектлар карамагында төбәкләрнең 50-60 % табышлары, ә киләчәктә тагын да күбрәк, үзләрендә калырга тиеш. Субъектлар, шулай ук, үзләре эшләп алган акчаларын ирекле тоту хокукына ия булырга тиешләр (җирле үзидарә өлешеннән башка).

Һәрбер федерация субъектының хезмәт куюы һәм андагы тормыш дәрәҗәсе арасында үзара бәйлелекне тәэмин итүче үтә күренмәле һәм аңлаешлы механизм булдырырга

кирәк. Бу ике мәсьәләдә субъектларны тигезләү мөмкин түгел. Кем яхшырак эшли — шул яхшырак яшәргә хокуклы.

Ләкин уңышлы федератив Россия бердәм булып калырга тиеш.

Фәндәс САФИУЛЛИН,
җәмәгать эшлеклесе, 1990-1995 елларда Татарстан Республикасы Югары советы, 1995-1999 елларда Татарстан Республикасы Дәүләт советы, 1999-2003 елларда Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты

1. Суверенитет — ул бәйсезлек дигән сүз, ә бәйсезлек коллык бәйлегеннән арынуны аңлата. Азатлыкның, иреклекнең коллыктан кайсы ягы белән аерылып торуын әйтеп торасы юктыр.

Хәзерге заманда тулаем, һәрьяктан да бәйсез дәүләтләр, халыклар юктыр. Без дә Татарстанда 1990 елның 30 августында республиканың дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул иткәндә андый бәйсезлек максатын куймаган идек. Безнең максат — барлык халыкларның милли хокукларын тигезләп, тигез хокуклы халыклар бердәмлеге итеп үзгәртеп корылган СССР биләмәсендә Татарстанга союздаш република статусын алуга ирешү иде. Ул максатка без СССРны саклап калганда гына ирешә ала идек. Әмма Татарстан үзе генә СССР ны саклап кала алмады. РСФСР (хәзерге РФ), сепаратизм юлына басып, 1990 елның 12 июнендә СССРдан бәйсезлек игълан итеп, аны җимерде. 90 нчы елларда безнең иң зур югалтуларыбыз шуның нәтиҗәсе булды. Югалтып бетермәгәне дә аз түгел. Россиядә яңадан башларын күтәргән кара көчләр татар халкының шактый ныгып өлгергән милли аңына, тарихи хәтеренә, мәктәпләренә, мәдәниятенә, елдан-елга көчәеп, явызларча ябырылсалар да, безнең 90 нчы елларда салып калдырган бәйсезлек нигезен таптап, изеп үтә алмыйлар. Кыска гомерле суверенитетның иң кыйммәтле әһәмияте, аның үстереп өлгергән «җимеше», минемчә, шулдыр.

Суверенлыкны яулаганда көрәшнең алгы сафларында, аның кайнар үзәгендә катнашу бәхете минем язмышымның иң югары ноктасы, гомеремнең иң күтәренке рухлы еллары булып калдылар.

2. Соңгы 20 ел эчендә булган яхшы үзгәрешләрнең барысын да суверенитет җимешләре, дип әйтсәләр, бәхәскә кермәм.

Җанымны әрнеткәне — булган мөмкинлекләрдән файдаланмый калу, һәм шуның аркасында суверенлыкны югалту. Азатлыкны, ирекне беркем беркемгә дә, беркайчан да үз ихтыяры белән бирмәгән һәм бирмәячәк. Тигез хокукны, азатлыкны халык үзе яулап алып, үзе саклый алмаса, алар тиз юкка чыгалар. 80 нче елларның ахрында — 90 нчы елларның башында азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән халкыбызга шул аксиоманы аңлау һәм аңлату җитмәде. Хакимияткә артык ышанып, язмышын аңа тапшырып, халык тынып калды — алданды, оттырды, җиңелде. Моның төп сәбәбе

— халкыбызның сәяси һәм гомуми культурасы, сәяси аңы, милли горурлык тойгысы тиешле дәрәҗәдә булмауда. Әгәр дә бу хәл шулай калса, милли киләчәгебез дә бик аяныч булуы мөмкин. Чөнки, якынлашып килгән глобализация заманында, дөньякүләм масштабта аерым халыкларның, милләтләрнең исән калулары, яисә, киресенчә, «эреп» бетүләре хәлиткеч рәвештә аларның мәдәният, белем, аң дәрәҗәсенә бәйле булачак.

90 нчы еллар безгә мәгариф, мәдәният өлкәләрендә ун ел эчендә йөз елга тиң тарихи юлны үтәрлек мөмкинлекләр ачкан иде. Безгә кичекмәстән үзебезнең тулы милли мәгариф ситемасын, милли университетыбызны, башка югары уку йортларын булдырып өлгерергә кирәк иде. Дөньяның иң абруйлы университетлары катнашында Татар милли университетын оештырып өлгергән булсак, мәктәпләребез, гимназияләребез, лицейларыбыз гөрләп үсеп киткән булсалар, аларны Россия Федерациясенең 309 нчы федераль законы белән бетерү бүгенге кебек ансат булмас иде.

Мәгариф һәм мәдәният министрлыкларына халкыбызның иң көчле галимнәрен, белгечләрен бөтен татар дөньясыннан эзләп, табып, чакырып тупларга кирәк иде.

Иң аянычы — безнең гуманитар сәясәтебез халкыбызның ихтыяҗына капма-каршы юнәлеш алды. Буш сүз булмасын өчен берничә мисал: инде 10 ел эшләп килгән бердәнбер милли югары уку йортын — Гуманитар институтны юк итү, Татар дәүләт милли университетын булдыру турындагы Югары Совет карарын тормышка ашырудан баш тарту, «Татарстан» телерадиокомпаниясен юк итү, татар китабы сәүдәсен юк итеп, Казанда соңгы татар китабы кибетен подвалга күчерү, татар мәктәпләрен, гимназияләрен ташландык балалар бакчаларына урнаштыру, татар халкының музыкаль культурасын күтәрү өчен оештырылган Татар опера һәм балет театрын читтә йөрүче шабашникка әйләндерү... Хурлыклы мисалларның чиге юк. Ахыргы чиктә, милләтебезнең изге урыны булган «Болгар номерларын» җимерүгә һәм җимертүче җинаятьчеләрнең хакимият тарафыннан яклануына-саклануына кадәр түбәнгә тәгәрәдек!

3. «Суверенитет мәсьәләсендәге Русия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләр» бүген Россия тарафыннан «суверенитет» дигән сүзнең Татарстанда, эзен калдырмыйча, безнең белән исәпләшеп тормыйча, тәмам сызып ташлауга юнәлтелгән. Ул мөнәсәбәтләрне тагын да «үстерү-киңәйтү мөмкинлекләре» бар ул барын. Ләкин, Алла сакласын! Россиянең безгә карата бүгенге мөнәсәбәтен тагын да үстерү-киңәйтү безне республика буларак та, татар милләте буларак та бетерүгә җиткерергә мөмкин. Бер генә мисал. Татарстанның 400 млрд сумлык еллык кеременең 90 процентын Федераль үзәк үзенә ала икән, андый мөнәсәбәтне тагын ничек «киңәйтеп, тирәнәйтеп» булуы мөмкин?

Россия белән Татарстан арасында кешелекле гадел мөнәсәбәтләр тудыру, шуның кирәклеген аңлау, минемчә, бөтен илебезне айнытырлык тетрәнү кичермичә була алмас.

Узган вакыйгалардан нинди сабак?

Үзенең язмышын, үзенең киләчәге өчен җаваплылыкны халык үз кулына алырга тиеш!

Нонна ОРЕШИНА,
язучы, Г.Р.Державин исемендәге премия лауреаты

1. Мин Мәскәүдә тудым, әмма җиде яшемнән бирле Казанда яшим. Шуңа күрә дә Татарстанны үземнең туган йортым дип саныйм. Безнең республикабыз миңа һәрвакытта да уңай, мөстәкыйль һәм үз-үзен тәэмин итә ала торган булып күренде. Нинди милләттән булуыңа да карамастан, кешеләрнең бер-берсенә хөрмәте, дуслык-татулык мөнәсәбәтләре булу һәрвакыт куандырды.

Язучы буларак, мин үземне һәрвакыт ирекле һәм ышанычлы хис иттем. Әмма 90 нчы еллар башында алынган Татарстанның суверенлыгы, бәхәссез, мәдәни, иҗтимагый һәм көнкүреш тормышның күп өлкәләрендә үзен сиздерә.

Суверенитет күп кенә шәһәр һәм авылларда яшәүчеләр өчен яңа фикерләргә, планнарга этәргеч бирә алды. Республикабызга дуслык һәм чын рухи тормыш атмосферасы хас. Болардан башка, тарихның кайсы гына дәверендә булмасын, бер илдә дә төрле милләт вәкилләре матур итеп бергә яши алмаслар иде.

2. Минем фикеремчә, барыннан да бигрәк, республика хакимиятенең мөстәкыйльлеге, җаваплылыгы шәһәр төзелешендә, мәгариф һәм мәдәният үсешендә күренә. Соңгы елларда гына Казан һәм Татарстанның башка шәһәрләре тамырдан үзгәрде. Төзелешнең эре объектларын санап тормыйм, аларны санап бетерерлек түгел. Яңа мәчетләрнең төзелүе һәм республика күләмендә иске чиркәүләрне төзекләндерү дә әһәмияткә ия. Әмма борынгы тарихи биналарны югалту кебек моңсу мизгелләр дә бар.

Шулай ук татар телендә укытыла торган гимназияләрнең ачылуы игътибарга лаек; әдәбият укытучыларының укучылар белән очрашуларга рус язучыларын да чакыруы, аларның иҗаты турында сөйләшүләр күңелгә аеруча рәхәтлек бирә. Ә рус мәктәпләрендә татар классиклары әсәрләрен һәм безнең республикабызның барлыкка килү, үсеш тарихын өйрәтәләр.

Соңгы елларда шигърият бәйрәмнәре, һәм татар, һәм рус әдәбияты классикларының туган көннәре еш һәм зурлап үткәрелә башлады. Республикабызның мәдәни тормышы яңа формалар алды. Әдәби премияләрнең саны күбәйде, хәтта кайберләре Россиякүләм даирәгә чыкты. Мисалга, Г.Р.Державин исемендәге әдәби премияне китергә була.

Казанда үткәрелә торган фәнни конференцияләрне оештыручыларның инициативасы һәм җаваплылыгы куандыра. Алар халыкара статус алалар. Әлеге һәм башка мәдәни чараларны Мәдәният министрлыгы әйдәп бара һәм хуплый. Бу барыбызга да мәгълүм.

3. Ике дистә ел эчендә Татарстан һәм Россиядә генә түгел, ә бөтен дөньяда күп әйберләрнең үзгәртеп корылуын онытырга ярамый. Элемтәләр гадиләште, инсаннар арасында мөнәсәбәтләр үзгәрде. Нәрсәдер яхшыга үзгәрде, ә кайберләре катлауланды.

Ничек кенә булмасын, халыкара дәрәҗәгә чыгарга омтылырга кирәк. Безнең язучыларыбызга — шагыйрьләргә, прозаикларга, әдәбият белгечләренә чит илләрдә оештырылган әдәби чараларда катнашырга, үз иҗат җимешләре белән чит ил укучыларын сөендерергә, иң дәрәҗәле фестивальләрдә һәм башка мәдәни, иҗади чараларда чыгыш ясарга вакыт. Бу — Республикабыз суверенлыгының өлешчә, әмма шактый әһәмиятле чагылышы.

Ренат ВӘЛИУЛЛИН,
«Бөтендөнья татар конгрессы» Башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары, филология фәннәре кандидаты

1. 1990 елның 30 августында кабул ителгән Татарстан Республикасының суверенлыгы турындагы Декларация татар халкы тарихында зур бер вакыйга булды. Шул вакытта татарлар үзләренең онытыла башлаган милли горурлык хисләрен яңадан искә төшерделәр. 90 нчы елларда милли китап, мәгариф һәм мәдәниятне саклап калу, иң мөһиме мирасыбызны халыкка кайтару буенча зур омтылышлар булды. Шуларның нәтиҗәсе буларак татар гимназияләре ачылды, яңа газета-журналлар, мәдәният үзәкләре төзелде, югары уку йортларында татар телендә белем бирелә башлады. Бу дәвердә Татарстанда төрле-төрле фикерләр булуга карамастан, милләтара, динара мөнәсәбәтләр бары тик ныгый гына барды. Икетеллелек барлыкка килде. Шулай ук «Татарстан моделе» дигән термин гомумроссия җирлегендә уңай образ буларак формалашты. Конституциябездә тарихи ватаннарыннан читтә яшәгән милләттәшләребезгә ярдәм итү турында махсус маддә билгеләнде. Быел бөтендөнья буенча 400гә якын милли оешманы берләштергән, телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне торгызу өлкәсендә зур эш алып бара торган «Бөтендөнья татар конгрессы» оешуына 20 ел тула.

2. Ике дистә ел эчендә Татарстан Россиядә һәм дөньяда үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәтте. Бүген безнең республиканың үсеш темпы, социаль һәм икътисади яшәеше күпләр өчен үрнәк булып тора. Авыл хуҗалыгы, төзелеш индустриясенең эшчәнлеге ил күләмендә иң яхшылардан санала. Татарстан, киләчәккә карап, алга омтылу белән бергә, тарихи үткәнне барлау һәм саклау юнәлешендә дә зур эшләр алып бара. Шуның иң әһәмиятлесе дип Болгар шәһәрчеген һәм Зөя утравында тарихи биналарны саклау программасын атап була.

3. Россия һәм Татарстан арасындагы сәяси мөнәсәбәтләр төрле дәвердә төрлечә булды. Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителү, Россия һәм Тататарстан арасында вәкаләтләрне бүлешү турында Шартнамә төзелү, һичшиксез, яңа чор тарихының уңай күренешләре, чын мәгънәсендә илне таркалудан саклап калган механизмнар булды. Узган дәвердә шактый катлаулы вакыйгалар да булды, әмма республика федерализм үсешенә үзенең лаеклы өлешен кертә алды. Бүген Федераль үзәк белән ирешелгән мөнәсәбәтләр — шуның ачык мисалы.

Вадим ХОМЕНКО,
Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, икътисад фәннәре докторы, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли фәнни-тикшеренү университеты (КАИ) профессоры

1-2. Хокук һәм вәкаләтләрнең киңәюе хуҗалык итүче субъектларның, дәүләт органнары һәм муниципаль идарәләр инициативалары үсеше өчен зур стимул булды. Бу Россиянең зур территориясен, аерым регионнарда икътисад һәм социаль сфераларның оешу үзенчәлекләрен исәпкә алганда бик мөһим. Шуңа күрә 90 нчы еллар урталарында башланган федератив мөнәсәбәтләр үсеше объектив сәбәпләргә нигезләнгән иде. Ул үзгәрешләр регионнарның икътисади, сәяси, мәгариф һәм фән өлкәләрендәге инициативалары белән үрелеп барды. Моны инкарь итү кыен. Республиканы газификацияләү программасы, нефть ятмаларын тулысы белән үзләштерү өлкәсендә булган салым ташламалары, Россиянең күп регионнарында ташландык хәлгә килгән эре эшкәртү сәнәгать оешмаларына һәм авыл хуҗалыгына ярдәм итү — болар барысы да Татарстанның федератив мөнәсәбәтләр тергезүенең беренче этабы үсеше билгеләре. Шәхсән минем өчен, Татарстан Фәннәр академиясен оештыру нигезендә республика гуманитар фәннәр үсешенә этәргеч бирү омтылышы һәм республикада югары белем бирүче мәгариф үзәкләренең формалашуын тәэмин итәргә омтылышы мөһим... Әгәр дә мондый омтылышлар башка төбәкләрдә булган булса, хәзер Россия бөтенләй башкача күренер иде. Татарстан өчен чимал керемнәре мәсьәләсе мөһим иде. Бу очракта бөтен Россия икътисады нигезенең шуңа корылганын әйтеп китү кирәк. Кызганычка каршы, әлеге финанс керемнәренең аерым төбәкләрнең үсеш дәрәҗәләре белән бәйләнеше начар. Керемнәрне алар алынган төбәкләрдән «аеру» факты, аларны башка региональ берләшмәләр белән контрольгә алынмый торган үзәкләргә, шул исәптән ил башкаласында тупланууы үзен нык сиздерә.

Без республикада Россиянең башка төбәкләренә дә хас булган тискәре күренешләр дә булуын инкарь итмибез. Федераль үзәк белән мөнәсәбәттә һәрбер очракта да иң уңай «плюс» һәм «минуслар» табу мөһим. Киләчәктә Россия регионнарны берләштерә, илдәге һәм халыкара кооперациянең үзәк функциясен башкара торган территориаль үзәкләр булдыруын, аларның икътисади үсешен оештыруны стимуллаштыруга дучар ителгән дип уйлыйм. Бу шартларда тарихи һәм милли хәтер чынбарлыкны позитив кабул итүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Бу җәмгыятьнең консолидацисе өчен көчле стимул булып тора. Моңа мисаллар бик күп. Халыклар бер-берсен дини, милли һәм башка яктан күрә алмаулары — ул үсеш нәтиҗәсе түгел, ә икътисадның дөрес сайланмаган үсеш моделе нәтиҗәсендә түбән тәгәрәве яки элеккеге икътисад моделенең потенциалы бетүе. Бу очракта «дошманнар һәм гаеплеләр»не эзләү котылгысыз, кызганычка каршы ул еш кына милли һәм дини нигезгә күчә башлый....

3. Югарыда әйтелгәннәрдән бу сорауга да җавап килеп чыга. Россия федератив мөнәсәбәтләрнең үсешенә мохтаҗ һәм аңа дучар. Әмма моңа төшенү озак «өлгерә», ул сәяси һәм икътисади төзелеш, шул исәптән бюджетара мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән. Безгә эффектлы дәүләт сәясәте тарафыннан стимуллаштырыла торган, шулай ук федератив мөнәсәбәтләргә көчле стимул бирүче ил төбәкләренең икътисади үсеш стратегиясе кирәк. Фән һәм дәүләт эшлеклесенең бурычы — шушы иң уңай булган үсеш юлын табу, аны вакытында камилләштерә бару. Башка илләрдән аермалы буларак, Россиянең үсеш юлы башкача күренүе табигый хәл дип уйлыйм. Чөнки нык үскән илләр берләшмәсендә күптөрле модельләр яши. Алар турында фикерләшү аерым сөйләшүне сорый.

Газинур МОРАТ,
шагыйрь, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррир урынбасары, Республиканың М.Җәлил исемендәге премия лауреаты

1. Суверенитет безнең колакка ятрак сүз булып ишетелсә дә, ул — эти-әни, Ватан, ил кебек үк изге төшенчә. Аның тирәсендә сүз уйнату гөнаһ. 1990 елларда «суверенитетлар444 парады» дигән булып, метрополия бу кәлимәнең асыл мәгънәсен бик нык очсызландырырга тырышса да, Татарстан, дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация игълан итеп, бөтенхалык референдумы үткәреп, хәтта империя шартларында да камил дәрәҗәдә аңлашып яшәп булуын күрсәтте. Суверенитет, беренче чиратта, гасырлар дәвамында изелгән, мыскылланган, кимсетелгән, хәкарәтләнгән халкыбызның билен турайтты, милли үзаңын хәрәкәткә китерде, хак тарихына борылып карарга мөмкинлек бирде.

2. 90 нчы елларда, бигрәк тә Шартнамә имзалангач, Русия белән Татарстан «50 гә 50» принцибы буенча яшәде, дип беләбез. Шушы чорда җөмһүриятебез авыллары тулысынча диярлек газлаштырылды, меңәрләгән чакрым юллар рәткә китерелде, миллиардлаган тонна нефть озатып та, хәрабә хәлендә кала килгән республикабыз башкаласы Казан да, ниһаять, пайтәхет рәвешенә керә башлады. Ә хәзерге «85 кә 15» принцибы илгә беркайчан да бәрәкәт китермәстер. Империяләр тарихы шуны күрсәтә.

3. Мәскәү Конституциябездән «суверенитет» төшенчәсен алып ташлауны бертуктаусыз таләп итеп торган бер вакытта «мөнәсәбәтләрне тагын да үстерү-киңәйтү мөмкинлекләре» турында сүз алып бару шиктый кыен, әлбәттә. Метрополиянең сәясәте асылда донор төбәкләрне талауга корылган. Ә инде Татарстанның үзәк белән мөнәсәбәтләрен Шартнамә нигезендә корган бердәнбер җөмһүрият икәнен истә тотканда, үз мәнфәгатьләребезне кыюрак якларга да була торгандыр. Бусы инде, беренче чиратта, җитәкчеләребезнең ихтыярыннан тора.

Илдус Заһидуллин һәм Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

АРАН

ГАЗИНУР МОРАТ

Бәйсезлегең бәйдә бәргәләнә,
Бәйсезлегең бәйле әлегә.
Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем,
Бәйсезлегең тоткын хәлендә.

Бәйгеләрдә бәйге тоткан Атың
Тышауланган килеш аранда
Сугымчыны көтә...
Араннарда
Атлар бетеп барган заманда

Сугымчылар арта: суга алар,
Күсәк белән суга Атыңа.
Атсыз йорттан мал-бәрәкәт китә,
Дәүләт китә... Арба ватыла.

Атсыз да һәм Ватансыз калгач,
Үзең җигеләсең арбага...
Бүген әнә тышауланган Атың
Сугымчыны көтә аранда.

Күзендә — яшь, юатырга теләп,
Җиләс җилләр ялмый ялларын.
— Коткар, Хуҗам, — диеп,
Атың бүген
Шәкүр картка гүя ялвара.

— Коткар, Хуҗам, — диеп,
Атың бүген
Аран аратасын кимерә.
Йортың, җирең, телең таланганда,
Ат карагы булсын илеңдә.

Ат карагы булсын — йолып алсын
Арандагы тоткын Атыңны...
Бу җиһанда Аты-малы качкан
Күп араннар инде ватылды.

Кемнәр анда Атлар аранын да
Хөр биләмә диеп атады?
Юк, араннар бәйсез була алмый,
Бәйдә яшәгәндә Атлары.

Ат карагы булсын — йолып алсын
Арандагы тоткын Атыңны...
Бу җиһанда Аты-малы качкан
Күп араннар инде ватылды.

Кемнәр анда Атлар аранын да
Хөр биләмә диеп атады?
Юк, араннар бәйсез була алмый,
Бәйдә яшәгәндә Атлары.

Атны бүген урлап чыгу кирәк,
Урлап чыгу — башка чара юк.
Артта — Ил-йорт.
Алда — империфронт —
Чигенергә инде чама юк.

XVIII ГАСЫР АХЫРЫНДА БАШКОРТСТАНДА ТИПТӘРЛӘРНЕҢ 1 НЧЕ, 2 НЧЕ АТЛЫ ПОЛКЫ ТИПТӘРЛӘР ҺӘМ БОБЕЛЬЛӘР КАТЛАМЫ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ОЕША ҺӘМ ШУЛ КАТЛАМ ХИСАБЫНДА ТОРА. ТӨП БУРЫЧЛАРЫ ОРЕНБУРГ ЧИК БУЕ ЛИНИЯСЕНДӘ ХЕЗМӘТ ИТҮДӘН ГЫЙБАРӘТ. ТИПТӘРЛӘР ҮЗ ВАКЫТЫНДА ДАИМИ ҖИҢЕЛ КАВАЛЕРИЯ (АТЛЫ ГАСКӘР), СӨҢГЕ, КЫЛЫЧ, АРМИЯ ҮРНӘГЕНДӘГЕ КАРАБИН БЕЛӘН КОРАЛЛАНДЫРЫЛА, БЕРДӘМ ХӘРБИ ФОРМАГА КИЕНДЕРЕЛӘ, ОФИЦЕРЛАРНЫҢ ХӘРБИ ЧИННАРЫ РАНГЛАР ТАБЕЛЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ. МИЛЛИ ЯКТАН КАРАГАНДА, ТИПТӘРЛӘР КАТЛАМЫН ТАТАРЛАР, БАШКОРТЛАР, ЧУВАШЛАР, МАРИЛАР, МОРДВАЛАР ТӘШКИЛ ИТКӘН. ПОЛК ШТАТЫНДА ДИН ӘҺЕЛЕ – МУЛЛА БУЛУ КАРАЛГАН. ПОЛКЛАР БЕЛӘН ДАИМИ АРМИЯ ОФИЦЕРЛАРЫ ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТКӘН.

1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА ҖИҢҮГӘ 200 ЕЛ

1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА БЕРЕНЧЕ ТИПТӘР ПОЛКЫ

РАМИЛ РӘХИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Башкорт дәүләт университеты доценты

1807 елда подполковник Никифоров җитәкчелегендәге беренче Типтәр полкы армиягә озатыла. 1810 елда полк, Балтыйк диңгезе ярларында инглиз десантының һөҗүмен кисәтү максатыннан, патруль хезмәтен башкара. 1810-1811 еллар кышында полк Аренсбургта тора. 1811 елда Россия армиясе командованиесе типтәрләрне Оренбург чик буе линиясенә кире кайтарырга карар кыла. Полк Җаекка кузгалырга күрсәтмә ала. Ләкин 4 февральдә хәрби министр М.Б.Барклай де Толли күрсәтмәсе белән, Бөек Луки шәһәре янындагы Васковой авылына урнаша [1]. Әлеге вакытта ул генерал-лейтенант К.Ф.Багговут корпусына керә. Полк март аенда Вильнода була. Подполковник Никифоров үлеменнән соң, 23 марттан полкны 39 нчы Егер полкы майоры Николай Александрович Темиров (Тимиров) Беренче [2] җитәкли. Бу вакытта ул Буг 1 нче, Симферополь һәм Перекоп атлы кырым-татар һәм 4 нче Дон Иловай полклары белән бергә Мереч урынында була [3]. Шул ук елның язында полк Барклай де Толли җитәкчелегендәге 1 нче Көнбатыш армия составына кертелә. Типтәр полкы генерал-майор В.В.Орлов-Денисов командованиесе лейб-гвардия казак полкы белән бергә Неман елгасы буенда урнашкан Понемуни авылыннан Олитага кадәр күзәтчелек итә. Март ахырыннан башлап һәр ике полк генерал-лейтенант Н.А.Тучков I нең 3 нче җәяүле корпусы составында санала.

Лейб-казаклар белән типтәрләр 1812 елның 11 июнь төнендә Россия чиген үтеп, Неман елгасын кичеп чыккан француз сапёрлары һәм пехотасына беренче булып каршы төшәләр. Румжишки авылы янындагы беренче кыска вакытлы атышудан соң, дозор Россия территориясенә чигенә. 1812 елгы Ватан сугышы әнә шулай башланып китә. Француз гаскәрләренең хәрәкәт башлавын хәбәр итеп, Орлов-Денисовка биргән рапортында Темиров болай дип яза: «Мин хәзерге вакытта есаул Юсуповтан рапорт алдым... Ярты көн буе Балберишки аша Ковно елгасына таба берничә көчле отряд узды. Шулай ук йөзлек Юмашев та Матишанцы аша биш атлы полк һәм Прены кордонына таба пехота үткәне турында рапорт бирә. Әлеге хәлләрне яхшырак белер өчен, мин шунда баргач, тиз арада сез галиҗәнапларга җиткезермен» [4].

Кенәз И.Л.Шаховский арьергарды составында типтәр полкы рус армиясенең Вильно янындагы чигенүен тәэмин итте. 15 июньдә кенәз Тучковка үз гаскәрләренең урнашуы турында түбәндәгене хәбәр итә: «Мин авангард белән Трок шәһәреннән көндезге сәгать дүрттә Муравново Вакуына чыгып китәм, граф Орлов-Денисов командалыгындагы кавалерияне калдырам. Аның составында Типтәр полкының өч йөзлеге, бер лейб-казак эскадроны һәм бер лейб-Кара диңгез казаклары йөзлеге; бирегә кичке сәгать җидегә барып җитәчәкмен» [5].

1. Отечественная война 1812 г. Материалы Военно-учёного архива. — СПб., Т.II. — С.45.

2. Залесский К.А.Наполеоновские войны. 1799-1815 гг.: Биографический-энциклопедический словарь. — М., 2003. — С.746. Майор үз фамилиясен Тимиров дип язган, без аның тарихи әдәбиятка кергән Темиров фамилиясен калдырдык.

3. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1908. — Т.IX. — С.152.

4. Шунда ук.

5. Усманов А.Н. Башкирский народ в Отечественной войне 1812 года. — Уфа, 1964. — С.26.

1 нче Типтәр атлы казак полкы мулласы походта. 1812 ел
С.С.Петров. Кәгазь, каләм. 2008 ел

1 нче Типтәр атлы казак полкы казагы чит ил походында. 1813 ел
С.С.Петров. Кәгазь, каләм. 2008 ел

Әлеге рапорттан күренгәнчә, типтәрләрнең өч йөзлеге — ул 1 нче, 2 нче, 3 нче йөзлекләр булып, алар, кордоннарда тормыйча, ә бәлки, икенче катлам резервын тәшкил иткәннәрдер. 20 нче Егер, лейб-гвардия Улан, 1 нче Типтәр полклары һәм атлы артиллерия ротасыннан торган арьергард 16 июньдә Вильнодагы күперне, арсеналны һәм складларны, («запас кибетләрен») яндыра [6]. Барклай де Толлиның Александр I гә җиткерелгән хәбәрендә лейб-казаклар һәм типтәрләрнең беренче югалтулары: икесенең үтерелүе, казаклардан — алты, типтәрләрдән икесенең яралануы турында яза [7]. 16 июнь иртәсендә лейб-казаклар белән бергә Типтәр полкы французларның авангарды — 7 нче һәм 8 нче гусар полклары белән атыша; 18 июньдә лейб-гвардия Улан полкы белән бергә, Довигоны янында сугышта катнашып, дошман кавалериясенең «берничә көчле һөҗүмен» кире кайтара [8]. 21 июньдә лейб-гвардия Кара диңгез казак йөзлеге хорунжие Н.С.Завадовский 25 казак һәм 50 типтәр белән бергә Свенцян янындагы Авапостка җибәрелә. Аларга французларның ике кавалерия полкы каршы чыга, флангларындагы (атлы сугышчы) гаскәриләре белән Завадовский отряды ике сәгатьтән артык каршы «сугыша». 23 июньдә Кочергишки авылы янында «дошманның атлы гаскәре рус армиясе арьергардына һөҗүм итә». Өч сәгатьлек бәрелештән соң, дошман чигенүенә типтәр полкы үз өлешен кертә. Әлеге сугышта катнашучыларны Александр I үзе акчалата бүләкли [9].

29 июньдә командование генерал-майор Ф.К.Корфка

6. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1910. — Т.XIV. — С.202, 212; СПб., 1911. — Т.XV. — С.3.

7. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1910. — Т.XIII. — С.173.

8. Поликарпов Н.П. Боевой календарь-ежедневник Отечественной войны 1812 года. Ч.I. Перечень боевых столкновений русских армий с 4 июня по 31 августа 1812 года / Труды Московского отдела императорского Русского военно-исторического общества. — М., 1913. — Т.IV. Материалы по Отечественной войне. — С.64, 69.

9. Шунда ук. — Б.81-83.

«дошманның кайда икәнлеген белер өчен, кичекмәстән барлык юлларга ышанычлы һәм җитез армия офицерлары белән мөмкин кадәр көчле разъезд [патруль гаскәре] җибәрергә һәм берничә әсир төшерергә», дип боера [10]. Гаскәр составында 1 нче Буг һәм Родионов I [полкы] җитәкчелегендәге Дон казак полклары белән берлектә 1 нче Типтәр полкы да җибәрелә. 19 нчы Егер полкына кергән һәм шушы полк белән арьергардны тәшкил иткән типтәрләр һәм Кара диңгез казаклар йөзлегендә күпме кеше булганлыгы 7 июльдә полковник Н.В.Вуичның рапортында күрсәтә. Анда штаб-офицер, 3 обер-офицер, 5 старшина, 248 казак була [11]. Рапорттан күренгәнчә, полкта элеккечә өч йөзлек булган. Калган икесе төп көчләр белән бергә 1 нче Көнбатыш армия составына кергән. Дошман гаскәрләре ягына әсир төшкән типтәр йөзлекләрен коткару төп хәрби көчләрдән шактый еракта булганга, күрәсең, барып чыкмый. Шуңа күрә Хәрби министр 1 нче Көнбатыш армия штабы начальнигы генерал-майор А.П.Ермиловка махсус күрсәтмә бирә: «Типтәр һәм Родионов казак полкларына армия белән кичекмәстән кушылырга боерык бирегез, әгәр дә алар, атлары арып, армиягә кушыла алмасалар, Улага барырга кушыгыз» [12].

10 июльдә генерал-майор Е.И.Оленин отряды оештырыла. Ул пехотаның резерв батальоннары, атлы полкларның резерв эскадроннары, артиллерия, Дон казаклары, 1 нче Типтәр полкының бер өлешеннән тора. Бу отряд генерал-адъютант барон Ф.Ф.Винцингероденың Смоленск резерв корпусы авангардын тәшкил итә [13]. 14 июльдә отряд Красный шәһәрен ала, шул ук көнне әлеге отрядның бер өлеше һәм генерал-майор Г.В.Розенның отрядына кергән 1 нче, 2 нче, 6 нчы Егер, 1 нче Типтәр һәм Власов җитәкчелегендәге 3 нче Дон казак полклары, Барклай де Толли боерыгы буенча, Катынь авылы янында Днепр елгасын кичеп, уң як ярга чыгарга һәм, элемтәне җайга салыр өчен, генерал М.И.Платов гаскәренең сул флангына кушылырга тиеш була. 16 июльдә 1 нче Егер, Власов җитәкчелегендәге Дон казаклары һәм Типтәр полкларына генерал Платов янына барырга кушыла. 17 июльдә Платовның корпусы 1 нче армиягә кушыла. Днепр елгасы буендагы хәрби хәрәкәтләр нәтиҗәләре буенча Барклай де Толлига җибәрелгән командир Оленин рапортында болай дип билгеләп үтелә: «Майор Темировның 1 нче Типтәр полкы, Днепрны кичеп, Староколени [Сырокоренье] авылы янында француз гусарын әсирлеккә алды, генерал Вотрен [Готрен] җитәкчелегендәге атлы бригадасының 4 француз сугышчысын үтерде» [14]. Оленин шәхси доклад өчен Темировны Барклай де Толли янына юллый: «Рапортта язылган әсирләрне мин Сез чакырткан майор Темировка тапшырдым... майор Темиров әфәнде дошманның көче һәм нияте турында Сез галиҗәнапләргә шәхсән үзе җиткерер» [15].

10. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XVII. — С.127.

11. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XIII. — С.62-63.

12. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XIV. — С.79. Приказание от 9 июля 1812 г.

13. Подмазо А.А. Большая Европейская война 1812-1815 годов: Хроника событий. — М., 2003. — С.36. В.А.Бессонов һәм А.И.Попов фикеренчә, ул ошбу отрядта 22-26 июльдә булган (Бессонов В.А., Попов А.И. Действия казачьих отрядов Быхалова и Тимирова в 1812 г. // Отечественная война 1812 года: Источники. Памятники. Проблемы: Материалы XI Всероссийской научной конференции. Бородино, 2003 г. — Можайск, 2004. — С.24).

14. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XIII. — С.212.

15. Шунда ук. — Б.213.

Әлеге вакыйгалар кайчан булган? Оленин үзенең 22 июльдә Корытни торак пунктыннан язып җибәргән рапортында аның отрядына да, башкалардан тыш, «1 нче Типтәр полкының бер өлеше» кергәнлеген искәртә. Шул ук көнне 1 нче Типтәр полкы Сырокореньега җибәрелә. Полк аннан 50 француз җайдагын елганың аргы ягына — Гусиново авылына куып җибәрә. 23 июльдә Типтәр һәм Власов җитәкчелегендәге 3 нче Дон казаклары полклары җайдаклары Оленинга Гусиново һәм Ляды авыллары янында әсирлеккә алынган француз гусары белән поляк уланын илтеп тапшыра [16]. Шулай итеп, полкның ике өлешкә бүленгәнлеге, аның берсе — өч йөзлектән торган полк һәм калган икенче өлеше ике йөзлектән торган булуы ачыклана.

Типтәрләрнең рус армиясенең арьергарды составында батырлыклары хәрби җитәкчелек тарафыннан билгеләп үтелә. 21 июльдә «дошман гаскәре флангында һөҗүм итү өчен», генерал-адъютант барон Ф.Ф.Винценгероде җитәкчелегендә «җитез (летучий) корпус» оештырыла. 25 июльдә генерал Платов Власов җитәкчелегендәге 3 нче Дон казаклары һәм 1 нче Типтәр полкларын әлеге корпуска җибәрергә тәкъдим итә [17]. Әмма кайбер сәбәпләр аркасында әлеге тәкъдим тормышка ашмый кала.

26 июльдә Барклай де Толли белән Багратионның берләштерелгән армияләре, дошман гаскәрләренең берберсеннән аерым-аерым торуыннан файдаланып, аны өлешләп тар-мар итү өчен, Рудня авылы юнәлешендә һөҗүм башлый. Һөҗүм өч колонна белән хәрәкәт итүне күздә тота: янында уң һәм урта колонналар — 1 нче армия гаскәрләреннән, сул колонна 2 нче армиянең хәрби көчләреннән тора. Власов җитәкчелегендәге Дон казаклары һәм Типтәр полклары Днепр елгасының уң ягындагы Ракитна белән Чебуры авыллары арасындагы урманга урнашырга тиеш була [18]. Ләкин бу хәрәкәт уңышлы булып чыкмый. 8 августта Барклай де Толлиның 1 нче Көнбатыш армиясе Соловьёво авылы янында Днепрны кичеп чыга. Платов рапортыннан күренгәнчә, Типтәр полкы, Дон казаклары белән бергә, армия арьергарды составында Духовищенский юлыннан хәрәкәт иткән олаулыларның һәм яралыларның куркынычсызлыгын саклый. [19]. Типтәрләр Дорогобуж авылындагы арьергард гаскәрләре алып барган сугышта түбәндәге торак пунктлары янында катнаша: 17 сендә — Вязьма тирәсендә; 20 августта — Гжатски янында. Подполковник Власов җитәкчелегендәге Дон казаклары гаскәре, 1 нче Буг, Перекоп кырым-татар һәм 1 нче Типтәр полклары, «дошманның көчле һөҗүменә каршы торып, аны ике тапкыр чигенергә мәҗбүр итә һәм безнең авангардны бүлгәләргә мөмкинлек бирми» [20].

Тарихи чыганакларда 1 нче Типтәр полкының Бородино

16. Попов А.И. Первое дело при Красном. — М., 2007. — С.48.

17. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XIII. — С.218.

18. РГАДА. Ф. 1406. Оп.1. Д.1024. Л.31 об.

19. Шунда ук. — 1028. Л.26. Арьергардный бой, в котором участвовали тептяри у д.Пново, было 9 августа (Поликарпов Н.П. Указ.соч. — С.375).

20. Поликарпов Н.П. Күрсәтелгән сайланма хезмәт. — Б.453.

сугышында катнашуы турында фикер яшәп килде. Аның белән бергә бу сугышта 1811 елда армиягә Оренбург губернасыннан килгән 1 нче Башкорт полкы да катнаша [21].

Күптән түгел тарихчылар В.А.Бессонов һәм В.А.Попов Типтәр полкының зур бер өлешенең 20 август көннәрендә Юхнов өязен сакларга җибәрелгәнлеген ачыклады [22]. Кайбер документларның, шул исәптән Темиров хәбәрләре, Бородино сугышы көнендә полкның башка урында булуын раслый. Безнеңчә, мондый фикер төрлелеге полкның, сугыш башланганда, ике өлешкә бүленгән булуы белән аңлатыла. Күрәсең, Бородино янындагы бәрелештә полкның 4 нче һәм 5 нче эскадроннары катнашкан, ә «кече сугышларда» полкның калган йөзлекләре Темиров җитәкчелегендә сугышкан. Типтәрләрнең Бородино сугышында катнашуын әлеге вакыйганы күреп-күзәтеп торган кешенең язмасы раслый. Сугышта катнашкан И.Т.Радожицкий, лазаретны сурәтләп, болай дип яза: «Бер татар-типтәр казагы аеруча куркыныч һәм кызганыч иде: ... аның арка сөягеннән ядрә ярып алганда, ул коточкыч өзгәләнеп кычкырды, йөзе кара янган, куркыныч иде» [23].

Без В.А.Бессонов һәм А.И.Поповның бу чыганакның дөреслеген шик астына алуы белән килешәбез, чөнки Родожицкий, үзе гаять көчле контузия алып, тирә-юнендә ни хәл булганлыгын авырлык белән генә күзәткән. Аркадан ядрә алу операциясе вакытында мундирны йә салдыралар, йә ярып төшерәләр, ә шаровар белән аңа төшерелгән лампаслар төсеннән генә полкны төгәл ачыклау бик сирәк очракларда гына мөмкин. Шуңа күрә Бородино сугышында 1 нче Типтәр полкының ике йөзлеге катнашу-катнашмау мәсьәләсе бүгенгә кадәр ачык булып кала.

Типтәрләр 1812 елның көзендә башланган «кече сугышта» актив катнашалар. Алар 1 нче Буг казак полкы белән бергә Темиров җитәкчелегендәге хәрби отрядны тәшкил итәләр. 1812 елгы сугыш турындагы Россия историографиясендә әлеге факт моңарчы искә алынмады, фәкать бу полкларның аерым-аерым һәм аларның берләшмәләренең соңрак Д.В.Давыдов отрядында партизаннар сугышында катнашулары турында гына язылды. В.А.Бессонов белән А.И.Попов, беренчеләрдән булып, Смоленск губернасындагы Юхнов өязен саклау өчен ике отряд: Быхалов җитәкчелегендәге Дон һәм Быхалов кул астындагы гаскәр старшинасы Д.Д.Комиссаров Беренченең казак полклары; Темировның 1 нче Типтәр, 1 нче Буг казак гаскәриләреннән торган полклар җибәрелүен ачыклады. Темиров отряды (Тимиров) дошман фуражирларына һәм мародёрларга каршы көрәш алып бару өчен җибәрелә һәм Знаменское авылына урнаша, ә Быхалов отряды Калуга губернасы Медынск өязендә калдырыла.

Инде 26 августта ук Темиров үз рапортында дошман солдатлары — 10 испан һәм ике поляк әсир ителгәнлеген хәбәр

21. Усманов А.Н. Указ. соч.— С.34; История Башкортстана с древнейших времён до 60-х годов XIX века. — Уфа, 1996. — С.394; Мамонов В.Ф., Форстман Г.В. Гроза Двенадцатого года. — Челябинск, 1991. — С.45.

22. Бессонов В.А., Попов А.И. Указ. соч. — С.26; Отечественная война 1812 года. Энциклопедия. — М., 2004. — С.698.

23. Родожицкий И.Т. Походные записки артиллериста с 1812 по 1816 год // Бородино. Документы, письма, воспоминания. — М., 1962. — С.390.

24. Бессонов В.А., Попов А.И. Күрсәтелгән җыентык. — Б.23.

25. Давыдов Д.В. 1812 елгы партизан хәрәкәтләре көндәлеге // 1812 елгы рус поэзиясендә һәм шул заман кешеләре истәлекләрендә. — М., 1987. — Б.189; Михайловский А.И. 1812 елгы Ватан сугышы: Истәлекләр. — М., 2004. — Б.161. Андый хәл-әхвәлләр армиядә дә булган. Әйтик,

итә [24]. Ул 9 августта Юхново торак пунктыннан язган рапортында аның полкы җайдакларының 87 дошман солдатын юк итүен, 98 кешене әсирлеккә алуын күрсәтә [25]. Шуннан соң дошманның 51 фуражиры һәм мародёры әсир итеп алына. Шулай итеп, сакланып калган документлардан күренгәнчә, отряд 26 августтан 11 сентябрьгә чаклы 150дән артык кешене әсир төшерә, йөзләгән дошманны юк итә [26].

Сентябрь башында отряд, Вязьмадан Калугага кадәрге юлны каплап, Гжатский белән Мосальский якларына разъездлар җибәрә, әлеге өяздә хәрәкәт итә. Нәкъ менә шул вакытта 1 нче Типтәр полкында, Медыни авылыннан ерак түгел бер җирдә, фаҗигале хәл була. Шундагы бер авылда яшәгән җирле халык русча начар сөйләшүләренә һәм зәңгәр мундирларына карап, боларны французлар дип уйлап, 60 кешене һәлак итә [27]. Бессонов һәм Попов фикеренчә, бу вакыйга Егорье авылында 25 август көнне типтәрләр белән түгел, ә бәлки, хорунжий Ромоданов җитәкчелегендәге 1 нче Буг полк казаклары белән була. Без бу фикер белән килешә алмыйбыз. Төрле полклар хакында сөйләгәндә, Давыдовның ялгышуын күз алдына китерүе кыен. Буг буе казаклары һәм типтәрләр зәңгәр мундир кигән булган, тик беренчеләре русча сөйләшеп, православныйлар булса, типтәрләр исә, урысча начар сөйләшкән һәм, крестьяннар таләп иткәнчә, алар чукына белмәгәннәр, ә сугыш барышында руслар Наполеон сугышчыларын бик еш кына шушы ысул белән аерганнар. Давыдов болай дип яза: «Мин мужик кафтанын кидем, сакал җибәрдем, Изге Анна ордены урынына Изге Николай образын тагып куйдым һәм алар белән халык телендә сөйләштем» [28]. Типтәрләр белән булган бу фаҗигале вакыйганы А.И.Михайловский-Данилевский Мәскәү губернасында булган, дип яза. Ихтимал, монда сүз Темиров белән булган типтәрләрнең калган ике йөзлек җайдаклары хакында барадыр.

Темиров отряды белән бәйле барча вакыйгалар 24 августта шушы төбәккә җибәрелгән партизаннар отряды командиры подполковник Давыдовка мәгълүм була. «Моннан соң тиздән мин Юхново шәһәрендә дворяннар башлыгы, мәхкәмә вә земство җитәкчеләре барлыгын, шулай ук Юхново өязендә уртак максатсыз анда-санда йөргән көчсез ике казак полкы турында хәбәр алдым. Анда баргач, мин ике мәсьәләне хәл итәргә тырыштым: җирле халыкны күпләп ополчениегә кертү һәм икенчесе — минем гаскәргә ике казак полкын кушу». Н.П.Михневич фикеренчә, Давыдов казак отрядлары хакындагы хәбәрне 6 сентябрьдә алган [29]. Үз отрядын көчәйтү мәсьәләсен хәл итәр өчен, Давыдовка, үзе язганча, дипломатия алымын кулланырга туры килә. «Икенче мәсьәләне хәл иткәндә, мин хәйләгә бардым: бу казак полклары Калуга ополчениесе башлыгы отставкадагы генерал-лейтенант Шепелёв карамагында иде. Аның киң күңелле вә намуслы, вөҗданлы булуы миңа күптән билгеле иде, әмма

Вяземский болай сурәтли: «Минем Мамонов полкы мундирым, әйтергә кирәк, казакныкына охшамаган, армиядә билгеле түгел иде. Ул сыек зәңгәр каймалы чикмән иде. Башымда аю тиресе белән каймаланган биек зур кивер. Кайсында икәнлеген әйтә алмыйм, вә ләкин без Милорадович белән тулысынча хәрәкәттәге батареядә идек. Шунда яныма таныш булмаган бер офицер килде дә әлеге киверны кию мине уңайсыз хәлдә калдырырга мөмкин булуын әйтте. «Хәзер, — дип дәвам итте ул, — мин сезгә каршы «очып килгән» һәм миңа: «Карагыз әле, галиҗәнап, каһәрле француз кая килеп бәрелде!» — дигән казакны туктаттым!» Вяземский П.А. 1812 ел турында истәлекләр // Рус архивы. — 1 том. — 1869. — Б.6.

26. Давыдов Д.В. Күрсәтелгән җыентык. — Б.190.

27. Михневич Н.П. 1812 һәм 1813 еллардагы партизан хәрәкәтләре. — СПб., 1888. — Б.16.

мин кулына хәрби команда эләккән ополчение башлыгының ни икәнлеген белә идем! Бу хәл башлыкның мин-минлеген үстерә. Әлеге полкларның минем партия составына кертелү турындагы таләбем уңышсыз чыгасын белгәнгә, мин үз теләгем белән Шепелёвка буйсынуымны белдердем. Павловск авылыннан аңа поручик Бекетов аша рапорт җибәрдем. Шуның өстенә рапортымда, дошманнарны эзәрлекләгәндә, күрше губернада сугыш хәрәкәтләре алып барганда, аның җитәкчелегендә хезмәт итү минем өчен дәрәҗә, ә хәбәр җибәреп тору — бурычым, дип белдердем. Мин үземнең аз-маз уңышларымны сурәтләп һәм батырлык күрсәткән сугышчыларны бүләкләүләрен сорап, Юхново шәһәреннән Шепелёвка (минем чын рапортларым турыдан-туры Россия армияләренең кизү генералы булган Коновницынга җибәрелеп барды) тагын бер курьер җибәрдем. Минем яхшы күңелле Шепелёвым сoклануыннан эреп китте. Шепелёв аның планы буенча эш итүем, дошманны җиңәчәге турында хыяллана башлады. Тугызы көнне мин аңа, хәрәкәт итүдә бердәмлекнең файдасын бик матур шәрехләп, яңа курьер җибәрдем һәм, гадәттәгечә, рапортымны минем отрядны аның җитәкчелегендәге казак полкларын кушып көчәйтүен түбәнчелек белән сорап тәгәлләдем» [30]. Нәтиҗәдә һәр ике полкка да (Буг казак полкында — 60, Типтәр полкында 110 кеше) 10 сентябрьдә Давыдов отрядына керү турында күрсәтмә бирелә. Алар 11 сентябрь кичендә Знаменски авылы янында кушылалар.

Шуны ачыклап китү кирәк: В.Ф.Шепелёв М.И.Кутузов тарафыннан Калуга губернасы ополчениесе җитәкчесе итеп билгеләнә, аңа Смоленск губернасының Юхново, Ельня һәм Рославль өязләре дә буйсына. Шунлыктан, Юхново шәһәрендә урнашкан Давыдов команда буенча чынлыкта Шепелёвка буйсына һәм аңа даими рәвештә сугышчан эшчәнлеге турында рапортлар җибәреп тора, ә алар исә Шепелёв аркылы Кутузовка җиткерелә. Димәк, әлеге очракта да, Д.Давыдов, үзен отышлы итеп күрсәтү максатында, чынбарлыкны беркадәр бозып тасвирлый [31].

Үз отрядын көчәйтеп, Давыдов инде икенче көнне үк актив сугыш хәрәкәтләре башлый. «12сендә [сентябрь] мин Вязьманың үзендә эзләнүләр үткәрдем. Үз полкларымны күзәткәндә, минем йөрәгем шатлык белән тулды. Йөз дә утыз җайдак белән өч йөз җитмеш кешене вә ике офицерны әсир итеп алдым, үземнең ике йөз кешемне кире кайтардым һәм табыш итеп, патроннар төягән бер фураны (өсте ябык арба) һәм ун азык-төлек йөген алдым… Мин берьюлы өч йөз җайдак белән идарә иттем; нинди аерма! нинди ышаныч!..

Таң алдыннан без шәһәр күз алдында азык-төлек һәм артиллерия снарядлары транспортын саплап барган дошман отрядына һөҗүм иттек. Каршы тору ашкынулы кысуга бәрабәр

28. Давыдов Д.В. Күрсәтелгән җыентык. — Б.195.

29. Василий Фёдорович Шепелёв (1768-1813), Калуга губернасы дворяннарыннан. 1780 елда лейб-гвардия Преображенск полкында хезмәт итәргә билгеләнә. 1786 елның 1 гыйнвареннан атлы полкның лейб-гвардия корнеты. 1797 елдан — полковник, 1798 елдан — генерал-майор, Санкт-Петербург драгун полкының шефы. Польшага һәм Швейцариягә 1800 елдагы походларда катнашучы. 1802 елда Кавказ инспекциясе кавалериясенең инспекторы. 1805-1806 елларда 8 нче дивизия составында Наполеон сугышларында катнаша. Сугыш башланганда отставкада була. 1812 елда губернаның барлык хәрби частьләре буйсынган Калуга ополчениесе башлыгы итеп сайлана. I дәрәҗә Изге Анна, III дәрәҗә Изге Владимир орденнары, Мальтия тәресе, «За храбрость» алтын шпагасы белән бүләкләнә. (Безотосный В.М., Горшман А.М., Ивченко Л.Л. и др. Русские генералы в войнах с наполео-

булмады һәм бу мин көткәннән дә уңышлырак булды: ике йөз җитмеш рядовой һәм алты офицер коралларын ташлады, йөзгә якын кеше җирдә ятып калды; егерме азык-төлек йөге белән снаряд төягән унике артиллерия олавы безнең кулга төште» [32].

Давыдов отрядына кереп, 1 нче Типтәр полкы, Буг казак полкыннан аермалы буларак, үз мөстәкыйльлеген саклап кала. Ул аерым рейдларга җибәрелә. Әйтик, майор Темиров полкы 13 сентябрьдә 100 француз солдатын юк итә, 12 кешене әсир итеп ала [33]. Темиров полкы, 15-16 сентябрьдә Давыдов отрядыннан аерым хәрәкәт итеп, дошманның 54 кешесен һәм 79 фуражирын әсирлеккә ала. Ул, 18 сентябрьдә француз отрядына һөҗүм итеп, 100 кешене юк итә, 125 кешене әсирлеккә ала [34]. Трофей сыйфатында артиллерия снарядлары фурасы кулга төшерелә [35]. Мондый аерымлану, безнең уебызча, командованиенең Темиров отрядына Вязьмадан Калугага бара торган юлны саклауны бурыч итеп кую белән аңлатыла. Ә Давыдовның отряд белән турыдан-туры җитәкчелек итүе полкның мөстәкыйль хәрәкәт итүен боза. Моннан тыш Темиров, үзен отряд командиры дип санап, Давыдовка буйсынырга теләми һәм шунда ук Давыдовка мөстәкыйль хәрәкәт итәчәген тәкъдим иткәндер.

Әсирлеккә эләккән русларны азат итү максаты белән, Давыдов Никольское авылында тикшерү үткәрә. Төрле сәбәпләр аркасында әсирләрне азат итә алмыйлар, шулай да артиллерия паркы кулга төшерелә.

22 сентябрьдә Типтәр полкы яңадан Калуга ополчениесе башлыгы генерал-лейтенант Шепелёв карамагына җибәрелә. Аның үз җитәкчелегеннән чыгуын Давыдов болай дип аңлата: «Нәкъ шул вакытта мин Типтәр полкын, Орлов губернасын сакларга билгеләнгән Калуга ополчениесе отрядына ярдәм итү өчен, Рославль һәм Брянскка җибәрергә боерык алдым. Никадәр авыр булса да, мин Смоленскидан Орлов юлы буенча Рославльгә таба җибәрелгән һәм куркыныч тудырган дошман отрядларына каршы тору өчен, һич икеләнмичә, майор Темировка Мутищево аркылы Рославльгә барырга боердым» [36]. Бессонов белән Попов типтәрләрнең бер өлеше Давыдов отрядында калган булу ихтималын билгеләп үтә. Денисов үзенең 4 октябрьдәге хәбәрендә 1 нче Типтәр полкы есаулы Хәмит Сәгыйтовның дошман кавалериясен эзәрлекләвен һәм 16 кешене әсирлеккә алуын хәбәр итә [37].

Кутузов кушуы буенча Шепелёв В.М.Яшвиль җитәкчелегендә Типтәр полкы да кертелергә тиеш булган «корпус» оештыра (Яшвиль аның белән 30 сентябрьгә кадәр — Шепелёвка «корпусны» җитәкләргә рөхсәт ителгәнче идарә итә). 22 сентябрьдә Давыдов типтәрләрне Рославльгә юнәлдерергә боерык ала, аны шунда ук үти. Шул ук көнне полк, Мутищево (Юхнов өязе,

новской Франции в 1812-1815 гг. // Российский архив: История Отечества в свидетельствах и документах, XVIII-XIX вв. — М., 1996. — Вып. VII. — С.612).

30. Давыдов Д.В. Күрсәтелгән җыентык. — Б.198-199.

31. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XV. — С.33.

32. Отечественная война 1812 г. — СПб., 1911. — Т.XVIII. — С.101.

33. Журнал военных действий с 1 сентября по 31 декабря 1812 г. // Толь Е.Н. Генерал Толь Е.Н. Генерал-квартирмейстер Карл Фёдорович Толь в Отечественную войну. — СПб., 1912. — С.45.

34. Шул ук. — Б.207.

35. Бессонов В.А., Попов А.И. Күрсәтелгән язма. — Б.38.

36. Журнал военных действий с 1 сентября по 31 декабря 1812 г. // Толь Е.Н. Генерал Толь Е.Н. Генерал-квартирмейстер Карл Фёдорович Толь в Отечественную войну. — СПб., 1912. — С.71.

Мытищино) һәм Капустино авыллары янында француз отряды белән кара-каршы атышта катнашып, 60 кешене юк итә, 44 кешене әсирлеккә ала, сугышчан зарядлы туп ядрәләре әрҗәсен кулга төшерә. Типтәрләрдән иллебашы Сафарович яралана, 28 ат җәрәхәтләнә [38]. Сентябрьнең 28-30лары тирәсендә Темиров Рославльне ала, һәм аңа биредәге «казна тоз кибетен үз карамагына алырга» боерыла. Соңрак полковник Шепелёв кул астындагы Калуга ополчениесенең 5 полкы килеп җитә. Ләкин бүтән мәгълүматлар буенча, Темировның үз рапортында күренгәнчә, 23 сентябрьдә ул инде Рославльдә булган һәм өязне дошманнан чистарта башлаган [39]. Полк Забежне (Забежное) белән Устиново авыллары янында 24 һәм 25 сентябрь көннәрендә булган бәрелешләрдә дошманның 70 тән артык кешесен юк итә. 26-27 сентябрьдә Костыляне (Костыри) авылы янындагы 50 кешедән торган полякларның 1 нче атлы Егер полкы заставасына һөҗүм итеп, 21 дошманны юк итә, 6 солдатны әсирлеккә төшерә [40]. Полк үзенең 2 кешесен югалта, 31 ат һәлак була һәм яралана. 24-27 сентябрь арасында исә француз һәм поляк кавалериясе белән сугышлар алып барып, полк дошманның 100 кешесен юк итә [41]. Сугыш хәрәкәтләреннән тыш, типтәрләр разведка алып бара, ләкин алар, күрәсең, мәгълүматны читтән алганнар, чөнки кайвакыт булмаган гаскәрләр хакында да хәбәр итәләр. Әйтик: «Смоленски аша 8 австрияле кавалерия полклары узды, алар 4 гусар венгр полкыннан тора иде, алар Смоленскидан Мәскәүгә бара торган юлдан атна дәвамында үттеләр» [42].

Бессонов, гадел рәвештә, Калуга ополчениесенең 1812 елгы Ватан сугышында катнашуын гадел рәвештә 2 этапка бүлеп карый. Беренчесе – август уртасыннан октябрь башына кадәргесе – Калуга губернасын саклау белән бәйле. Бу этапта ополчение тәртип саклау белән шөгыльләнә, губернадагы дошман гаскәре белән сугыш алып бара. Икенчесе – хәрәкәт итү этабы – ополчениенең аерым отрядка («В.Ф.Шепелёв корпусы») кушылуы һәм аның составында Смоленск губернасының көньяк өязләрен дошманнан азат итүдә актив катнашуы һәм Могилёв губернасында тәртип урнаштыруы белән бәйле [43]. 1 нче Типтәр полкы, Калуга ополчениесенең 5 нче җәяүле Казак полкы белән бергә, 15-16 октябрь көннәрендә Семиново, Ступино авыллары янында сугыш алып бара, дошманны Хмары авылына кадәр эзәрлекли. Рус чыганакларында күпертеп язылганга охшаган мәгълүматларга караганда, бу сугышларда катнашкан дошман гаскәрендә 1200 җәяүле солдат һәм җайдак санала. Канкойгыч бәрелешләрдә дошманның 70 солдаты үтерелә, 95е әсирлеккә алына, ә калганнары типтәрләр һәм ополчение басымы астында чигенә. Кылган батырлыклары өчен бүләкләнүгә түбәндәгеләр тәкъдим ителә: полк шефы майор Темиров – бантлы 4 нче дәрәҗә Изге Владимир орденына, прапорщик Манасыпов (дөресе – Монасыйповтыр) – 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденына, зауряд-хорунжий Абраһимов (Ибраһимов) –

37. Отечественная война 1812 г. – СПб., 1911. – Т.XIX. – С.25-26.

38. Кутузов М.И. Сборник документов. – М., 1955. – Т.IV. – Ч.2. – С.73.

39. Отечественная война 1812 г. – СПб., 1912. – Т.XIX. – С.25.

40. Шунда ук. – Б.26.

41. Бессонов В.А. Калужское ополчение в Отечественной войне 1812 года // Отечественная война 1812 года: Источники. Памятники. Проблемы. – М., 2005. – С.191; Попов А.И. Дело при Ляхово. – М., 2000. – С.9-13; Бессонов В.А. «Корпус» генерал-лейтенанта В.Ф.Шепелёва в Отечественной войне 1812 г.

42. Отечественная война 1812 г. – СПб. – С.162 .

43. Бессонов В.А., Попов А.И. Күрсәтелгән җыентык. – С.39.

хорунжий чинына. Шепелёв үз тәкъдимнамәсендә күрсәткәнчә, әлеге сугышчылар — нык оештырылган җәяүлеләр һәм атлылар ике пикеттан торган ике яклы кыю һөҗүм итеп, аларны тар-мар иттеләр һәм әсирлеккә алдылар, сугыш ахырына кадәр батырларча хәрәкәт кылдылар» [44]. Калуга губернасы ополчениесе һәм аның составындагы 1 нче Типтәр полкы 4 ноябрьдә Мстиславльне яулап ала, ә аннан Могилёвка юнәлә. 16 ноябрьдә Могилёвны алгач, губернада тәртип урнаштырып, полк кышкы квартирларга туктый. Декабрь ахырында полк генерал М.А.Милорадович корпусына керә.

Шулай итеп, Темиров отрядына кергән 1 нче Типтәр полкы 1812 елның көзендә Юхново өязе җирендә Вязьмадан Калугага кадәрге мөһим юлны ике атнадан артык саклап тора һәм дошманның фуражирлары белән мародёрлары партияләренә каршы актив көрәш алып бара. 1 сентябрьдә Темиров отряды Давыдовка буйсына, ләкин мөстәкыйль гаскәр булудан туктый. Типтәрләр хәрби бурычларны мөстәкыйль гаскәрләр кебек хәл итә [45]. Аннары полк, Калуга губернасы ополчение отрядына кушылып, аның составында сугышны тәмамлый. Әлеге бәрелешләрдә типтәрләр дә югалтуларга дучар булалар, атлар төркемен тулыландыру, ватылган-бозылган коралны алмаштыру эше начар куелган була. 30 сентябрьгә полкта 120 кеше кала. Моннан тыш типтәрләрнең бер өлеше (ике эскадрон) армиядә була һәм хәрби полиция сак сыйфатында файдаланыла, Углич өязендә полкның квартирмейстеры торганлыгы мәгълүм [46].

Оренбургта торган 2 нче Типтәр полкы походка 1812 елның 8 сентябрендә чыга [46]. Ул Самара, Сембер, Арзамас аша Түбән Новгородка юл ала, шәһәргә 18 октябрь көнне килеп җитә. Типтәрләр биредән башкорт, мещеряк полклары белән бергә Владимирга озатыла. Декабрьдә полк полковник В.А.Углицкий бригадасы составында (Оренбург атаман, 2 нче Типтәр, 7 нче атлы Башкорт полклары) граф П.Х.Витгенштейн корпусына җибәрелә. 1812 елның декабреннән 1813 елның март ае арасында полк Санкт-Петербургта гарнизон хезмәтен үти.

Русчадан Әхәт Гаффар тәрҗемәсе.

44. Волконский Д.М. Дневник 1812-1814 гг. // 1812 год. Военные дневники. — М., 1990. — С.151; Отечественная война 1812 г. — Т.XIX. — С.26.

45. РГВИА. Ф. 846. Оп. 16. Д. 16853. Л. 2 об. — С.3.

46. Кутузов М.И. Сборник документов. Т. I, Ч.1, № 517.

Д.Бунтуков фотосы

БЕЗ ДӘ БӨЕК

РИФАТ СӘЛАХ

Без тарихсыз, җансыз милләт түгел,
Дөнья тоткан горур татар без.
Болгар, Урда, Казаннарны ничек
Чал тарихтан алып атарбыз?!

Без таркалган, тузган, сүнгән түгел,
Бездә югалмаган бердәмлек.
Биш гасырга якын юкка чыкмый
Тоткынлыкта гомер сөргән бит.

Без дәүләтсез, илсез, хансыз түгел,
Татарстан — туган оябыз,
Киләчәккә очкан илебезне
Канатлы ат итеп тоябыз.

Без имансыз, динсез-денсез түгел —
Күмалмаган заман агышы.
Күккә ашкан биек манарадан
Ишетелә азан тавышы.

Юк, без кансыз-вәхши халык түгел —
Таш диварлар гүя кабатлый:
«Үзен күралмаган милләт кенә
Башка халыкларны яратмый!»

ИДЕЛ-УРАЛ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ГОСМАНЛЫ ҖИРЛӘРЕНӘ

XIX ГАСЫРНЫҢ 70 НЧЕ ЕЛЛАРЫНА КАДӘРГЕ КҮЧЕШЛӘРЕ

АРЗУ КЫЛЫНЧ,
доктор, Мигъмар Синан Нәфис сәнгать университетының (Истанбул) тарих укытучысы

БУ МӘКАЛӘ ПАТША РОССИЯСЕНЕҢ ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕННӘН ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕ ҖИРЛӘРЕНӘ КҮЧЕП КИЛЕП УРНАШУЛАРНЫҢ КАЙЧАН БАШЛАНГАНЫН ҺӘМ МӨҺАҖИРЛЕКНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕН АЧЫКЛАУНЫ МАКСАТ ИТЕП КУЯ. БИРЕДӘ БАРЫННАН ДА ЭЛЕК РОССИЯ ҺӘМ ГОСМАНЛЫ ИМПЕРИЯЛӘРЕ АЛЫП БАРГАН СӘЯСӘТ БЕЛӘН БЕРГӘ АЛАР АРАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘРНЕҢ ДӘ БУ ПРОЦЕССТА ӘҺӘМИЯТЛЕ РОЛЬ УЙНАГАНЫН БИЛГЕЛӘП ҮТӘРГӘ КИРӘК.

Госманлылар XIV гасырда, ягъни бәйлекләр дәверендә, Балканга үтеп керәләр. Фатих Солтан Мөхәммәд II (1451-1481) 1453 елда Византия империясен яулап алуны тәмамлаганнан соң, Госманлы күп халыклы һәм күп динле дәүләткә әверелә. Ул солтанлык иткән чорда Истанбулның

төньягындагы Кара диңгез буйлары кыска вакыт эчендә яулап алына. Башта Кара диңгезнең көньяк ярларындагы әһәмиятле сәүдә портлары Амасра һәм Синоп, аннан соң Трабзон (1461) кулга төшерелә. 1475 елда исә Кара диңгезнең төньяк ярындагы Кырым ханлыгы Госманлы дәүләте вассалына әверелә. Шул рәвешле, бу вазгыять, генуэзлар сәүдә итә торган Кәфә, Судак кебек ышанычлы портларның һәм Азов һәм Кара диңгезләрнең Госманлы дәүләте хакимияте карамагына күчүенә китерә.

XVI гасырның урталарында, Идел буенда урнашкан Казан, аның артыннан Әстерхан һәм Себер ханлыклары бер-бер артлы Россия кулына төшкәннән соң, Кара диңгездән төньякка таба урнашкан җирләр һәм тора-бара Кара диңгез үзе дә бу ике дәүләтнең көндәшлегенә сәхнә була. Кара диңгездә барган көрәш 1768 елда башланган госманлы-рус сугышының ахырында имзаланган 1774 елгы Күчүккайнарҗа килешүе Госманлы дәүләте файдасына булмый. 1783 елда Тамань ярымутравын һәм Кубань вилаятен дә үз эченә алган Кырым ханлыгы Россия тарафыннан яулап алына. Госманлы дәүләте бу басып алуны һәм Грузиядәге рус хакимиятен 1786 елда — Истанбулда, 1792 елда Йашта имзаланган килешүләр белән таный [1].

XVIII гасыр ахырында Кара диңгез ике дәүләт арасында табигый чик рәвешен ала. Кырымның җирле халкы булган татарлар басып алу дәвам иткән елларда, җирләре яулап алыну сәбәпле, төркем-төркем Госманлы дәүләте җирләренә күчеп утыра башлыйлар.

Башлангыч чорда, нигездә, Шаһин Гәрәй хан хакимлеге астында яшәгән татарлар күчеп китә. Моннан тыш 1783-1784 елларда күчкән 8 мең татар арасында Кәфәдә яшәгән Госманлы дәүләте тәбәгасе (ватандашы)да шактый була [2]. 1828-1829 еллардагы Госманлы-рус сугышы һәм Кырым сугышы (1853-1856) чорында дәвам иткән бу күченүләр белән бәйле эзләнүләр алып барганда, мөһаҗирләр арасында чыгышлары белән Идел-Урал төбәкләреннән булган кешеләр һәм төркемнәр дә очрый. Алда, XIX гасырның ахырларында, күпкә артачак бу сан, әлбәттә, ул елларда кырым татарлары белән чагыштырганда күпкә аз. Тик шунысы ачык: Кырымнан күчүләр Идел-Урал татарларына да йогынты ясаган. Кырым сугышы елларында Кара диңгезне кичү куркыныч юл булса да, һаман да арта барган пароход сәфәрләре мөһаҗирләр өчен уңайлы шартлар тудыра, мөһаҗирләрнең санын арттыра.

Гомумән алганда, 1783-1922 еллар арасында Госманлы дәүләтенә килгән мөһаҗир татарларның саны якынча 1 млн 800 мең кеше тәшкил итә [3].

Бу сугышлар Россиянең мөселман халыкларына, бигрәк тә гаскәргә алынган яшьләргә, аеруча көчле йогынты ясый. Сугыш яралану яки гарипләнүләрне генә түгел, әсир төшү яки яу кырында үлеп калуларны аңлата. Патша Россиясе гаскәрләрендә

1. Hasan Şahin, «Kaynarca'dan (1774) Paris Barışı'na Kadar Şark Meselesi Perspektifinden Osmanlı-Rus Münasebetlerine Genel Bir Bakış», Türkler, C. XII, Ankara, 2002. – s.532.

2. Alan Fisher, Kırım Tatarları, (çev. Eşref B. Özbilgin), Selenge yay., İstanbul, 2009. – s.114.

3. Kemal Karpat, The Ottoman Population (1830-1914), University of Wisconsin press.,Wisconsin, 1986. – p.66.

руслар белән бергә сугышкан, госманлыларга әсир төшкәннәр арасында Урта Идел буе татарлары да очрый. Мәсәлән, 1790 елгы бер архив документында рус әсирләре арасында биш Казан төбәге татары барлыгы белдерелгән. Бу биш егет, мөселман булуларын сәбәп итеп күрсәтеп, азат ителүләрен сорап, үтенеч язуы язганнар [4].

Госманлы-рус сугышларында мөселман сугышчыларның гаскәрдән качып китүләре еш очрый [5]. Госманлы дәүләтенә эләккәч, аларның уртак теләге ватандашлыкка кабул ителү була. 1828-1829 еллардагы сугышта да моңа охшаш вакыйгалар күзәтелә. Мондый кешеләрне илдәш итеп кабул иткәнче, аларның шәхесе бик җентекле тикшерү үткән. Нәтиҗәләр уңай булган очракта гына алар ватандашлыкка кабул ителгән [6].

Кырым сугышында әсир төшкән рус гаскәриләренең кайберләре Ходавәндигяр вилаятенең (губернасының) Карахисары Сахиб санҗагына (өязенә) бәйле һәм Чифтәләр харасы (ат заводы) исеме белән дә мәгълүм булган Чифтлике Һомаюнга (солтанның шәхси утарына) урнаштырылганнар һәм шунда яшәгәннәр [7].

БАЛКАНГА КҮЧЕП УТЫРГАН ХАЛЫКЛАР

1853-1856 еллар Кырым сугышы Госманлы дәүләтенә күчешләр һәм мөһаҗирләргә бәйле мәсьәләләр белән йөзгә-йөз очраштырган беренче сугыш булды [8]. Австрия оккупациясендәге Әфлак һәм Бугдан (Румыния һәм Молдавия) төбәкләреннән җир өсте һәм диңгез юллары аша Румелигә (Румиле — Госманлы дәүләтенең Европа өлешендәге җирләре) килгән мөһаҗирләрне кабул итү, урнаштыру эшләре Силистрә губернаторлыгына тапшырылган була. Силистрә һәм бу губернага бәйле портлар мөһаҗирләр өчен империя җирләренә үтеп керү үзәкләре булып торган [9].

Кырым басып алынганнан соң, 1784-1850 еллар арасында татарларның бер өлеше Балканга күченеп китә һәм бүгенге Румыниянең Дубруҗа төбәгенә, Бабадаг белән Күстәнҗә (Констанца) районнарына урнаштырыла. Кырым сугышыннан соң мөһаҗирләр Дубруҗаның көньяк-көнбатыш тарафына урнаштырылалар һәм биредә Мәҗидия шәһәрчеген төзиләр [10]. Шул сәбәпле Дубруҗадагы Күстәнҗә һәм Мәҗидия шәһәрләрендә, Болгариянең Варна һәм Силистрә шәһәрләрендә шактый күп санда татарлар яши [11]. 1854 елда Дубруҗа русларның кулына күчә һәм көчле ныгытмалары булган Силистрә дә хәтта берара камалышта кала [12]. Болардан тыш без Күстәнҗәдә һәм кырым татарлары урнаштырылган Мәҗидия шәһәрләре әйләнә-тирәсендә казан татарлары да булган, дигән фикердә торабыз.

4. HAT 1398 / 56158, 29 Zilhicce 1204 / 09.09.1790.

5. Geniş bilgi için bkz. Nedim İpek, «Rus Ordusundaki Türk Askerlerinin Osmanlı Tâbiiyetine Geçmesi (1911-1917)», Tarih ve Toplum, sayı: 145, Ocak 1996, s. 14-19.

6. C. AS., 1106 / 48925, 05 Zilhicce 1243 / 18.06.1828 Rus ordusundan firar eden iki nefer hakkında alınacak tedbirlere dair olan bu belgenin orijinali, tamire muhtaç durumda olduğundan görülememiştir.

7. A. MKT. MHM. 74 / 29, 7 Zilhicce 1271 / 20.08.1855 Бүгенге көндә Иске Шәһәр илчесе булган Чифтәләргә Кырым һәм 1890 еллар ахырындагы Казан мөһаҗирләре җирләшәләр Günümüzde Eskişehir'e bağlı bir ilçe olan Çifteler'e Kırım ve 1890 sonrasında Kazan muhacirleri (Kuruhöyük köyü) iskân ettirilmiştir.

8. Osmanlı Belgelerinde Kırım Savaşı (1853-1856), (haz. K. Gurulkan, M. Küçük, Y. İ. Genç…), Başbakanlık Devlet Arşivleri Genel Müd. yay., Ankara, 2006, s. VI.

Шиһабетдин Мәрҗани хаҗга барышлый портлы шәһәр Измирдә тукталы, анда Сәйфулла бине Гали исемле якташы белән күрешүе турында искә ала. Мәрҗанине каршы алып, озатып калучы бу кеше Измиргә кадәр үзенең Күстәнҗәдә яшәгәнлеген, башта мал-мөлкәтле булып та, соңыннан байлыгын югалтып, мөшкел хәлгә төшкәнлеген сөйли [13].

1850 елга караган архив документында да бу төбәкләрдән Истанбулга җибәрелгән бер казан татары турында сүз бара. Варнада алдап талау белән шөгыльләнүдә гаепләнеп кулга алынган һәм Истанбулга җибәрелгән бу кешенең исеме — Йосыф бине Мөхәммәд. Биредә аның Россия кешесе һәм чыгышы белән казан татары булуы, Венгр эмигрантлары белән бергә Шумнуга китүенә бәйле мәгълүмат теркәлгән. Иленә кире кайту өчен, Россия илчелегенә мөрәҗәгать итәргә рөхсәт бирелгәнлеге, көтелгән җавап килгәнче, жандарм идарәсе изоляторында тотылачагы турында да белдерелгән [14].

Польша татарлары арасында да Госманлы дәүләтенә күченеп килүчеләр булган. Польшадан килгәнлеген белдергән Мәхмүд бине Мостафа 1850 елда Истанбулда яшәгән бертуганы белән күрешү өчен гариза язган. Ул гаризасында ата-бабаларының Урта Идел буеннан килгәнлеге, үзенең намаз кылуын һәм «Фатиха» сүрәсен яттан белүен теркәгән [15].

Бу елларда төрле сәбәпләр белән Истанбулга килеп чыгучылар һәм Мәҗидия шәһәренә китәргә теләүчеләр булган. Әйтик, бер архив документында Казан мөһаҗирләреннән Мөхәммәт исемле кеше 1857 елда вакытлыча Истанбулда яшәве һәм Мәҗидиягә китеп, шунда төпләнергә теләве, моның өчен матди ярдәм соравы турында мәгълүмат теркәлгән. Ул алырга теләгән акчаның күләме мөһаҗирләргә бирелә торган 100 курушлык пароход билеты бәясе һәм 106 куруш кирәк-ярак акчасы булуы язылган [16].

Кырым сугышында рус гаскәре Балканда, Кавказда, Кырымда — берничә җирдә сугыша. Төньяк Баязитне кулга төшереп, Карска үтеп керә. Бу форсаттан файдаланып, Хәсән бине Мостафа һәм Хәсән бине Хөсәен исемле казан татарларыннан булган ике солдат сыену сорап мөрәҗәгать иткәннәр. Диңгез юлы белән Трабзоннан Истанбулга килеп җиткәннән соң, рәсми оешмаларга Мәҗидиягә китәргә теләүләрен белдергәннәр, пароход өчен түләнгән 150шәрдән 300 курушлык билет бәясен түләүләрен сорап гариза язганнар [17].

Һаман да арта барган күчешләр нәтиҗәсендә халык төркемнәрен урнаштыру, вакытлыча булса да яшәү урыны белән тәэмин итүдә Госманлы дәүләте төрле кыенлыклар алдында кала. Зур төркем мөһаҗирләр турында сүз алып барсак, килеп туган кыенлыкларны хәл итү өчен, хөкүмәт тарафыннан башкарылган чараларның беренчесе яңа яшәү урыннары төзү булуын искәртеп үтәргә кирәк. 1863 елда Изник күле

9. Ahmet Cevat Eren, Türkiye'de Göç ve Göçmen Meseleleri, Nurgök matb., İstanbul, 1966, s. 40-41.

10. Nedim İpek, Rumeli'den Anadolu'ya Türk Göçleri (1877-1890), TTK yay., Ankara, 1999, s. 4.

11. A. MKT. UM., 412 / 55, 07 Zilhicce 1276 / 27.06.1860.

12. A. MKT. NZD., 323 / 69, 18 Safer 1277 / 05.09.1860.

13. Mercani, (yay. Salih bin Sabit Gabidullin), Maarif neşr., Kazan, 1915, s. 8-9.

14. HR. MKT., 33 / 42, 19 Cemaziyelahir 1266 / 02.05.1850.

15. A.MKT. UM., 17 / 66, 27 Receb 1266 / 08.06.1850.

16. A. MKT. UM., 398 / 17, 5 Şevval 1276 / 28.02.1860.

17. İrade, Dahiliye, 25149, 05 Zilkade 1273 / 15 Haziran 1273 / 27.06.1857.

янындагы сазлы җирләрне киптереп, шунда өч-дүрт яңа авыл төзергә рөхсәт бирелүе — шул чараның бер үрнәге. Төзеләчәк авылларның һәрберенә якынча 50-60ар бүлмәдән (номердан) торган йорттан 150-200 кунакхэнә-йорт төзү һәм Идел буеннан килгән мөһаҗирләрне урнаштыру планлаштырыла. Тагын Идел буеннан башка мөһаҗирләр булса, аларны да, алардан соң киләчәкләрен дә — һәммәсен Изниккә җибәрергә дигән карар кабул ителә [18].

18. A. MKT. MHM., 278 / 90, 17 Rebiülahir 1280 / 01.10.1863.

XIX гасырда көчәя барган панславизм идеологиясе һәм Россиянең көньякка йогынтысын көчәйтү сәясәте Балканда зур сугышлар кабынуга сәбәп булган, миллионлаган кеше моның йогынты астында калган. 1877-1878 еллардагы Госманлы-рус сугышыннан соң кул куелган Аястефанос (Сан-Стефано) һәм Берлин килешүе нигезендә, Румыния, Сербия һәм Карадаг бәйсезлек ала. 1912-1913 еллардагы Балкан сугышлары тәмамлангач, Румелидә яшәгән мөселман төрек халкы Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр була. Аңа кадәр Балканга урнашып яши башлаган кырым татарлары һәм чиркәсләр, шул исәптән казан татарлары да, икенче тапкыр күчеп китә.

Башта Румыниягә, аннан соң Төркиягә күченгән Казан төбәге мөһаҗирләренең бер өлешен Мәрмәрә районының көньягына, Бандырманың Манъяс күле яннарына урнаштыралар. Болардан 61 гаилә [19] яшәргә алачык булса да төзер өчен ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәннәр, күл тирәсендәге камыш һәм җикәнне алачык төзүдә кулланырга рөхсәт сораганнар, дәүләткә түләргә тиеш салымнардан азат итүләрен үтенгәннәр [20].

19. Йорт санын дүрткә тапкырлап, якынча кеше санын чыгарырга мөмкин.

20. ŞD., 382 / 2, 02 Muharrem 1317 / 12.05.1899.

ГОСМАНЛЫНЫҢ БАШКАЛАСЫ ҺӘМ ХӘЛИФӘЛЕК МӘРКӘЗЕ ИСТАНБУЛДАГЫ ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕ ТАТАРЛАРЫ

XVIII гасыр ахырларыннан Госманлы җирләренә күчеп утырган халыкларга нисбәтле мәгълүматлар күп түгел. Бу хәл, мөгаен, ул вакытларда күчешләр белән бәйле дәүләт хезмәтенең тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган һәм билгеле бер җитәкчелеккә йөкләнмәгән булуыннан килеп чыккан. 1839 елдагы Танзимат фәрманы игълан ителгәнче, чик буендагы районнарга күчеп утырганда, я Истанбулдан җибәрелгән күрсәтмәләргә таянып эш ителгән, я мөһаҗирләр үзләре дәүләткә мөрәҗәгать итә торган булганнар. Истанбул идарәләре күчеп килеп урнашуларны билгеле бер тәртипкә кертү өчен, уңайлы төбәкләрне алдан ук билгеләп куйган.

1831 елда оештырылган һәм бер үк вакытта күчешләрне дә контроль астында тоткан Истанбул шәһәре идарәсе 1855 елдан соң заманча оешмага әверелә башлый. Мөһаҗирләрнең һаман да арта баруы исә 1859 елда Мөһаҗирләр комиссиясе оештыру зарурияten тудыра [21]. Бу комиссия мөһаҗирләр урнаштыры-

21. Ahmet Cevat Eren, Türkiye'de Göç ve Göçmen Meseleleri, İstanbul, 1966, s. 39-41.

лачак җирләрне сайлау, аларны ул җирләргә китерү, акчалата һәм башка төрле ярдәм итү (юл чыгымнары, чәчү орлыклары, азык-төлек) кебек мәсьәләләр белән шөгыльләнә.

Мөһаҗирләр комиссиясенә караган 1861 елгы бер эш кәгазендә Казан мөһаҗирләренә күрсәтеләчәк мөгамәлә алдагылардан үзгә булмаячагы белдерелә [22]. Әлеге мәгълүматка нигезләнеп, татарларының оешкан хәлдә күчеше бу вакыттан соң тагын да сизелерлек арткан, дигән фикергә килергә мөмкин. Казан татарларының Идел-Урал төбәгеннән күчешләре артуын 1861 елда Россиядә крепостнойлыкның бетерелүе, ягъни татар крепостной крестьяннарының азат ителүе белән бәйләү бик үк дөрес булмас. Чөнки казан татарлары арасында крепостнойлык бик җәелмәгән иде [23].

Дәүләттән матди ярдәм алу максатыннан язылган гаризалар белән танышу, бу төбәк мөһаҗирләре турында беркадәр мәгълүмат алырга мөмкинлек тудырды [24]. Госманлы дәүләтендә вакытлыча яшәүчеләр арасында да акчалата ярдәм алучылар булган. Дәүләт төрле сәбәпләр аркасында Россия, Кавказ, Урта Азия һәм Кытайдан Истанбулга килгән һәм матди шартлары начар булган мөселманнарга, хаҗиларга ярдәм иткән. Мондый мөгамәләнең яңадан-яңа күчешләр өчен дә юл ачкан булуы ихтимал.

Истанбулга күчеп килгән кешеләрнең азык-төлек һәм башка төрле ихтыяҗлары мәсьәләсендә Мөһаҗирләр комиссиясе, мөмкин кадәр ярдәм күрсәтүдән тыш, аларга көнлек акча бирдерү өчен дә тырышлык куйган. Шул рәвешле, мөһаҗирләргә кагылышлы күрсәтмәләр нигезендә, 12 яшьтән өлкән балалар да, зурлар рәтенә кертелеп, өлкәннәргә — 100, кечкенәләргә 50шәр куруш акча бирү турында карар кабул ителгән [25].

1841 елда Хаҗгагында Әхмәд Җәмил әфәнденең өендә кунак булган Казан кешесе Мирза Мөхәммәд Гариф бер айлык акча алу өчен гариза белән мөрәҗәгать иткән [26]. Бер ел үткәннән соң, шул ук кешенең Кыршәһәрдә яшәгәнлеге, андагы дин галимнәре һәм башка кунаклар белән бергә аралашуы билгеле. Малия нәзарәте (Финанс министрлыгы) аның утыз көнлек чыгымнарын түләү турында карар чыгарган [27].

1847 елда Болгар шәһәреннән килгән, Хуҗа Әхмәт нәселеннән булган Мөхәммәт һәм Габделкәрим исемле ике бертуган Һашим ага исемле кешенең өендә кунак булганнар. Гаризаларына җавап йөзеннән, аларга ике ай буе көненә унар куруш акча бирергә, дигән карар чыгарылган [28]. Бу кешеләр соңыннан илләренә кайтып киткәннәрме-юкмы — бу хакта мәгълүмат теркәлмәгән.

Тагын бер документ Казан мөһаҗирләреннән булуы теркәлгән Мөхәммәт әфәнде исемле кеше белән бәйле. Матди хәленең авыр булуын әйтеп, бу кеше, үзенә акча түләүне үтенеп,

22. A. MKT. NZD., 361 / 40, 27. Muharrem 1278 / 05.08.1861.

23. İskender Gilyazov, «XI-XVIII. Yüzyıllarda Çarlık Rusyası'nda İdil-Ural Tatarları», Türkler, C. 18, s. 413, Ankara, 2002.

24. C. ML., 331 / 13580, 20 Ramazan 1233 / 17.07.1841.

25. Ahmet Halaçoğlu, a.e., s. 80.

26. C. ML., 208 / 8575, 27 Cemaziyelevvel 1257 / 17.07.1841.

27. C. ML., 57 / 2611, 07 Zilkade 1258 / 10.12.1842.

28. C.HR., 131 / 6504/ 18 Rebiülevvel 1263 / 04. 04.1847.

Тиҗарәт нәзарәтенә (Сәүдә министрлыгына) мөрәҗәгать иткән [29]. Хаҗи Мөхәммәт Кәрим исемле казан татары исә гаиләсендәге тугыз кеше белән бергә, Госманлы дәүләте боерыгы астына кабул ителүен сорап гариза биргән [30].

XIX гасырның урталарында Истанбулда һәм башка шәһәрләрдә белем алган, вакыт үтү белән саннары арта барачак мәдрәсә шәкертләре игътибарны җәлеп итә. Болар арасыннан казан татарлары имам Мөхәммәт һәм хаҗи Әхмәт, гыйлемнәрен арттыру максатыннан килүләрен белдереп, биредә яшәү дәверендә айга иллешәр куруш түләү билгеләнүен сораганнар. Аларның гаризалары Губернатор Мәҗлесе тарафыннан кабул ителгәннән соң, үтенечләрен канәгатьләндерү өчен, Малия нәзарәтенә тапшырылган [31].

Хәрбия (сугыш белемнәре) мәктәбе укучылары булган казан татарлары Габдеррахман һәм аның бертуганы Салих, Россия дәүләте боерыгыннан чыгып, Госманлы дәүләте боерыгы астына керү өчен гариза биргәннәр [32]. Шул рәвешле, Истанбул һәм башка шәһәрләрдәге белем бирү йортларына кабул ителү бер үк вакытта ватандашлыкка күчүнең бер юлы да булган.

Истанбулга килеп урнашкан Идел-Урал төбәге мөһаҗирләренең бер өлешенә караган мәгълүматларны мәктәп яшенә җиткән балаларын укырга биргәндә язган гаризалары аша эзләп табу мөмкин булды. Мәсәлән, 1869 елда Истанбулда Давутпаша мәхәлләсендә яшәүче бер казан татарының, берсе телсез булган ун һәм унике яшьләрендәге балаларын Сәнәгать (җитештерү белемнәре) мәктәбенә урнаштыруы эш кәгазьләренә теркәлгән [33].

Истанбулдагы казан татарлары ул чорларда мөселман катлавы яшәгән Фатих, Баязит, Солтанәхмәт, Нурыгосмания һәм Мәхмүтпаша районнарында көн күргәннәр. Моңа ватандашлыкка кабул ителү, түләүләр алуга ирешү эшләре хәл ителә торган рәсми даирәләрнең биредә урнашкан булуы да, мөгаен, тәэсир итми калмагандыр. Бигрәк тә юлчы пароходлары туктый торган Каракөй, Әминөнү, Сиркәҗи кебек портлар һәм пристаньнарга якын урнашкан бу районнарда Россия мөселманнары тукталып яшәп калган тәккәләр (дәрвиш гыйбадәтханәләре), ханнар (кәрван сарайлар) һәм кунакханәләр күп булган. Әлеге районнарның җанлы сәүдә үзәкләре булуы юлчыларның игътибарын җәлеп иткәндер. Чынлап та, сәүдә эшенә осталыклары белән аерылып торган казан татарлары арасында Төркиядә эшчәнлек алып баручылар да булган. 1855 елда казан татарлары Габдулла, бертуган энесе Хәсән һәм өч дусты, Истанбулда сәүдәгәрлек таныклыгы бирелүне көтеп, Хәрбия (сугыш мәсьәләләре) нәзарәтендә вакытлыча яшәп ятканнар [34].

XIX гасырның ахырларына таба Фатих Казаннан килүче мөһаҗирләр күпләп яшәгән районга әйләнә. Аеруча Фатих мәчетендә вазифа башкаручы һәм Фатих мәдрәсәсендә белем алучы Идел-Урал яшьләренең саны арта [35]. 1857 елда Истан-

29. A. MKT. NZD., 243 / 26, 7 Rebiülahir 1274 / 25.11.1857.

30. MVL., 825 /136, 18 Zilhicce 1275 / 19.07.1859.

31. İrade, Meclis-i Vâlâ, 179 / 6, 8 Cemaziyelahir 1275 / 14.01.1859.

32. HR. TO., 494 / 79, 20.12.1866.

33. ŞD., 2854745, 27. l. 1285 / 10.02.1869.

34. A. MKT. DV., 78 / 51, 15 Cemaziyelevvel 1271 / 03.02.1855.

35. Arzu Kılınç, «İdil-Ural'dan Göçler, Neden ve Sonuçları (19. yüzyıl sonu ve 20. yüzyıl başı)», Doktora Tezi, (danışman: Prof. Dr. Nadir Devlet), Marmara Üniversitesi, Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü, İstanbul, 2001, s. 80-81.

булда яшәгән Хәйрулла әфәнде исемле кеше, Вакыфлар (дини оешмаларның мөлкәте) нәзарәтенә биргән гаризасында Фатих районындагы вафат булган Хәсән әфәндедән калган Хыркаи шәриф тирәсендәге йортның үзенә бирелүен сорый [36]. Күчеп килгән вакыты төгәл билгеле булмаса да, Госманлы дәүләте боерыгына керүе хәл ителгән булганлыктан, Истанбулга шактый электән килеп урнашуы ихтимал.

1865 елда язылган бер гариза чыгышы буенча Казан шәһәреннән булган гаилә белән бәйле. Гаилә башлыгы хаҗи Мөхәммәт Габделкәрим вафат булганнан соң, гаилә кешеләре аның 250 курушлык айлыгының үзләренә түләнүен сорап мөрәҗәгать иткәннәр [37].

Бу елларда Госманлы җирләрендә Идел-Уралның төрле төбәкләреннән килгән мөһаҗирләр яшәгән. Шундый төбәкләрнең берсе — Идел елгасы суларын Каспий диңгезенә койган җирләрдә урнашкан, шул ук вакытта сәүдә үзәге дә булган Әстерхан (Хаҗитархан) шәһәре. 1857 елга караган бер документта Әстерхан мөһаҗирләре булган, исемнәре белдерелмәгән ике кешегә гатия [38] бирелүе турында сүз бара [39]. Шулай ук Әстерхан кешесе булган Габдулла әфәнде дүрт кешелек гаиләсе белән бергә Истанбулга күчеп килгән. Дәүләттән матди ярдәм сорап язган үтенеч язуы җавапсыз калмаган, 1861 елда бу кешегә көнлек түләү турында карар чыгарылган [40].

Төркиядә яшәүче мөһаҗирләрнең туган җирләре белән элемтәләре өзелмәгән. Моның беренче сәбәбе бүлгәләнгән гаиләләрен яңадан берләштерү булса, икенчесе башка тугантумачаларын да яңа ватаннарына алдыру булган. Моңа үрнәк итеп ун гаилә исеменнән язылган бер гаризаны китерергә мөмкин. Төп чыгышлары Җәрифкә шәһәрчегеннән булган ун ир мөһаҗир Истанбулда «Әмирләр ханы» дигән кәрвансарайда яшәп ятуларын, Әстерханда 17 йорт булып яшәп калган гаиләләрен Төркиягә китерттертү өчен рөхсәт сорауларын белдереп язган уртак гаризага Йосыф Сөләйман дигән кеше кул куйган. Күчеп килүләренә рөхсәт соралган гаиләләрнең җидесе Җәрифкәдә, биш йорт Чёрный яр дигән районның Команлы авылында һәм биш йорт Бахтиярлифкәдә булуы турында рәсми оешмаларга мәгълүмат бирелгән [41].

Күчеп утырган гаиләләрнең туган җирләре, туганнары белән булган элемтәләрен дәвам итүләре аларга акча җибәреп торуларыннан да аңлашыла. Казанның Тәтеш өязе Урта Балтай волостенә кергән Кече Бакырчы авылының имамы мулла Гобәйдулла бине Хәмиднең улы Хәмидулла да Россиядә калган гаиләсенә акча җибәреп торган. Ләкин бик аз микъдарда булган бу акчаның энеләрен-сеңелләрен укытырга җитмәвен һәм ата-анасының да инде олы яшьтә булуын сәбәп итеп күрсәтеп, гаиләсен Истанбулга китертү өчен, Мөһаҗирләр комиссиясенә мөрәҗәгать иткән. Гаризасында гаиләсенең ун кешелек булуын

36. A. MKT. NZD., 232 / 49, 23. Zilhicce 1273 / 14.08.1857.

37. MVL., 872 / 36, 16 Cemaziyelevvel 1282 / 06.10.1865.

38. Иганә.

39. A. MKT. NZD., 248 / 15, 07 Cemaziyelevvel 1274 / 29.09.1857.

40. A. MKT. NZD., 368 / 59, 23. Rebiülevvel 1278 / 29.09.1861.

41. A. MKT. NZD., 398 / 21, 07 Şaban 1278 / 07.02.1862.

белдергән. Комиссия, казан татары Хәмидулланың бу үтенечен үтәп, тиешле рәсми эшләрне башкару максатыннан, гаризаны Харидҗия (тышкы эшләр) нәзарәтенә җибәргән [42].

42. A. MKT. NZD., 402 / 101, 24 Şaban 1278 / 24.02.1862.

КҮЧЕШЛӘРНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ

XVI гасырның икенче яртысы — XVIII йөзнең соңгы чирегендә Россия хакимиятенә кергән Урта Идел төбәкләрендә яшәгән мөселман халыкларның көчләп чукындырылуы, басым астында булулары уйдырма түгел — чынбарлык. Россия мөселманнарының ватаннарын ташлап китүгә этәргән сәбәпләрнең беренчесе дини һәм сәяси басым астында калулары була.

XIX гасырның беренче чирегендә, ягъни Николай I (1825-1855) заманында, илдәге мөселманнарга карата карарлар чыгарылган. Христианлыкны саклау юнәлешендә миссионерлык эшчәнлеге дәүләтнең мөһим вазифаларыннан берсе буларак кабул ителгән. 1842 елда миссионерлар хәзерләп чыгару өчен, Казан рухани академиясенең ачылуы, христианлыкка күчүчеләрне салымнардан азат итү карары, акчалата ярдәм кебек кызыктыргыч чаралар белән беррәттән, 1822 елда мөфтиләрдән башка бөтен дин әһелләренә карата аларны түбәнсетә торган таяк җәзасы карары чыгарыла һәм 1850 елга кадәр көчендә кала [43].

1860 елларга кадәр Рус хөкүмәте белән христиан чиркәүләре алып барган миссионерлык эшчәнлеге, алынган төрле идарә һәм гаскәри чараларга карамастан, рус булмаган халыкларны христианлаштыруда һәм руслаштыруда куелган максатларга ирешә алмый. Ислам динен бөтенләе белән контроль астына ала алмаган рус авторитетлары, XIX гасырның икенче яртысында бу юлы тагын да хәйләле һәм тәэсирлерәк ысул уйлап табалар. Бу мәсьәләдә аларга ярдәм иткән кеше тел белеме һәм дин белемнәре галиме Николай Ильминский була [44]. Аның тарафыннан алга сөрелгән, җирле халыкларга үз телләрендә белем бирү һәм рус әлифбасын бу телләргә кертү алымының җәмгыятьне христианлаштыруда уңышлы булачагы фаразлана. Чөнки рус әлифбасын һәр халыкка үз сөйләм аерымлыкларын калкытып яраклаштыру һәм бу үзенчәлекләр нигезендә басылачак китаплар ярдәме белән мөселман-төрки халыклары арасындагы якынлык, бердәмлек, үзара аралашу өзелергә тиеш була.

Мөселманнарга карата кабул ителгән тагын бер чара Инҗилне (Евангелие) һәм башка дини язмаларны башта татарчага, аннары башка төрки телләргә тәрҗемә итеп, эчтәлегенең аңлаешлылыгын тәэмин итү, аларны җәелдерү була. Ильминский, татарларның үзләренә карата кулланылган үзенчәлекле руслаштыру чараларына каршы торуларын, хәтта башка төрки халыкларны татарлаштыруларын белә иде. Шуңа күрә ул үзенең әлеге алымы кыргыз-казахларны татарлашудан саклап кала-

43. Aidar Nogmanov, «Relations Between State and Islam in the 18th. And 19th. Centuries»,, (haz. Halit Eren, Damir Ishaqov, Sadık Ünay), Tatar History and Civilisation, (çev. İlnur İ. Nadirov), Ircica yay., İstanbul, 2010, s. 233-236.

44. Николай Иванович Ильминский – (1821-1891) Пензада рухани гаиләсендә туа. Казан руханилар академиясен бетергән. Көнчыгыш телләренә булган зур кызыксынуы аны мәдрәсәдә укырга этәргән. Башта ул Казанда православие дине китапларын татарчага тәрҗемә итү белән

чак дигән фикердә тора иде. Сөйләшләрне, үзенчәлекләренә нигезләнеп, аерым төрки телләргә тәрҗемә итәргә тырышулар зур резонанс тудыра, хәтта төрки халыкларның үзләрендә дә яклау таба. Шулай итеп, рус язучыларының әсәрләрен төрле төрки сөйләшләргә тәрҗемә итү һәм бөтен төрки халыклар өчен аерым-аерым әдәби тел барлыкка китерү процессы башланып китә [45]. Ильминскийның методы, үзе яшәгән 1851-1891 еллар арасында гына түгел, үлеменнән соң да дәвам иткән, 1905 елга, хәтта 1917 ел революциясенә кадәр кулланылган [46].

Татарлар, хөкүмәт һәм православие чиркәве тарафыннан өзлексез һәм системалы рәвештә алып барылган сәясәткә каршы торып, ислам динендә калуларын дәвам итәләр. Рус дәүләте оешмалары ислам динен җәелдерүне катгый рәвештә тыйган булса да, татарлар башкорт, чирмеш һәм чуваш авылларына йогынты ясап, аларның ислам диненә кайтуларына сәбәп булалар. Эзләнүләрдән күренгәнчә, христианлаштырылган татарларның мөселманлыкка кире кайтулары XIX гасырның башыннан алып 1802-1803, 1827-1830, 1858-1870 еллар арасында һәм 1905 елда аеруча арта [47].

Санкт-Петербургтагы илчелектән Истанбулга тапшырылган Казан суд органнарында кайбер дәгъваларга караган мәгълүматлар мөселманнарның ул заманнардагы яшәү шартлары һәм хокукый яктан нәрсәләр өчен гаепләнүләре мәсьәләсенә беркадәр ачыклык кертә. 1867 елның 15 декабрендә чыккан суд карарында законнарга каршы килгән татарлар өчен шактый авыр җәзалар бирелгән: күзәтү астына алу, мәҗбүри хезмәт лагерьларена җибәрелү, Эчке эшләр министрлыгының раславы нигезендә Себергә сөрелү. Мәсәлән, Чистайга караган Никитино авылындагы бер төркем мөселман кешесе, хөкүмәттән рөхсәт сорамыйча, мәчет салуда гаепләнеп, акчалата штраф җәзасына тартылганнар.

1870 елның 27 февралендә Казан суд органнарында каралган 1417 номерлы дәгъва Зур Солабаш, Норма һәм Олы Битаман авылларында яшәгән татарлар белән бәйле. Бу кешеләр православие кабул иткән мөселманнарны диннән чыгарырга тырышуда гаепләнәләр. Чистай кешесе мулла Галим Сәмигулов ислам диненнән чыгуга каршы торучыларны теләкләрен аңлатып гариза язарга үгетләүдә гаепләнә. Шуңа өстәп, өендә ясалган тентү вакытында дини китаплар табылуы да күрсәтелгән. Миңлебай Хәлимовның гаебе исә — вафат булган кызын мөселман йолалары буенча күмүе, гарәп телендә дога укуы. Бәдретдин Миръянов һәм Сабит Сабитов ислам динендә калырга теләүчеләрдән имза җыюда һәм үзләренә кушылган рус исемнәреннән баш тартуда гаепләнәләр [48].

Казан губернаторының ярдәмчесе Розов 1866 елның июль аенда, янына Ильминскийны да алып, губернадагы мөселман диненә кире кайткан авылларны йөреп чыккан. Тикшерүне Югары Никитино авылыннан башлаган Розов үзенең отчётында

шөгыльләнүче бер комиссиядә эшли. 1854 елдан Казан руханилар академиясенең төрек һәм гарәп телләре кафедрасында эшли. 1858 елда Оренбургта чик буе комиссиясенә эшкә керә, төрки телләр буенча гыйльми тикшеренүләр башлый. 1862 елда кабат Казанга кайта һәм 1870 елга кадәр Казан руханилар академиясендә һәм Казан университетында укыта. 1872 елдан вафатына кадәр Казан укытучылар семинариясенең директоры.

45. Nadir Devlet, Rusya Türklerinin Milli Mücadele Tarihi (1905-1917), TTK. yay., Ankara, 1999, s.162.

46. Jean Saussay, «Ilminskij et la politique de Russification des Tatars (1865-1891)», C M R S, Juillet-Septembre 1967, p. 400-425.

47. Agnès Kefeli, «Une note sur le rôle des femmes Tatares converties au christianisme dans la réislamisation de la Moyenne-Volga au milieu du XIX e siècle», L'Islam de Russie, p. 65-71.

48. HR. TO., 551 / 2, 01.02.1872 (француз телендә).

мөселманнарның 1856 елда Галим Сәмигулов җитәкчелегендә турыдан-туры Санкт-Петербургка рәсми гариза җибәргән булуларын, әлеге гаризаның игътибарга алынмавына да карамастан, 1865 елда мәчет салып, бөтен авыллары белән шунда гыйбадәт кыла башлауларын терки. Мәчет 1866 елда халыкның каршы торуына карамастан яптырыла.

Казан губернаторы Скарятин 1866 елның 20 августында Эчке эшләр министрлыгына мөселманлыкка кире кайту мәсьәләләре турында язып җибәргән бер отчётында Казан өязе Олы Мәңгәр авылында булып үткән дингә кире кайту вакыйгалары турында яза. Биредәге христиан татарларның вафат булган кешеләрен православие ысулы буенча күмүдән баш тартулары һәм бу хакта рәсми язма рәвештә хәбәр бирүләре белдерелә [49].

Мәккәдәге Казан мөселманнары, бу авылда булып узган вакыйгалар турында шикаять хатын гариза рәвешендә язып, падишаһ һәм хәлифә Габделхәмид II гә җибәргәннәр. Бу вакыйгалардан соң 1878 елда Казан губернаторы авыл старосталары аша мөселман авылларына белдерү тарата. Белдерүдә җиде яшен тутырган балаларның рус мәктәпләренә укырга җибәреләчәге, каршы килгән ата-аналарның җәзага тартылачагы хәбәр ителә. Моннан тыш чиркәүләрне төзекләндерү һәм тәртиптә тоту эшләренең мөселманнарга йөкләнәчәге, һәр авылда манара кебек биек урыннарга чаң эленәчәге дә белдерелә. Бу чараларга гаризалар язып каршылык күрсәтүчеләр исә таяк, төрмә һәм сөрген җәзалары белән куркытылалар. Казан губернаторы министрлыкның әмере белән гаскәр китертеп, карарларга каршы килгән кешеләрне күсәкләр белән кыйната. Казан өязенең Мәңгәр авылына кереп, хаҗи Шакир исемле 90 яшьлек картны, киемнәрен салдырып, халыкка гыйбрәт булсын дип, камчы белән суктыра. Аягы белән башына типкәләп: «Менә, Мөхәммәтнең башына тибәм!» — дип каһәрли [50].

49. Gökgöz, Saime Selenga, Yevfimiy Aleksandroviç Malov: İdil-Ural'da İslâm Karşıtı Rus Misyon Siyseti, Köksav yay., Ankara, 2007, s. 403-404.

50. Y. Müt. Mar. Ev.57 / 50, 19. Ca. 1309 / 21.12.1891 (документ гарәп телендә).

КҮМӘК КҮЧЕНҮЛӘР ҺӘМ АНАДУЛЫГА (ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕНЕҢ АЗИЯ ӨЛЕШЕНДӘГЕ (ГАДӘТТӘ, КЕЧЕ АЗИЯДӘГЕ) ҖИРЛӘРЕ) УРНАШТЫРЫЛГАН ХАЛЫКЛАР

XIX гасырның икенче яртысыннан алып башта Кавказ, ә аннан Төркстан ханлыклары берәм-берәм рус хакимиятенең кулына төшә. Бу вакыйгалардан соң Идел-Урал төбәкләрендә яшәгән рус булмаган халыкларга, казан татарлары, башкортлар һәм чувашларга карата кабат системалы ассимиляцияләү алымнары кулланыла башлый. Мөселманнар бик көчле христианлаштыруга дучар ителсәләр дә, бу басымнар рус хөкүмәте максат итеп куйган нәтиҗәләрне бирми, хәтта, киресенчә, каршы торуны ныгыта [51].

Бу чорда Анадулыга Идел-Уралдан килүче мөһаҗирләрнең саны тагын да арта. Күчешләрнең башкаларыннан аермасы һәм

51. Akdes Nimet Kurat, Rusya Tarihi, TTK yay., Ankara, 1993, 359-361.

уйландыра торган ягы мөһаҗирләрне биргән ил белән аларны кабул иткән ил арасындагы араның үтә дә ерак булуы, климат шартларының юл мәшәкатьләрен тагын да кыенлаштыруы иде.

Мәгълүм булганча, мондый күчешләр вакытында туйганчы ашый алмау, йогышлы авырулар һәм юл газаплары үлемнәргә сәбәп булган. Төркем-төркем мөһаҗирләрне кабул иткән Госманлы дәүләте сәламәтлеккә бәйле мәсьәләләрне кайгыртырга тиешле булган оешмалар кора башлый. Мәсәлән, карантин ысулы 1838 елда мәҗлес оештырылу белән рәсми төс ала. Аеруча порт һәм яр буйларында сәламәтлек саклауда әлеге оешма беренче дәрәҗәдә җаваплылыкка ия була [52].

Мөһаҗирләр Анадулыдагы яшәү урыннарына таратылганчы Истанбулда җыела торган булганнар. Аннан соң, барып урнашу җайлы булган шәһәр һәм авылларга җибәрелеп, җир бүлеп бирелгән, мөмкин очракта иген кырлары белән тәэмин ителгәннәр. Араларында үзләреннән алдарак килеп урнашкан туганнары янында төпләнү теләге белдерүчеләр дә булган, андый үтенечләр дә кире кагылмаган. Моңа үрнәк итеп Казан мөһаҗире һәм дин әһеле хаҗи Мөхәммәт исемле кешене атарга мөмкин. Олылардан дүрт кеше һәм балалардан торган гаиләсе белән Истанбулда яшәгән бу кеше хәерчелеккә төшүен, бу хәлдән котылу өчен, Кютахъяга бәйле Иске Шәһәрдәге туганнары янына китәргә теләвен белдергән [53]. Иске Шәһәрнең тимер юл буйларына урнаштырылган мондый гаиләләр биредә игенчелекнең алга китүенә дә этәргеч биргән. [54].

Чыгышлары буенча Казаннан булган Мөхәммәт һәм Габделгани исемле ике кеше, үзләре белән туган-тумачаларын (22 кеше) да алып, Төркиягә килгән. Болар үзләреннән алда күчеп киткән туганнары янына — Бурсага караган Яманлы дигән җиргә һәм Измиткә караган Чанаксуе Мәшәкүендәге Искемазар дигән җиргә җибәрелүләрен сораганнар. Әлеге җирләр әлеге төркемнәр барып төпләнү өчен яраклы дип табылган [55].

Бу җәһәттән, Ходавәндигяр вилаяте мөһаҗирләрне урнаштырыр өчен уңайлы җир булганлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Беренчеләрдән булып күчеп килгән Казан мөһаҗирләрен Ходавәндигярга урнаштырганнар. Биредә мөһаҗирләрнең туган-тумачалары белән бергә яшәр өчен белдерелгән теләкләре идарәчеләр тарафыннан игътибарга алынганлыгы архив документларыннан аңлашыла. Казан татарларының монда кардәшырулары яшәве күчешләрнең элек тә булганлыгына ишарә итә.

1866 елда Казан мөһаҗирләреннән 18 кешелек 4 гаиләнең Ходавәндигяр вилаятенең Тәпәҗик авылындагы туганнары янына урнаштырылачаклары, бу кешеләрнең паспортлары булганлыгы белдерелгән тагын бер документ табылды [56]. Моннан да күренгәнчә, араларында күчеп китү өчен, Россиядә рәсми документлар эшләтүчеләр, ягъни качак булмаганнар да очрый. Госманлы җирләренә килеп урнашкан 18 гаиләлек Ка-

52. Gülden Sarıyıldız, Hicaz Karantina Teşkilatı (1865-1914), TTK yay., Ankara, 1996, s. 7.

53. MVL., 511 / 92, 26 Cemaziyelahir 1283 / 04.11.1866.

54. Kemal H. Karpat, Osmanlı Nüfusu Demografik ve Sosyal Özellikleri (1830-1914), (çev. Bahar Tırnakçı), Tarih Vakfı Yurt yay., İstanbul, 2003, s. 49.

55. MVL., 721 / 88, 11 S 1283 / 24.06.1866.

56. MVL., 738 / 6, 13 Rebiülevvel 1284 / 15.07.1867.

зан мөһаҗирләрен Кырым һәм Дагыстан мөһаҗирләре белән бергә урнаштырырга дигән тагын бер карар кабул ителгәнлеге билгеле [57].

11 гаиләдән оешкан һәм барлыгы 40 кешелек төркем Казан кешеләрен Худавәндигяр вилаятенә кергән Михалич һәм Тәпәҗик дигән җирләргә урнаштырырга дигән карар чыгарылган. Боларның да туганнары янына төпләнергә теләүләре, паспортлары барлыгы белдерелгән [58].

Измиткә караган Элмалы (Алмалы) авылы тирәсендә 42 йорт булып урнашкан Казан мөһаҗирләре исеменнән бирелгән бер гаризадан аларның авыр шартларда яшәүләре аңлашыла. Мокатдәретдин исемле вәкилләре белдергәнчә, бу авыл кешеләре, инде ике елдан бирле чәчү орлыгы юнәтә алмыйча, үзләренә җитәрлек чәчү орлыгы бирелүен үтенеп дәүләткә мөрәҗәгать иткәннәр [59]. Тагын бер документта Казан мөһаҗирләреннән булган 7 йортлык бер төркемгә шул ук Измиттә җир бирелү хәбәрен очратабыз. Бу җир сайланганда, анда туганнарының яшәве исәпкә алынган [60]. Әлеге төбәкләрдә яшәгән халыкның берничә елдан бирле чәчү орлыгына ихтыяҗ тоюлары тагын бер документта белдерелә. Элмалы авылында яшәгән Казан кешесе хаҗи Габделгазиз үзенә башка якташларына караганда азрак бодай бирелүе турында шикаять язган [61].

57. MVL., 875 / 13, 18 Rebiülevvel 1283 / 31.07.1866.

58. MVL., 726 / 53, 01 Safer 1283 / 14.06.1866.

59. MVL., 528 / 58, 14 Zilkade 1283 / 21.03.1867.

60. MVL., 738 / 22, 19 Rebiülahir 1284 / 20.08.1867 (әлеге документны тикшерергә кирәк булганлыктан, оригиналы күрсәтелми).

61. MVL., 713 / 103, 24 Zilhicce 1282 / 09.05.1866.

ХИҖАЗ ҺӘМ ШАМДӘ (ДӘМӘШКЪ) ЯШӘГӘН ИДЕЛ-УРАЛ КЕШЕЛӘРЕ, АЛАРНЫҢ СУФИЧЫЛЫККА БУЛГАН БӘЙЛЕЛЕГЕ

Мөселманнар өчен изге саналган Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре, Явыз Солтан Сәлим (1512-1520) заманыннан башлап Госманлы хакимиятенә керә. Шул рәвешле, падишаһлар хәлифәлектән тыш «хәдимел-хәрәмәйн» (Хәрәмәйнгә хезмәт итүче; Харәмәйн дип Мәккә белән Мәдинә шәһәрләренә әйтелгән — тәрҗемәче искәрмәсе) титулына да ия булалар. Бу исем изге шәһәрләрне карап, халкын тыныч һәм мул тормыш белән тәэмин итеп тору җаваплылыгын өстәгән. Һәр елны хаҗ вакытында алтын, бүләк һәм ризык төяп, башкала һәм хәлифәт мәркәзе Истанбулдан Хиҗазга таба кәрваннар юлга чыга торган булган. 1782 елда Үскүдардагы солтанатның хәзинә сараена казан татарларыннан 26 кешенең китерелүе, матди тәэмин ителүләренә бәйле күрсәтмә XVIII гасырның ахырында Идел-Урал белән булган бәйләнешләрнең көчле булуын дәлилли [62].

Хаҗга барып кайту башлыча берничә елга сузыла торган булган, хәтта араларында төпләнеп калып, кире кайтмаганнары да очраган. Мәсәлән, Уфа төбәгендә мәдрәсә ачып, бик күп шәкертләргә сабак биргән мөдәррис Габделхаликъ бине Габделкәрим (1844 елда үлгән), Казанда белем алганнан соң, 1798 елда Истанбул аша Хиҗазга барган. Аннан соңгы елларда

62. C. DH., 326 / 16268, 29 Şaban 1196 / 09.08.1782.

да хаж сәфәренә чыккан Габделхаликъ бине Габделкәрим ике ел Мәккә белән Мәдинәдә, берәр ел Мисыр (Мисыр иле яки аның башкаласы Каһирә) белән Кодыста (Иерусалим), алты ай Шамда (Сурия яки аның башкаласы Димәшекъ) яшәгән [63].

1818 елда Казан дин галимнәреннән Габделкәрим әфәндегә билгеләнгән акчаны 180 курушка күтәрергә дигән күрсәтмә теркәлгән тагын бер документ белән таныштык [64]. Габделкәрим әфәнденең бераздан бу билгеләнгән акчаны тулаем алу өчен мөрәҗәгать иткән язуы да бар [65]. Ул заманнарда казан татарлары арасында Габделкәрим исеменең бик еш очравы күзгә ташлана. Фамилияләрнең кулланылмавы, мәгълүматларның да шактый чикле булуы сәбәпле, бу кешеләрнең шәхесен төгәл билгеләү мөмкин түгел.

Дәүләт, кирәк дип тапканда, хаҗга баручыларга ярдәм иткәнгә, хаҗ кылучылар да гозерләре белән мөрәҗәгать иткәннәр. Казаннан юлга чыгып, Хиҗазга барырга ниятләгән Мортаза исемле бер кеше, Искәндәриягә (Александрия) кадәр пароходта бушлай бару өчен гариза язган [66]. Мәккәдә мөҗавир [67] булган Казан мөһаҗире Демирполат исемле кеше азык-төлек, ягъни бодай бирелүен үтенеп мөрәҗәгать иткән. Үзе турында биргән мәгълүматта Һиҗри белән 1267 елда Казаннан гаиләсе, бала-чагасы белән бергә китүен, Мәккәдә мөҗавир булып торуын белдергән. Үзе генә Истанбулга барып кайтуын, ул югында ярдәм ризыгы таратылганга, гаиләсе өлешсез калып, юклыкка, хәерчелеккә төшүләрен белдерә [68].

Татарлар сәүдә эшчәнлеге өчен мәйданнарын Урта Азиягә күчергәннән соң, андагы мәдрәсәләр һәм фикер ияләре белән танышалар, дини һәм мәдәни бәйләнешләргә нигез салалар. Бу төбәктә барлыкка килгән тарикатьләрнең йогынтысына да биреләләр. Аеруча Бохарада булучыларның XVI гасырда оешкан Нәкышибәнди [69] тарикатенә керүләре һәм Идел-Уралда да нәкъ менә бу тарикатьнең җәелүен билгеләргә мөмкин. Гомумән, Оренбург Мөселман Диния нәзарәте тарафыннан алга сөрелгән рәсми ислам фикерендә дә нәкъшибәндиләр карашы хакимлек иткән [70].

XIX гасырның икенче яртысыннан алып руслар сәүдә юлларын һәм мәйданнарын үз кулларына төшергәннән соң, татар сәүдәгәрләренә Урта Азия капкалары бикләнгән. Икенче яктан, нәкъ бу елларда Госманлының башкаласы Истанбул һәм Каһирә кебек башка изге шәһәрләр белән бәйләнешләр ныгыган. Россия мөселманнары һәм хаҗилары Истанбулдагы нәкъшибәнди тәккәләренә бик еш килә торган булганнар. Шәһәрдәге тәккә, һанкяһ, завия, дәргяһ кебек дәрвиш гыйбадәтханәләре Әмир Бохари, Габдуллаһ Кашгари кебек Урта Азия дәрвишләренең исемнәре белән дә аталып йөртелгән. Урта Азия нәкъшибәндилеге бирегә үзбәк тәккәләре ярдәмендә күчә. Өскедар Солтантәпәдәге Үзбәкләр тәккәсе, Солтанәхмәттәге

63. Rızaeddin bin Fahreddin, Asar, C. II, cüz.10, Orenburg,1907, s. 96-99.

64. C. MF., 38 / 1882, 28 Cemaziyelevvel 1233 / 05.04.1818.

65. C. DH., 340 / 16997, 27 Rebiülevvel 1239 / 01.12.1823.

66. A. MKT. NZD., 377 / 32, 05 Cemaziyelevvel 1278 / 09.11.1861.

67. Йотрын-җирен калдырып, Мәккә һәм Мәдинәдә гыйбадәт кылып яшәүче.

68. A. DVN., 159 / 67, 14 Cemaziyelahir 1277 / 28.12.1860.

69. XIV гасырда барлыкка килгән бу тарикатьнең оештыручысы Мөхәммәт Баһаведдин Нәкъшибәнд була. 1388 елда Бохарада вафат булган Баһаведдин Нәкъшибәнднең кабере дә билгеле.

70. Alexandre Bennigsen-Chantal Lemercier-Quelquejay, Sûfi ve Komiser, çev. Osman Türer, Akçağ yay., İstanbul, 1988, s. 122-123.

Бохара тәккәсе, Үзбәк һәм Шаһ Хәйдәр Ташкәнди тәккәләре моңа мисал булып тора [71].

Бу тәккәләр бер үк вакытта Төркстан һәм Кытайдан килгән хаҗиларның Истанбулда туктау һәм яшәү урыннары да булган. Мәсәлән, бохаралылар һәм кашгарлылар Мәхмүтпашадагы Үзбәк тәккәсендә һәм Әюп Солтан тәккәсендә куна кала торган булганнар. Казанлы хаҗилар исә күбесенчә казанлылар тәккәсендә тукталганнар.

XIX гасырда Мәккә һәм Мәдинә кебек изге шәһәрләрдә, Шамда яшәгән казан татарларының саны шактый булганлыгын күрәбез. Болар арасында казанлы, нәкъшибәнди тарикатеннән шәех Хафиз Мөхәммәтҗан исемле кеше 1847 елда Мәккәдә бер тәккә [72] салдыра. Дәүләт тәккәнең чыгымнары өчен акча, бу шәхеснең үзенә хезмәт хакы билгеләп ярдәм итә. Шул ук документта аның Мәдинәи мөнәввәрәдә мөҗавир булып торганлыгы да белдерелә [73]. Казанлы шәех Хафиз Мөхәммәтҗан әфәнденең шул ук вакытларда Истанбулда яшәгән якташы Гыйззәт исемле ярдәмчесе, эшләренең дәвамчысы да булганлыгы аңлашыла [74].

Хафиз Мөхәммәтҗан әфәнде, аннан соңгы елларда Мәккәгә мөҗавир булып китәчәген әйтеп, яңадан хезмәт хакы билгеләнүен сорап мөрәҗәгать иткән [75]. Хафиз Мөхәммәтҗанның Мәккә һәм Мәдинәдән соң Шамда яшәгәнлеген күрсәтүче тагын бер документ бар. Шам вәлилегенә (губернаторлыкка) аның исеменнән гариза биргән кеше — Габдеррахман исемле югары дини белем алучы бер шәкерт [76].

Башка бер документтан казан татары һәм нәкъшибәнди дәрвише булуын белдергән Хөсәен исемле кешенең, хатыны белән бергә юлга чыкканлыгы һәм Хиҗазга барырга теләве аңлашыла. Искәндәрия (Александрия) юлы аша барырга ниятләгән бу кешенең юл чыгымнарын күтәрүләрен үтенеп язган гаризасына уңай җавап бирелгән [77].

1852 елга караган бер документта исә Мәдинә шәһәрендәге Казан кешесе хаҗи Мөхәммәт Сафа, шәкерт Габдеррәхим әфәнде һәм Шам шәһәрендәге Хәмзәзадә Сәет Хөсәен әфәнделәргә бер микъдар акча түләүне билгеләү турында сүз бара [78].

Бу кешеләрнең изге җирләргә тартылуларының сәбәбен дини инанулары белән аңлатырга мөмкин. Шиһабетдин Мәрҗани заманында, Россиядә ислам әһелләренең тәрәккыяте (прогрессы) мөмкин булмаячак, шуңа күрә Төркиягә күчеп китүләре кирәк, дигән фикер бик киң җәелгән була. Ул вакытларда Казанның иң мәшһүр мөдәррисләренең берсе булган Мөхәммәт Габделкәрим хәзрәт [79] һәм башка бик күпләр нәкъ менә шул сәбәп белән күчеп китәләр. Ләкин Мәрҗани бу фикерне хупламаган. Ул, тиешле реформалар үткәрелгән очракта Россия мөселманнарының алга китеше мөмкин дигән карашта торган [80].

Бу чорда Габделкәрим әфәнде исемле бер кешенең җиде

71. Thierry. Zarcone, «Les Derviches Turkestanais et Indiens à Istanbul», Anatolia Moderna, II, 1991, s. 136-200.

72. Мәдинәдә казанлылар өчен аерым бер тәккә булган кебек, Мәдинәи мөнәввәрәдә дә Карабаш тирәләрендә Үзбәк тәккәсе корылган. Бу тәккәнең булуын, аны төзеткән Габделгаффур әфәнденең балавыз шәме сорап язган язмасыннан укып белергә мөмкин. Тулырак мәгълүмат алу өчен карагыз: www.actaturcica.com/sayi5/III_1a_5.pdf

73. A. MKT. DV., 59 / 72, 02.09. 1268 / 20.06.1852.

74. A. MKT. NZD., 24 / 54, 15 Rebiülevvel 1267 / 18.01.1851.

75. A.MKT. UM., 432 /11, 29. Rebiülevvel 1277 / 15.10.1860.

76. A. MKT. DV., 185 / 37, 14 Ramazan 1277 / 27.03.1861.

77. ZB., 3 / 68, 11 Receb 1287 / 06.10.1870.

78. A. MKT. DV., 59 / 72, 02 Ramazan 1268 / 20.06.1852.

кешелек гаиләсе белән Россиядән күчеп килүе, үзенә тúләү билгеләнүен сорап, дәүләт оешмасына мөрәҗәгать итүе теркәлгән тагын бер документ бар. Бу кешенең нияте Мәдинәгә барып төпләнү, ул мөмкин булмаса, Шамда торып калу була. Рәсми оешмалар тарафыннан тикшерү үткәрелгәннән соң, гаризасын кире кагу өчен җирлек булмавы белдерелә, 1863 елның 10 октябрендә үтенечен канәгатьләндерергә дигән карар чыгарыла [81]. Безнең фикеребезчә, бу кешенең алда искә алынган Габделкәрим хәзрәт булуы да мөмкин.

1897 елда хаҗ юлчылыгы вакытында Истанбулда тукталган имам Корбангали Халит угылы үзенең истәлекләрендә Казан кешесе мулла Мөхәммәт Кәрим хәзрәтнең вафат булуы турында яза, каберенә баруын белдерә. Каберенең Әдернәкапы тирәләрендә икәнен дә әйтә [82].

Идел-Урал җирлегеннән килгән һәм Хуҗа мулла Муса җитәкчелегендә тагын бер төркем мөһаҗир Шамга урнашу өчен гариза биргән. Алты йорттан 27 кеше булып оешкан бу төркем, «диннәрен саклап калу» максаты белән, туган-үскән җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булуларын белдергән. Шам һәм Сайда вәлиләренә бу кешеләр Госманлы боерыгы астына алынганнан соң, урнашачак җирләренә исән-сау барып җитүләрен тәэмин итү өчен, яннарына озатучы жандармнар бирергә кушылган [83].

Казан татарлары аеруча хаҗ юлы өстендәге борынгы мәдәният мәркәзе булган Шам вилаятендә төпләнеп калырга теләгәннәр. Идел-Уралдан килгән мөһаҗирләрнең бу җирләргә омтылуларының сәбәбе, безнең фикеребезчә, нәкъшибәндилектәге халидия [84] тармагының Сүриядә оешкан булуы иде.

Халидия тармагын казан татарлары арасында таныту өчен хезмәт куйган кешеләрнең булуы билгеле. Боларның берсе — Чистай мәдрәсәсен ачкан Закир Камалов [85]. Гарәп дөньясында халидия иң таралган ил — Сүрия булуы мәгълүм. Тарикатьнең Шамда тамыр җибәрүендә мәшһүр Хани гаиләсенең өлеше зур булган, тарикатьнең төп китаплары да бу гаилә кешеләре тарафыннан язылган [86].

XIX гасырның ахыры һәм XX гасырның башларында Истанбул, Мәккә белән Мәдинә һәм Шам кебек шәһәрләрдә төпләнеп калган казан татарлары белән беррәттән, Кавказның җирле халыклары, бигрәк тә Дагыстан кешеләре очрый. Моны Дагыстандагы ислам традицияләренең көчле булуы белән аңлатырга мөмкин. 1850 елда Дагыстан мөфтиенең уллары — Шамга, кайбер дин әһелләре исә Хиҗазга килеп урнашалар [87]. Дагысланлы нәкъшибәнди шәехләре Госманлы дәүләте шәһәрләренә бик еш килеп китә торган булганнар [88].

Бу еллар Дагыстан һәм Кавказ тарихында бик үзенчәлекле дәвер иде. Кавказда шәех Шамил һәм аның дуслары рус көчләренә күп еллар дәвамында каршылык күрсәтәләр, нәтиҗәдә, 1859 елда җиңелергә мәҗбүр булалар. Рус басып

79. Дамулла Габделкәрим хәзрәт Буби мәдрәсәсендә дәрес биргән. Мөхәммәт Габделкәрим Бохарада укып кайтканнан соң егерме өч ел эчендә биш йөзгә якын шәкерт укытып чыгарган хөрмәтле шәхес булган.

80. Mercani, s. 534.

81. İrade Meclis-i Vâlâ, 22341, 24 Rebiülahir 1280 / 10 Ekim 1863.

82. İmam Kurbanali Halidoğlu, Tevârih-i Hemse-i Şarkî, Kazan, Ye. V. Kazakova matb., 1911, s. 570.

83. A. MKT. MHM., 230 / 87, 5 Safer 1278 / 12.08.1861.

84. Баһаведдин Нәкъшибәнд (1318-1389) тарафыннан оештырылган тарикать, Әхмәт Ясәви аша Мавераүннәһердә, Габделхаликъ аша Харәзмдә тарала. XV гасырда Анадулыда, XVI гасырда Һиндстанда тәэсире көчәя. Бу тарикать Һиндстаннан Мүҗәддидия исеме белән Хиҗазда, Гыйракъта һәм Сүриядә тарала. Сүриядә тарикатьнең халидия тармагы оеша.

85. Arzu Kılınç, «XIX. Yüzyılda İdil-Ural Bölgesinden Anadolu'ya Göçler», Türkler, C. 13, s. 899, Ankara, 2002.

алуларына бәйле рәвештә, Кавказдан саннары миллионнарга җиткән мөһаҗирләр, әченә Балкан да кергән Госманлы җирләренә килеп урнашканнар. Шәех Шамил руслар тарафыннан әсир алынганнан соң, хаҗ вазифасын үтәү мөмкинлеге бирелүен сорый. 1869 елда Хиҗазга китә, кире кайтмый һәм Мәдинәдә вафат була.

Татарларның Дагыстан халыклары белән элемтәләренең башлангычы, Казан руслар тарафыннан алынганнан соң, татарларның Дагыстанга мөһаҗирлек белән бәйле ерак тарихка барып тоташа. Татарлар арасында ул җирләргә китеп белем алучылар да билгеле. Шул чорларда Дагыстанга күчеп китүчеләр булганлыгы, Казанда хәлләр бераз яхшыргач, бер өлешенең илләренә, кардәш-ыруы янына кире кайтканлыгы мәгълүм. Идел-Урал төбәкләрендә сакланган кайбер кульязмалар, рисаләләр һәм Дагыстан дин галимнәренең әсәрләре, бу төбәкләр арасындагы элемтәләр һәм мәдәни багланышлар белән аңлатыла ала [89].

Йомгаклап әйтсәк, Идел-Уралдан килүче мөһаҗирләрнең социаль мохитләре бер-береннән шактый аерылып торса да, туган җирләрен калдырып китүләренең төп сәбәбе, нигездә, дини һәм икътисади хәлләре белән бәйле. Госманлы империясе, күпчелеге мөселман булган халкы һәм изге шәһәрләре күп булган дәүләт буларак, Россия мөселманнары өчен бик әһәмиятле ил иде. Шул ук вакытта уртак ноктаның бары тик дин генә түгеллеген, тарихи, этник һәм мәдәни тамырларның кардәшлеген дә игътибарсыз калдырырга ярамаганлыгын искәртеп үтү зарур.

Руслаштыру һәм христианлаштыру хәрәкәтенең Идел-Уралдан күчеп китүләргә көчле йогынты ясаганлыгы бәхәссез. Госманлы дәүләте белән XIX гасыр башыннан алып дәвам иткән дини багланышлар күчешләр өчен җирлек хәзерләгән. Соңга табарак Кырым һәм Кавказдан күчеп китүләрнең ишәюе дә Идел-Урал мөһаҗирләренең кыюлыгы артуга китергән.

XIX гасырдагы җиңелүләрдән соң, Грит һәм Румели кебек географик өлкәләрдәге Госманлы дәүләте боерыгы астында яшәгән халыкның Анадолуга таба чигенүе башланганда, патша Россиясеннән дә миллионнарча кеше ватаннарын ташлап китә башлый. Бу зур-зур төркемнәр Анадолуда яшәр өчен шартлары булган җирләргә урнаштырылалар. Зур кыенлыклар белән күчеп утырган мөһаҗирләр яңа ватаннарының чәчәк атуында, авыл хуҗалыгының алга китүендә үзләреннән өлеш кертәләр. XIX гасырның икенче яртысыннан соң арткан күчешләрнең башында казан татарлары Төркиянең көнбатышына, тимер юллар булган төбәкләргә урнаштырылган. Җитештерү түбән, авыл хуҗалыгы да артта калган елларда күчеп килеп урнашкан казан татарларына бүлеп бирелгән җирләр шактый дымлы һәм уңдырышлы булган.

Төрекчәдән Асия Рәхимова тәрҗемәсе.

86. Hamid Algar, «Halidiyye», TDVİA, C. 15, İstanbul, 1997, s. 296.

87. A. MKT. UM., 467 / 58, 13 Şevval 1277 / 24.06.1861.

88. A. MKT. UM., 343776, 09 Receb 1275 / 13.02.1859.

89. Ризаэддин Фәхреддинов. Болгар һәм Казан төрекләре. Казан, 1997, б.255.

ИСТАНБУЛГА СӘҮДӘ ИТҮ МАКСАТЫ БЕЛӘН ДИП КИЛГӘН БИШ КАЗАН ТАТАРЫНА КАРАТА НИНДИ МӨГАМӘЛӘ МУАФЫЙК БУЛАЧАГЫН БЕЛДЕРҮЕН СОРАП ПАДИШАҺ СЕКРЕТАРЕНЫҢ (?) ХӘРБИ ЭШЛӘР МИНИСТРЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ



1271 елның 15 җөмадәл-әүвәле = 1855 елның 22 гыйнваре (3 феврале)

Казан кешеләреннән булып, Бабе сәргаскәриләрендә[1] мосафир буларак торган Габдулла, кардәше Хәсән һәм өч иптәшләренең үзләренә сәүдә итү рөхсәте биргән таныклык бирүне сорап, падишаһ хәзрәтләренә язган гаризалары бу язмага кушылып, Сезгә[2] җибәрелде. Бу мәсьәлә хакында фикерегез сорала.

BOA, A. MKT. DV 78/51*

КАЗАНДА ТОРУЧЫ МӨХӘММӘДКӘРИМНЕҢ ҮЗЕНӘ ҺӘМ ГАИЛӘСЕ ӘГЪЗАЛАРЫНА ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕ ВАТАНДАШЛЫГЫ БИРЕЛҮЕН ҺӘМ АЛАРГА ИСТАНБУЛГА КҮЧЕНЕРГӘ РӨХСӘТ БИРЕЛҮЕН СОРАП ПАДИШАҺ ИСЕМЕНӘ ЯЗГАН ГАРИЗАСЫ



1275 елның 18 зөлхиҗҗәсе = 1859 елның 7 (19) июле

Ул![3]

Бер догачылары гаризасы

Бу догачылары әфәнделәремнең[4] күптәнге догачы колларыннан булып, Казан шәһәрендә Икенче таш мәчет мәхәлләсендә торабыз. Бүгенге көндә шунда шәригать белемнәрен өйрәнү белән мәшгульмен. Ләкин быел телгә алынган җирдә калыр хәлем бетте. Әфәнделәремнең кулы астында яшәргә, Дәүләте Галия тәбәгасе[5] булырга көчле хыялым һәм теләгем бар. Моннан элек догачылары гаиләмнең әгъзалары булган тугыз коллары белән Истанбулга күченү һәм хәзер торган урыныбыздан котылу өчен Хариҗиягә[6] бер гариза белән мөрәҗәгать иткән булсам да, мөрәҗәгатем тиешле тәртипкә каршы килә дигән җавап бирелде һәм андый гаризалар фәкать мәрхәмәтле әфәндем исеменә языларга тиеш икәнлеге ачыкланды. Утыз елдан артык тәхсыйль иткән гыйлемемә хөрмәт һәм яшемә

---

*BOA — Премьер-министр каршындагы Госманлы архивы.

[1]Бабе сәргаскәри — Госманлы дәүләтенең Хәрби эшләр министрлыгы (Истанбулда урнашкан булган).

[2]Сәргаскәр паша — Госманлы дәүләтенең Хәрби эшләр министры.

[3]Ул (гарәпчә «Һөвә») — Аллаһы тәгалә. Бу алмашлык Госманлы һәм кайбер башка мөселман дәүләтләрендә рәсми һәм рәсми булмаган кәгазьләрнең башында әгузе бисмилла урынына язылган.

[4]Әфәнделәремнең — Госманлы падишаһы күздә тотыла.

[5]Дәүләте Галия тәбәгасе — Госманлы дәүләте ватандашы.

[6]Хариҗия [нәзарәте] — Госманлы дәүләтенең Тышкы эшләр министрлыгы.

мәрхәмәт йөзеннән үзем һәм тугыз кешелек гаиләм Госманлы дәүләте ватандашлыгына кабул ителеп һәм гаиләмә Истанбулга күченеп килергә рөхсәт бирелеп, хәзер торган урыныбыздан котыла алсак, гомеремнең чырасын яңадан кабызу һәм үземне терелтү кебек булыр иде. Бу хакта карар чыгару исә хөкем иясе[7] ихтыярында.

Казанның үзендә Икенче таш мәчет мәхәлләсе, әл-хажҗ[8] Мөхәммәд-Кәрим догачылары

BOA, MVL 825/136

РУМЫНИЯДӘН КИТЕП, АНАДУЛЫДА МАНЪЯС КҮЛЕ БУЕНДАГЫ ҖИРГӘ КҮЧЕРЕЛГӘН КАЗАН ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕНЕҢ ҮЗЛӘРЕНӘ АЛАЧЫКЛАР ТӨЗЕР ӨЧЕН КҮЛДӘ ҮСКӘН КАМЫШНЫ САЛЫМ ТҮЛӘМИЧӘ ХӘЗЕРЛӘРГӘ РӨХСӘТ БИРҮНЕ СОРАП МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЛӘРЕ ТУРЫНДА МАЛИЯ НАЗЫЙРЫНЫҢ[9] САДРЕ ӘГЪЗАМГА (ПРЕМЬЕР-МИНИСТРГА) ГАРИЗАСЫ



1317 елның 2 мөхәррәме = 1899 елның 1 (13) мае

Ул!

Түбәнчелекле гариза

Румыниядән китеп Бандырма [шәһәре] янындагы Манъяс күле тирәсенә күчерелгән алтмыш бер өй Казан мөһаҗирләре вакытлы тору өчен төзисе алачыклар өчен Манъяс күленнән салым түләмичә, камыш җыярга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итте. Бандырма өязе мөдирлеге белдерүенчә, камыш йөкләнгән һәр арбадан бишәр гуруш[10] алынырга тиешлеген исәпкә алганда, салым рәвешендә алынасы акча 1830 гурушка җитә. Малия нәзарәтенең баш идарәсе Бандырма өязенең идарә мәҗлесенә камышның телгә алынган мөһаҗирләргә салым түләттермичә бирү мөмкинлеге хакында мөрәҗәгать иткәннән соң, идарә мәҗлесеннән телгә алынган салымның Дөюне гомумия идарәсе[11] тарафыннан җыелуы белдерелде. Шуңа күрә садре әгъзам[12] хәзрәтләренә бу аз микъдарда булган камыштан Дөюне гомумия идарәсенә түләнәсе салым акчасының бу юлы дәүләт казнасыннан түләнгәне очракта Бандырма өязе идарә мәҗлесе тарафыннан телгә алынган мөһаҗирләрдән бу салымны түләттермәве белдерелә һәм Малия нәзарәтенең малия мәҗлесе тарафыннан мәсьәләне алда әйтелгән рәвешчә хәл итәргә рөхсәт сорала.

Малия назыйры[13] (имза).

BOA, ŞD 382/2

Госманлы төрек теленнән кыскартылган тәрҗемә.
Башкарды Ильяс Мөстәкыймов.

---

[7]Ягъни, госманлы падишаһы.
[8]Әл-хажҗ — хаҗи.
[9]Малия назыйры — Госманлы дәүләтенең финанслар министры.
[10]Гуруш — Госманлы дәүләтендә акча берәмлеге.
[11]Дөюне гомумия идарәсе (Җәмгыять бурычлары идарәсе) — Госманлы дәүләтенең 1875 елда үзен банкрот дип игълан иткәннән соң, 1881 елда Аурупалы кредитор дәүләтләр тарафыннан төзелеп, Аурупа дәүләтләре вәкилләреннән торган оешма. Госманлы хөкүмәте тарафыннан бу оешмага Госманлы дәүләте бурычларын түләү бәрабәренә тоз, балык, ефәк, тәмәке, алкоголь эчемлекләрне һ.б. җитештерү һәм сатудан алынасы салымнарны җыю тапшырыла.
[12]Садре әгъзам — Госманлы дәүләтенең Премьер-министры.
[13]Малия назыйры — финанслар министры.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ

(15.08.1937)

ШИГЫРЬ ГЕНӘ...

Үзем теләп алдым шундый һөнәр,
хәзер дәрвиш кебек көн-төн барам.
— Шигырь генә миндә, кемгә кирәк?
Шигырь бирәм! — дип, мин хәбәр салам.
...Барган саен, сизеп, сөенәм әле:
барына да шигырь кирәк бугай.
Төннәрендә җиде ят җирләрнең
Качак якташ кешем килеп, чыга:
— Тавышыңны танып килдем, — ди ул.
—Шигырь генә миндә, шигырь бирәм!
Ул шигырьгә карап өен таба,
өй каршыннан аккан Иделен күрә...
...Еректан ук таныйм күңелләрне,
һәр күңелгә бирер шигырем бар.

Шигырь генә сузам юл сөйгәнгә —
каршысына тезелә тимер юллар.
Мин кыюлык итеп шигырь бирәм
Үзем шикеллерәк кыюсызга.
Кыш уртасы була — гашыйкларга
умырзая итеп шигырь сузам.
Көмеш язга чыгам, җәйгә җитәм,
кунак булып керәм ятлар өенә.
Яхшы кеше миңа урын бирер,
— Шигырь генә миндә, шигырь генә!
— Шигырь генә икән, и мескен, — дип,
яман кеше көлеп каршы ала.
...Мин аның да яман куенына,
салкын елан итеп, шигырь салам.

*Шагыйрь Рөстәм Мингалимнең кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

**Дамелла Галимҗан әл-Баруди.
Казан, 1906 ел**

ЮБИЛЕЙЛАРГА БАЙ 2012 ЕЛДА ТАТАРНЫҢ МӘШҺҮР ДИН ГАЛИМЕ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ФИЛОСОФ, РЕФОРМАТОР, МӘГЪРИФӘТЧЕ, МӨДӘРРИС, ДӘРЕСЛЕКЛӘР АВТОРЫ, МӨХӘРРИР ГАЛИМҖАН БАРУДИНЫҢ ДӨНЬЯГА КИЛҮЕНӘ — 155, Ә АНЫҢ ДАНЛЫКЛЫ «МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ОЕШУГА 130 ЕЛ ТУЛДЫ.

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ОЕШУГА 130 ЕЛ

ГАЛИМҖАН БАРУДИ ҺӘМ «МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

АЛЬТА МӘХМҮТОВА,
тарих фәннәре кандидаты

Кем соң ул шундый күпкырлы эшчәнлек иясе Галимҗан Баруди? Аның тәрҗемәи хәлен 1907 елда ук, остазларына илле яшь һәм эшчәнлегенә 25 ел тулу уңаеннан ике шәкерте нәшер иткән. Язмаларның беренчесе — ялкынлы шәкерт хәрәкәте җитәкчесе һәм журналист буларак танылып килә торган Фатих Әмирхан тарафыннан «Тәрбияи этфаль» журналында басылса [1], икенчесен күренекле җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура аерым китапчык итеп дөньяга чыгарган [2]. Язмаларның эчтәлегеннән тәрҗемәи хәлләрнең төп авторы Г.Баруди үзе булырга тиеш дип фаразларга була [3]. Бу мәкаләне дә шушы басмалар нигезендә кыскача биографик мәгълүматтан башлау дөрес булыр.

Галимҗан бине Мөхәммәтҗан бине Бинейәмин бине Гали бине Колмөхәммәд (Галиев әл-Баруди) 1857 елның февралендә Казан өязе

Кече Ковал авылында әнисенең әтисе Хәбибулла бине Мөхәммәтшәриф йортында дөньяга килгән. 1860 елда сәүдә эшләре белән мәшгуль әтисе Мөхәммәтҗан бине Бинейәмин гаиләсен Казан каласына күчергән.

Булачак галим беренче дәресләрен әнисе Бибифәхреннисадан алган: «Анам буш вакытларындамы, һәркөнме, ачык белмим, мине каршысына тезләндереп, янына идән себеркесеннән бер чыбык куйган хәлдә әлифба укытканы хәтеремдә бар. Чыбык берлә аркамны үлчәдеме, юкмы — искәрмим. Бу 1862 елларның башларында булгандыр...» [4]. Шул ук елның май аенда биш яшен яңа гына тутырган Галимҗанны Казанның икенче мәхәллә мәдрәсәсенә Нургали хәлфә карамагына укырга биргәннәр. «Галимҗан шәкерт мәдрәсәләребезнең күбесендә хәзергә кадәр дәвам иткән ысул белән укырга тотынды, әүвәлен язылып бирелгән бер әлифбаны танып өйрәнде. Кышын һәфтияк иҗегенә төште. Яз башына табан инде кечкенә сүрәләрне карап укый ала иде» [5], — дип тасвирлаган аның гыйлем ала башлавын Й.Акчура. Бер елда шундый белемгә ия булу баланың тырышлыгын да, зирәклеген, укуга сәләтен дә күрсәтә.

Шулай дүрт ел мәдрәсәнең ибтидаия (башлангыч) бүлегендә өйрәнелергә тиеш булган барлык сабакларны хәлфәсеннән уңышлы гына үзләштергәннән соң, тугыз яшьлек малай 1866 елда мәдрәсәнең рөшдия (урта) бүлегендә «заманның иң сәләтле вә зирәк голямасыннан булган», Бохараи шәрифтә белем алган мөдәррис Сәләхеддин хәзрәттән дәрес ала башлаган. «1866 елдан башлап дүрт ел дәвам иткән гарәп кагыйдәләрен өйрәнү вакытында ул заманның дәрес ысулларында булган бәгъзе авырлыклар миңа сизелә

башлаган иде, — дип искә алган ул бу вакытларны, — унынчы яшемдә булып, фарсы теленә һич ияләнмәгән яшь балага берьюлы кагыйдәсез, ысулсыз фарсы китабы укытмак вә аның нигезендә озын вә мөшкел игълял кагыйдәләре аңлатмак, вә ул кагыйдәләрне фарсы ярдәмендә хәтердә тотмак баш вата торган зарарлы бер ысулсызлык булганын аңлый идем һәм моннан рәнҗенә идем...»

«Мөхәммәдия» мөгаллимнәре, сулдан: 1 рәт – Адутов Якуб, Ильяси Таһир, Әҗем Гәрәй, Мостафин Әхмәтҗан, Галиев Габдрахман, Тәрҗеманов Кәшшафетдин, Хәнәфи Рәхим, Шәрәф Шәһәр, Кари Вәли; 2 рәт – Мостафин Әхкам, Уразаев Зәки, Солтанов Хәсән, Шакиров Закир, Нигъмәтуллин Сәлах, Биккенин Касыйм, ..., ...; 3 рәт – Гозәеров Мирза, Бәдигый Хуҗаәхмәт, ..., Борһан Хәбиб, ... Казан, 1910 еллар тирәсе

[6]. Галимҗан шәкерткә бу очракта фарсы телендә язылган гарәп грамматикасын ибтидаиядә өйрәнгәндә хәлфәсенең төркичәгә тәрҗемәләре ярдәмгә килгән: «Әгәр хәлфәм «Бидан» вә «Шәрхе Габдулла»дан әһәмиятле фикерләрне төркичәгә тәрҗемә кылып, язып укытмаса иде, бөтенләй белми калыр идем» [7], — дип ассызыклаган Галимҗан хәзрәт тәрҗемәи хәлендә.

1871 елда ул игъдадия (югары

«Мөхәммәдия» шәкертләре. Казан, якынча 1904 ел

белем алуга хәзерләү бүлеге) китапларын өйрәнүгә күчкән һәм үзе дә хәлфәлек итә башлаган. 1875 елда, остазы Сәлахеддин хәзрәт вафатыннан соң, сәләтле, зирәк, мәгълүмат эзләүче Галимҗан шәкерт, остазының киңәшен тотып, гыйлем эстәү өчен Бохараи шәрифкә юл алган. Бу вакытта «Галимҗан әфәндедә тәнкыйть вә яңарту фикере куәтле иде; Казанда гыйлем алган заманында ук яшәп килгән укыту ысулларының кимчелекләрен күреп, үзгәртү турында уйлый башлаган иде», — дип күрсәткән Й.Акчура. Һәм Г.Барудиның аңлатмасын китергән: «Тарих китаплары вә тәрҗемәи хәлләр байтак укуымнан дәрес программалары тугрысында шактый уйлана башлаган идем... Мәдрәсәләрдә үзем кебекләр белән сөйләшүләрдә күбрәк дәрес ысулы, гыйлем арттыру юллары сөйләшелә иде. Соңгы елларымда Шаһ Вәлиулла әд-Дәһләви кеби иҗат итүчеләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләрен вә бәгъзеләренең китапларын өйрәнү илә әйтелгән фәннәр өстенә риязият (математика) вә илаһият фәннәренә кызыксынуым арткан кеби, Коръән вә хәдис буенча вә Шәех ибне әл-Һәмам мәсләгенчә дин тануга кызыга башлаган идем» [8].

Укуның ләззәтен табып, бик бирелеп белем эстәү җиде ел гомер узуын сиздермәгән дә. «Бохарада җиде кыш кадәр тору вакытым дөньяда иң ләззәтле мәгыйшәтем, иң рәхәт хәятем иде; Бохара халкының, хосусан, шәкертләренең садә [самими] рәвештә мәгыйшәтләре, ниләр белән әдәпле булулары бөтен халык эчендә (гади халык, гаскәриләр, байлар) гыйлем вә гыйлем ияләренең иң кадерле күренүе мине бик хушландыра, дәрес вә гыйлем алуымда тырышлыгымны арттыра иде» [9], — дип искә алган бу чорны Г.Баруди. Ләкин ул мондагы кимчелекләрне дә күргән: «Бохарада мине ике мәсьәлә хәйран кылып, башымны күп вата, йөрәгемне яндыра иде: беренче мәсьәлә — ибтидаиядә керүче дәрес вә тәгълимдәге [уку-укы-

тудагы] кимчелекләр, икенчесе — гади халыкны вәгазь вә тәзкир [искәртү] берлә тәрбия юклыгы» [10]. Галимнең Бохара хатирәләреннән Й.Акчура чыгарган нәтиҗә: «Мөдәррисләр никадәр алдынгы булса булсын, шәкертләр никадәр тырышса тырышсын, укытылган дәресләр файдасыз булгач, бөтен бу тырышлыклар юкка китәдер, күп зирәклек, күп гомер, күп тырышлык, күп акча әрәм китәдер» [11].

1882 елның август урталарында Бохарада уку дәвамында илаһият белемнәреннән тыш хисап, алгебра, геометрия, медицина һәм табигыять гыйлемнәре белән танышкан 25 яшьлек Галимҗан Галиев Казанга кайткан. Шул ук елның 31 октябрендә (12 ноябрендә) ул бишенче мәхәллә мәчетендә икенче имам вазифасын башкаруга указ алган һәм шушы көннән башлап бер-ике шәкерткә дәрес бирергә керешкән. Акрынлап шәкертләр саны да арткан [12]. Бабасы Ибнейәминнең кушаматы булган «Баруди» сүзе озакламый яшь имамның хәтта фамилиясен дә алмаштырган псевдонимы булып киткән.

Ләкин шуны истә тотарга кирәк: «Мәдрәсәи Мөхәммәдияне» оештыру, аны гадәти мәдрәсәдән заманының иң алдынгы уку йортларына тиң белем учагына әйләндерү нindидер сихри көчләр ярдәмендә капылт кына дөньяга килгән эш түгел. Моның өчен мөдәррискә бар белемен, бар көчен түпларга туры килгән. Бу юлда исә беренче адымнар да, уңышлар, ялгышлар да булган, төрле каршылыкларны да җиңәргә туры килгән. Әдәбиятта исә мәдрәсәнең үсеше һәм мөдәрриснең үзендә барган үзгәрешләргә игътибар аз бирелгән. Гомумән, татар тарихында мөһим урын алып торган XIX гасыр азагы — XX гасыр башы вакыйгаларын без еш кына статик хәлдә бәялибез. Ягъни, җәмгыятьнең тотрыклы нигезләрен җимерүгә китергән бу чорның зур үзгәрешләр заманы булуын искә алмыйбыз һәм үзгәрешләр нәтиҗәсе булган бәяләмәләрне аларның башлангыч, беренчел адымнарына карата да кулланабыз. Мондый мөнәсәбәтне аерым шәхесләрнең карашларында да, татар җәмгыятендә XIX-XX гасырлар кисешендә барган вакыйга-күренешләргә карата да очратырга була. Бу фикерне Г.Баруди һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе хакында әйтү дә урынлы.

«Хәтер дәфтәре»ндә Г.Баруди мәдрәсәсенең оешуын, үзгәрешләр кертүен — ислах чорын 1882-1908 еллар белән билгеләгән [13], ягъни ислах чоры 25 елга сузылган. Бу чирек гасыр татар халкы тормышында бик үзенчәлекле, халыкның уяна башлау, хәрәкәткә килү еллары булган. XIX гасырның 80-90 нчы елларын XX гасырның башында киң җәелеп киткән милли яңарыш хәрәкәтенә идеологик хәзерлек чоры дип атарга була. «Җәдидчелек», «җәдид хәрәкәте» дигән исем гарәп телендәге «яңа, яңалык» мәгънәсендәге «җәдид» сүзеннән ясалган. Бу атамалар башта мәктәп-мәдрәсәләрдә барган үзгәрешләргә бәйле рәвештә генә кулланылган. Ләкин милли үзаң формалашкан шартларда, бу үзгәрешләр үзкыйммәтләргә, гореф-гадәтләргә дә, хәтта кешенең килеш-килбәтенә, төсбашына да үтеп керә башлаган чорда, «җәдид» атамасы татар тормышында күренгән бар яңалыкларга да күчкән.

Г.Баруди үзенең мәдрәсәсен булдырырга ниятләгән чорда, татар мәдрәсәләрендә гасырлар буена мөселман дөньясында формалашкан традицион схоластик укыту системасы булган. Яңа мәдрәсә дә шәкертләр тормышын оештыруда, укыту ысулларында башка Казан мәдрәсәләреннән аерылмаган. Фәкать яшь имам-мөдәррис үзенең

төпле белеме, энергиясе, чоры өчен киң карашлары белән башка мулла-мөдәррисләрдән шактый аерылып торган һәм Казан голямасының игътибарын җәлеп иткән. Әлбәттә, буыннан-буынга мулла нәселеннән чыккан, ләкин укымышлылыгы чамалы булган тәкәббер мулла-мөдәррисләр Г.Барудины үз сафларына алырга ашыкмаганнар. Бары тик үзенең хөр фикерлеге, яңалыкларны бик тиз күреп алуы белән аерылып торучы, ислам дөньясының мәшһүр галиме — дин белгече, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабеддин Мәрҗани (1818-1889) яшь хәзрәткә зур өметләр баглаган, аны үз канаты астына алган. Бу хакта, мәсәлән, Шәһәр Шәрәф язып алган күренешне китерергә мөмкин: «Бервакыт Мәрҗани өендә берничә кешедән гыйбарәт булган махсус мәҗлестә яңарак кына мулла булган дамелла Галимҗан әл-Барудины яратмыйча сөйләделәр: кайберләре «ул солдат малае» дип кимсеттеләр. Шулвакыт Мәрҗани: «Ул солдат малае булса да, Казанның һәммә имамнарыннан өстен. Аңар тел озайтмагыз. Ул өметле кеше, үзегез дә аңларсыз», — диде» [14].

1908 елда язган «Остаз Шиһабеддин әл-Мәрҗани» әсәрендә Г.Баруди галимгә карата үзенең мөнәсәбәтен тасвирлаган: «Мәрҗани хәзрәтләренең әсәрләрен «Нәзурәтел-хак» чыкканнан бирле [15] укып килдем. Имамлык һәм дәрес бирү хезмәтләрен укый башлаганымнан соң, үзенә алты ел кадәр дусларча мөнәсәбәттә тордым, сәфәрләрдә юлдашы булдым, гомуми һәм хосуси мәҗлесләрдә мәҗлестәше булдым, әңгәмәләренең күбесендә әңгәмәдәше һәм тыңлаучысы булдым. Шуның өчен эшләренең һәм холкының күбесен, күркәмлек һәм камиллеген күрдем. Аңа карата бер ядкәр, юксыну вакытында үземә бер юаныч булсын дип, бу язмада кыскача расладым» [16].

Г.Барудиның мәдрәсә оештыруы төрки-татар дөньясындагы зур әһәмияткә ия вакыйга — Исмәгыйль Гаспринскийның «Тәрҗеман» газетасын чыгара башлавы белән бер чорга туры килгән. Киң мәгърифәтчелек эшчәнлеген башлап җибәрергә уйлаган Исмәгыйль бәк 80нче еллар башында киңәшләшү һәм газета алучылар табу өчен Кырымнан Казанга килгән була. Беркемдә дә теләктәшлек тапмаган, гайрәте сүндерелә язган булачак мөхәррир, «Мәрҗани хәзрәтләренә кереп, шул турыда киңәшләшкән. Мәрҗани хәзрәтләре: «Әфәндем, сез исә бик мөһим вә тәрәккыятебез юлы булган эшкә турыдан-туры керештегез. Җәнабе Хак ярдәмчегез булсын, угыздан кайтмый тырышыгыз, ихтимал, киләчәге хәерле булыр», — дип, Исмәгыйль әфәндене уйлаган эшенә өнди вә кыздыра. [...] Исмәгыйль әфәнде: «Уйлаган нәрсәмә Казаннан әле киңәш бирүчене тапмаган идем. Мәрҗани хәзрәтләренә керүем белән, әлхәмде лилләһи, дәртемә дәрман табылды, үземә бер рух вә гайрәт керде», — дип, бик шатланып, кулларын селки-селки сөйләве вә олы кыяфәте бу көн һаман күз алдымда торадыр» [17], — дип искә алган бу вакыйганы Мәрҗани шәкерте Х.Үтәки.

Абруйлы галимнең фатихасын алган Исмәгыйль Гаспринский 1883 елда Бакчасарайда рус һәм төрки-татар телләрендә «Тәрҗеман» газетасын чыгара башлаган. «Телдә, фикердә, эштә берлек» шигарен алга сөрүче басма матбугат белән эш итәргә өйрәнмәгән татар җәмгыяте тарафыннан шактый авырлык белән кабул ителгән. Гыйльман ахун Кәримов, мәсәлән, үзенең «Тәрҗеман» белән танышуын болай тасвирлаган: «Бакчасарайлы мөхтәрәм Исмәгыйль мир-

за Гаспринский «Тәрҗеман» газетасы нәшеренә һәм билгеле булмаган Аурупа һәм Русия галәменә кечкенә генә булса да, бер тәрәзә ачып, мәдәният вә мәгариф ярдәмендә гасырлардан бирле капланып калган фикерләребезне ача башлады. «Милләтебез наданлык вә золмәттәдер, гыйлем вә мәгарифкә бик мохтаҗбыз, зыялыларыбыз вә галимнәребез, галәм әхваленнән, гыйлем вә мәгарифтән мәхрүм булып, рәхәтләнеп йоклыйлар. Мәктәп һәм мәдрәсәләребездәге укыту ысулларын яңарту кирәк», — һ.б. дип, яза башлады. Болар безгә ят тоелды, үземнең иске фикерләремнең хата икәнлеген тану авыр булды. Канымда һәм табигатемдә иске фикер булу сәбәпле, Гаспринскийның фикерләре минем өчен каршылыклы күренде, килешергә теләмәдем. Аның белән хат алыша башладык» [18].

Мөгаен, Галимҗан хәзрәт тә 1883-1884 елларда ук газета белән таныша башлагандыр. Бәлки ул да Гыйльман ахун кебек фикер йөрткәндер. Ләкин мәдрәсәдә үзгәрешләр кирәклеге хакында шәкерт елларында ук уйлый башлаган Г.Баруди Гаспринскийның Россия мөселманнары тормышында үзгәрешләрнең зарурилыгы һәм моның өчен мәктәпләрдә укытуны кулланырга тиешлеге турындагы фикерләрен уңай кабул иткәндер. Аның да мәсләге яшьләрне укыту һәм тәрбияләү өчен тиешле шартлар булдыру булган ич. Шулай да Бохара традицияләрендә тәрбияләнгән Г.Баруди өчен Гаспринскийның Аурупа фәне һәм тәҗрибәсен өйрәнүгә чакыруы ят тоелгандыр. Әлбәттә, бу хакта без фаразлый гына алабыз, ләкин яшь мөдәррискә Исмәгыйль бәк тәкъдимнәренә кушылу өчен 6-7 ел кирәк булуы бу фикерныраслый кебек.

80 нче елларда Галимҗан хәзрәт

Сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев. Г.Барудиның әтисе

укыту-тәрбия эшендә үз юлын эзләгән. Яшь мулла әтисе Мөхәммәтҗан бай тарафыннан һәрвакыт яклау тапкан. Яңа мәдрәсә аякка бассын өчен, аның үз бинасы булырга тиешлеген аңлаган бай, мәдрәсә салырга җир дә сатып алган. Мәдрәсә ныгыган, шәкертләр саны арткан саен биналарны да киңәйтергә, зурайтырга, яңаларны да салырга туры килгән. Әлбәттә, бу эшләрне башкарганда да, шәкертләр җыйганда да Галимҗан хәзрәткә төрле авырлыклар белән очрашырга туры килгән. Көн саен туып торган кыенлыклар хәзрәттән сайлаган юлның дөреслеген аңлау өчен мәгариф системасын оештыру тәҗрибәсен тирәнрәк өйрәнүне таләп иткән.

Мәдрәсәне оештыру эшләре ныклы нигезгә салынгач (шәкертләр җыелган, аларга уку һәм яшәү мөмкинлекләре җайланган — барысы да уңышлы гына барган кебек),

мөдәррис башкарган эшенә читкәрәк китеп карарга булган. 1886 елда Г.Баруди һәр мөселманның изге хыялы булган хаҗ сәфәренә чыгып киткән. Берничә айга сузылган хаҗ сәфәрендә ул Истанбул, Каһирә, Бәйрүт шәһәрләрендәге уку йортларында дәрес бирү ысуллары һәм мәдрәсәләрнең оештырылуы белән танышкан, төрле галимнәр белән очрашкан, киңәшкән, үзенең эшләгән эшләренә анализ да ясаган.

«Тәрҗеман» аркылы Россия мөселманнарының дөньяга карашларын уяту һәм яңартуны максат итеп куйган И.Гаспринский да бу вакытта шактый гына уңышларга ирешкән. Корреспондентлар челтәре барлыкка килгән, даими абунәчеләр саны да арткан. Газетадан Г.Кәрими һәм аның кебек зыялылар күп кенә яңа мәгълүмат тапкан. Аның сәхифәләрендә урын алган дөньядагы «иң яңа белемнәр» хакында да, бу белемнәрне таләп иткән заман һәм, гомумән, мәдәният бурычлары хакында да уйлангандыр алар. Газета үз укучыларын дөнья һәм Россиядәге вакыйгалар белән дә, ислам дөньясы яңалыклары белән дә даими таныштырып барган. Истанбулда һәм Каһирәдә ачылган дөньяви белем бирә торган махсус мәктәпләр һәм университетлар, ислам дөньясында дөнья күргән газета-журналлар хакында да язган газета, яңа әдәби җәмгыятьләр һәм яңа әдәбият та (төрек һәм гарәп телендә күренә башлаган «ауропа» романнары, французчадан тәрҗемәләр хәзерләнүе һ.б.) күз угында булган. Бу мөселман укучысы өчен ят, күнегелмәгән хәбәрләр шул ук вакытта үзгәрешләргә омтылган укымышлы муллаларны үзенә тартып торган.

Газета иске мәктәпләрне тәнкыйтьләгән. «Унбиш ел укытып та, дөрес яза һәм мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтә алмаган мәктәпләребез хакында нәрсә әйтергә мөмкин?» — кебек сораулар һәм мәдәниятле илләрдә балаларны алты айда укырга һәм язарга өйрәтүдән тыш хисаптан да башлангыч мәгълүмат бирә торган укыту ысуллары хакындагы мәгълүмат [19] Г.Баруди кебек укучыларны уйландырган, кичектерми эшкә тотынырга өндәгән. Аерым мәкаләләрдә мөселманнар өчен яңа булган аваз ысулының (ысуле җәдид) өстенлекләре күрсәтелгән. 1883-1884 елда ысуле җәдид нигезендә укытуны гамәлдә күрсәтү өчен И.Гаспринский махсус ачкан үрнәк мәктәп, бу ысулга өйрәтү өчен мәгърифәтче язган «Хуҗаи сыйбиян» (Балаларны укытучы) әлифбасы хакындагы язмалар да газетада күп урын алган. «Ысуле җәдиднең уңышлары шулкадәр ачык ки, мәктәпләрне ислах итү ысулны белүче мөгаллимнәр юклыкка гына бәйле» [20], — дип ассызыклаган газета һәм даими рәвештә яңа ысулга өйрәнергә теләүчеләрне Кырымга, Бакчасарайга үрнәк мәктәпкә килергә чакырулар урнаштырган.

Хаҗ сәфәреннән яңа фикерләр туплап, көч җыеп, күңел тынычлыгын табып иленә әйләнеп кайткан Г.Баруди эшен дәвам иткән. Казан уку-укыту округы мәгълүматы буенча 1887 елда мәдрәсәдә 54 шәкерт белем алган. Ягъни «Мөхәммәдия» исемен алган мәдрәсә Казан үлчәме буенча уртакул мәдрәсәләр рәтенә кергән (бары ике мәдрәсәдә генә укучылар саны артыграк булган — «Мәрҗания»дә — 142 һәм «Галләмия» — Күл буе мәдрәсәсендә 140 шәкерт укыган) [21]. Мәдрәсә каршында ир балалар өчен һәм Г.Барудиның хәләл җефете Маһруй абыстай кул астында аерым кыз балалар өчен башлангыч мәктәп тә эшләгән.

«Мәдрәсәдә, ачылган вакытта

башкалардагы кеби иске тарика (юл, алым) белән укытылса да, мөдәррис җәнапләренең тәҗрибәсе белән әүвәл голүме гарәбия вә диния дәресләре арттырылган. Вә аннан соң, мәктәп ислах ителмичә мәдрәсә ислахы мөмкин түгеллеге уйланылып, 1309 сәнәдә мәүледе Мөхәммәд (галәйһиәс-сәлам) көнендә ысулы җәдидә белән укытыла башламыштыр» [22]. Башлангыч мәктәптә укытуны үзгәртү кирәклегенә инанган мөдәррис үзенең бер шәкертен, чыгышы белән Чистай өязе Күлбай-Мораса авылыннан булган Җиһангир-хәлфә Зыятдиновны Бакчасарайга, Исмәгыйль бәкнең үрнәк мәктәбенә җәдид ысулын өйрәнергә юллаган.

Г.Барудиның бу адымга баруы хакында әдәбиятта аермалыклар бар. XX гасырның 60 нчы еллар азагында басылган беренче мәкаләләремдә, Шәһәр Шәрәфнең кулъязмасына таянып, «Мөхәммәдия»дә җәдид ысулы белән укыту 1889 елда башланган дип күрсәткән идем. Бу кулъязманың күчермәсен миңа Г.Барудиның энесе Салихҗанның улы Әхмәт ага Галеев биргән иде [23]. Соңрак Р.Әмирхан мәкаләләрендә һәм башка хезмәтләрдә «1891 ел» кулланышка керде. Бу дата һиҗридән миладига күчергәндә килеп чыга (1309+582 =1891). Һәм бу алым дөрес тә кебек. Ләкин аны якынча саннар өчен генә кулланырга ярый. Әгәр дә без Й.Акчура күрсәткән датаны катлаулырак формула аркылы миладига күчерсәк, Мәүлед бәйрәме (Пәйгамбәрнең туган көне) 1309 һиҗринең 12 рабигыләүвәленә яки милади белән 1890 елның 4 октябренә туры килгәнен күрәбез.

Бу датаны раслый торган тагын бер фактны китерергә мөмкин. Казанда чыга торган «Волжский вестник» газетасының 1892 елгы 7 февраль санында «Тәрҗеман» газетасыннан күчерелгән материалда Г.Барудиның җәдид мәктәбендә уздырган имтиханы хакында хәбәр бирелгән. Анда алты ай эчендә балаларның, уку-язу техникасын, дини тәгълимат һәм арифметика нигезләрен үзләштереп, зур уңышларга ирешүе хакында язылган. Санап карасак, монда җәдид ысулын куллану нәкъ 1890-1891 уку елында башланган булып чыга.

Димәк 1890 елның 4 октябреннән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең үсешендә яңа — җәдид чоры башланган. Гомумән алганда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 35 ел эшләү дәверен, минемчә, биш этапка бүлеп карарга кирәк: 1) 1882-1889 еллар; 2) 1890-1904 еллар; 3) 1905-1908 еллар; 4) 1908-1911/12 еллар һәм 5) 1912-1918 еллар.

1. 1882-1889 еллар. Бу чорда, алда күрсәтелгәнчә, Галимҗан хәзрәт шәкертләр җыйган, мәдрәсәнең матди хәле төпле нигезгә куелган. Г.Баруди укыту-тәрбия системасын традицион (соңрак «кадими» исемен алган) укыту эчендә үзгәртергә тырышкан.

2. 1890-1904 еллар. Татар халкы тарихында иң катлаулы һәм кискен үзгәрешләр башланган бу чор — Галимҗан Барудиның атаклы мөдәррис һәм җәмәгать хадиме буларак өлгерү еллары. Иҗтимагый торгынлык, аң-фикердәге сүлпәнлек, йомыклык халәтеннән чыгарга омтылу еллары үзенең әйдәманнарыннан бик күп көч, батырлык, тәвәккәллек, күп өлкәләрдә эш башкаруны да таләп иткән.

Укытуда яңа ысуллар кертү көн тәртибенә укучыларны яңа дәреслекләр белән тәэмин итү зарурияттен куйган. Һәм Г.Баруди дин белгече, уку-укыту эшләрен яңа юлга салучы мөдәррис булып кына калмаган, ул, башка җәдидчеләр кебек үк, дәрес китаплары һәм дини-фәлсәфи

гыйльми хезмәтләр язу эшенә дә алынган. 1890 елда ул «Гыйльме әт-тәүхид (Аллаһның берлеге хакында гыйлем)», 1891 елда «Сәвадхан (Тырыш шәкерт)» — әлифба, «Нәмунәи хисаб (Хисап үрнәкләре)» — арифметика дәреслекләрен бастырган. Моннан соңгы елларда да бу эш дәвам иткән. 90 нчы еллар дәвамында гына да Галимҗан хәзрәтнең уннан артык дәреслеге дөнья күргән. Дәреслекләрдән Казанда һәм аннан читтәге мәктәпләрдә дә уңышлы файдаланганнар. Шуңа күрә 1891-1918 елларда алар дистәләр тапкыр кабат-кабат нәшер ителгәннәр. Мәсәлән, «Сәвадхан» меңләгән тиражлар белән унике мәртәбә басылган.

Җәдиди башлангыч мәктәпләре уңышлы гына эшләп киткән. Бу уңышлар мөдәрриснең дә, мәдрәсәнең дә данын еракларга таныткан. 1894 елда, рәсми мәгълүматлар күрсәткәнчә, «Мөхәммәдия» шәкертләр саны һәм төзеклеге ягыннан Казанда беренче урынга чыккан: 1895 елга мәдрәсәдә 121 шәкерт укыган (башка мәдрәсәләрдә 35-60 шәкерт булган) [24]. Ә 1905 елда мәктәп һәм мәдрәсәдә 14 яшькә кадәр 180 һәм 14 яшьтән өлкән 150 шәкерт белем алган. Бу 330 шәкертнең 130ы Казанныкылар, 200е читтән килүчеләр һәм мәдрәсәдә яшәүчеләр булган [25].

Әлбәттә, башлангыч мәктәп кебек, мәдрәсә үзе дә үзгәрешләр таләп иткән. Ләкин монда юл күрсәтүчеләр булмаган. Озакламый татар дөньясында Оренбургтагы «Хөсәения», Вятка губернасындагы Иж-Буби мәдрәсәләренең җитәкчеләре кебек Галимҗан хәзрәткә дә үз юлын эзләргә, юл ярып барырга туры килгән. Мөдәррис, акрынлап «рөшдия кыйсемен төзәтү фикеренә төшеп, әүвәл берничә китап тәэлиф итеп [төзеп], соңыннан 1317 сәнәдә [елда] (1898. — *А.М.*) ысуле рөшдия ачылып, аннан соң акрынлап игъдадия вә галияне бераз тәртипкә салып, хәзерге халәтләренә китергәндер. Бу юлда «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» халыктан яңа тәртипкә ияләнмәү кебек мәшәкатьләр башыннан уздыргандыр» [26].

Г.Баруди мәдрәсәнең уку-укыту программасын тәртипкә салган, дини фәннәрне укытуда схоластиканы бетерергә тырышкан. Мәдрәсәдә укыту, дәреслекләр язу, бастыру белән бергә Г.Барудига бу чорда мәдрәсә биналарын яңадан төзү эше белән дә шөгыльләнергә туры килгән. 1898 елгы зур янгыннан соң мәдрәсәне яңабаштан торгызырга туры килгән. Хәзерге көнгә килеп җиткән өч катлы таш бина 1901-1902 елларда салынган. 30 мең сум чамасына төшкән бина үзәктән ягып җылыту системасы белән тәэмин ителгән. Шәкертләрнең яшәү урыны һәм ашханә аерым биналарга урнашкан. Дәресханә аяклы тәбәнәк парталар, мөнбәр, кара такталар, төрле карталар һ.б. белән җиһазландырылган. Бу яңалыклар тагын 30 меңгә якын чыгым таләп иткән. Шәкертләр дәрескә махсус форма — утырма якалы казаки, түгәрәк түбәле кәләпүш киеп йөргәннәр.

XX гасыр башында Г.Барудига, бер яктан, гавамның канәгатьсезлеген басарга туры килгән, икенче яктан югары бүлекләрдә укучылар үзләренең ризасызлыгын күрсәтә башлаган. Остазларының тырышлыгы белән күзләре ачылган, фикерләре үскән шәкертләргә мөдәррис ипләп кенә кертә башлаган яңалыклар аз тоелган. Һәм 1904 ел азагында алар мәдрәсә җитәкчелегеннән дөньяви фәннәр һәм дин фәлсәфәсен укытуны таләп иткәннәр.

3. 1905-1908 еллар — Россиядәге беренче инкыйлаб еллары. Милли

хәрәкәт моңа кадәр күренмәгән тизлек белән активлашкан чор. Аның бер өлеше булып, Мөхәммәдия шәкертләре башлангычы белән барлык мәдрәсәләргә шәкертләр хәрәкәте җәелгән. Шәкертләр таләбе буенча мәдрәсәдә укыту программасы тамырдан үзгәргән, дини дәресләргә дә үзгәрешләр кертелгән, яңа дөньяви фәннәр дә укытыла башлаган. Бу яңалыклар белемле мөгаллимнәрне таләп иткән. 1906 елда мәдрәсәдә егермеләп укытучы дәрес биргән. Аларның күпчелеге дамелланың үз шәкертләре булган. Мөгаллимнәр арасында Г.Камал (татар теле), Ф.Әмирхан (география, төрле сәяси партияләр), табиб Әбүбәкер Терегулов (гигиена), адвокат Сәедгәрәй Алкин (хокук), Йосыф Акчура (сәяси тарих) һ.б. дөньяви фәннәрдән дәрес биргәннәр. Ләкин әле мәдрәсә программасында тотнаклылык булмаган, укытылган фәннәр, мәгаллимнәр гел алмашынып торган.

Бу чорда гаять зур абруйга ия булган дамелла милли хәрәкәтнең әйдәманнары арасында, мөселман съездларында да актив катнашкан, журнал чыгаруга да алынган. Галим 1906 елның гыйнварендa ук «Әд-дин вәл-әдәб» исемле журнал чыгарырга Казан губернаторының рөхсәтен алган. Бу «дини, әдәби, гыйльми вә сәяси мәҗәлләи исламия»нең [ислам журналы] мәхәррире вә нашире дә, төп авторы да Галимҗан Баруди үзе булган. Журнал чыгару дамеллага, бер яктан, дини тәгълиматны аңлату өчен кирәк булса, икенче яктан, ул җәдид мәктәп-мәдрәсәләре өчен методик әсбап буларак та хезмәт итәргә тиеш булган. Бу адымы Г.Барудига дин, фән, тормыш һәм мәгариф өлкәсендәге карашларын, милли хәрәкәттәге яңалыкларны һәрдаим җәмәгатьчелеккә җиткерү, төрле иҗтимагый катлау вәкилләрен «агарту» мөмкинлеген дә биргән.

4. 1908-1911/12 еллар. Революция җиңелгәннән соң 1908 елның 8 маенда актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Г.Баруди ике елга Вологдага сөргенгә җибәрелгән. Энесе Габдрахман хәзрәт Галиев һәм мөгаллим Әхмәтҗан Мостафа карамагына калдырылган ятим мәдрәсәдә бу чорда үзгәрешләр күренмәгән.

1910 елда Г.Баруди Казанга кайткан. Мәдрәсәдә шәкертләр укыту-тәрбияләүдән, имам вә мөхәррир буларак, халыкны «агарту»дан башка тормышын күз алдына да китерә алмаган дамелла һәм тарафдарлары аның вазифаларын кайтару өчен төрле чаралар күргән. Ниһаять, 1912 елның гыйнварендa имам-хатыйп һәм мөдәррис булу, декабрендә «Әд-дин вәл-әдәб» журналын яңарту мөмкинлеге ачылган.

5. 1912-1918 еллар — «Мөхәммәдия»нең иң шөһрәтле чоры. Нәкъ шушы вакытта мәдрәсәгә төп үзгәрешләр кертелгән. Мәдрәсәнең даими кулланырлык яңа программасы эшләнгән. Программадан күренгәнчә, мәдрәсә өч баскычтан торган: алтышар сыйныфлык ибтидайя һәм сәнәвия һәм өч сыйныфлык галия. Берьеллык хәзерлек бүлеген дә кушсак, мәдрәсәдә уку 16 ел дәвам итәргә тиеш була. 1913/1914 уку елыннан мәдрәсә шушы программа буенча эшли башлаган. Һәм нәкъ бу программа «Мөхәммәдия» хаклы рәвештә татар университеты исемен йөрткән дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

«Мөхәммәдия» — ныклы режим, шактый кырыс һәм таләпчән тәртипләр нигезендә эшләгән уку йорты. [...] Уку-укыту программасы татар баласына исламга, шәригатькә нигезләнгән төпле белем бирүне күздә тота, ул гына да түгел, югары белем-

ле дин эшлеклеләре, имамнар һәм мөдәррисләр әзерләүне максат итеп куя, — дип бәяли программаның 1998 елгы басмасына бирелгән «Кереш сүз»дә галим Равил Әмирхан. — Шул ук вакытта ана телен (төрки) үстерү, гарәп һәм фарсы телләрен үзләштерү, урыс телен камил өйрәтү программаның үзәк максатларыннан берсен тәшкил итә» [27].

Ләкин бу программаның да гомере кыска булган. 1917 елда Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда Галимҗан Баруди, Эчке Русия һәм Себер мөселманнары мөфтие итеп сайланып, Уфага күченеп киткән. Бу вазифаны да ул бөтен көчен җигеп башкарган. Бу хакта хәтта аның үлеме дә сөйли. Ул ачларга ярдәм оештыру өчен Мәскәүгә барган җирендә 1921 елның 6 декабрендә кинәт вафат булган. Галимҗан хәзрәтнең җәсәден, Казанга алып кайтып, зур хөрмәт белән җирләгәннәр. Аның йөрәк җимеше «Мөхәммәдия», 1918 елда мәдрәсә исемен югалтып, икенче баскыч совет мәктәбе статусын алган.

Г.Барудиның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген (шул исәптән, мөфтилек чорын да) анализлауны икенче мәкаләгә калдырып, язманы Ризаэтдин Фәхретдин бәяләмәсе белән тәмамлыйм:

«Мөфти Галимҗан хәзрәтләре бу мәмләкәт мөселманнары арасында заһир булган өч данә хакыйкый галимнәрнең берсе иде. Икесе Курсави белән Мәрҗанидыр. Шәкертләре әһле фазыйль булу һәм дә үзе күп галим күрү вә күп урында сәяхәт итү, соң басылган әсәрләрне моталәга кылу җәһәтеннән Курсави берлә Мәрҗанига күрә бәхетле иде. [...] Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләре дөрес игътикадлы вә гыйбадәтле һәм дә әүрадлы иде. Гайбәт сөйләүдән вә тыңлаудан сакланадыр, кешеләр арасын бозу кебек вак эшләрдән ерак булып, раст сүзле иде. Гарәпчә вә фарсычасы үзенең ана теле дәрәҗәсендә фәсыйх вә әдәби иде» [28].

Әдәбият:

1. Мәшаһир мөдәррисеннән Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләренең хезмәте миллия вә диниясенең 25 нче елы. — Тәрбияи әтфаль, 1907, №3. — Б.44-47.
2. Акчура угълы Й.Дамелла Галимҗан әл-Баруди. Тәрҗемәи хәле. — Казан, 1907.
3. Ике язма да 1997 елда Казанда «Иман» нәшриятында кабатлап басылды. Кара: Акчура Й.Дамелла Галимҗан әл-Баруди. Тәрҗемәи хәле. — Казан: Иман, 1997. — Б.76.
4. Шунда ук. — Б.13.
5. Шунда ук. — Б.14.
6. Акчура Й. Күрс. хезмәт. — Б.19.
7. Шунда ук.
8. Шунда ук. — Б.28.
9. Акчура Й. Күрс. хезмәт. — Б.34.
10. Шунда ук. — Б.35.
11. Шунда ук.
12. Галимджан хазрат Баруди. Памятная книжка (Хәтер дәфтәре). — Казань: Иман, 2000. — С.144.
13. Шунда ук.
14. Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. — Казан: Җыен, 2010. — Б.183.
15. Ягъни 1870 елдан (бу вакытта Г.Барудига 13-14 яшь булган).
16. Мәрҗани. — Б.399.
17. Мәрҗани. — Б.483-484.
18. Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык. — Казан: Рухият, 2000. — Б.18-19.
19. Тәрҗеман, 1890, 18 март.
20. Шунда ук, 23 ноябрь.
21. Медресе г.Казани XIX — нач. XX вв.: Сб. документов и материалов / Отв. сост. Л.В.Горохова. — Казань: Гасыр, 2007. — С.61-63.
22. Акчура Й. Күрс. хезмәт. — Б.58.
23. Ә.С.Галеев, Ләбибә Хәсәения мәктәбенә багышланган материалларны җыеп, университетның китапханәсенә дә тапшырды. Кара: Материалы по истории школы Лябибы Хусаиновой в Казани. — ОРРК НБ К(П)ФУ, №2390 т, л.104.
24. Медресе г.Казани. — С.86-93.
25. Шунда ук. — Б.127.
26. Акчура Й. — Б.58.
27. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе. — Казан: Мәгариф, 1998. — Б.4-6.
28. Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. — Казан: Рухият, 2010. — Б.363.

Кушымта

«МӘДРӘСӘИ МӨХӘММӘДИЯ» ПРОГРАММАСЫ [1]

(1913/1914 нче елгы уку елы)

КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия» ибтидаия [башлангыч], сәнәвийә [урта], галиядән [югары] гыйбарәт өч бүлеккә аерыладыр.

Ибтидаия алты еллык тәхсилдән [укудан] гыйбарәт, фәкать башлангыч мәгълүмат илә дөньяга чыгарга, яки хөкүмәт мәктәпләренә кереп, русча укырга теләгән кешеләр җитештерәдер.

Ибтидаияне тәмам кылучы тиешле булган әхкяме-шәргъне [шәригать хөкемнәрен] белеп гамәл итәрлек, дөрес Коръән укырлык, бераз гарәпчә вә фарсыча аңларлык, ана телебез төркичә һәрбер максудын язып аңлатырлык, тарих, җәгърәфия [география], физика нигезләреннән вә, хосусан [аеруча], хисаптан шактый хәбәрдар, ибтидаи дәрәҗәсендә русча да укыган буладыр.

Сәнәвийә алты еллык тәхсилдән [укудан] гыйбарәт булып, гыйльме гарәбия, голүм шәргыя [шәригать гыйлеме] вә рус теле укытыладыр.

Сәнәвийәне тәмам кылучы имам вә мөгаллим булыр өчен тиешле булган гомум шәргыя вә фөнүн зарурияне тәкәммел иткән [тулысынча үзләштергән] буладыр.

Галия өч еллык тәхсилдән гыйбарәт, чын голүм шәргыя, Коръән вә әхадисе нәбәвиядә [пәйгамбәрләр хәдисләрендә] тугры моталәга сахибе [хөкем йөртү хокукына ия], имам вә мөдәррис булмага бәхак лаек [хокукка лаек] буладыр.

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә кабул булыныр өчен кирәкле шартлар:

1. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә керер өчен йогышлы вә җирәндергеч авырулардан сәламәт, паспортлы, тәрбиячеләре рөхсәтле, элек укыган җиреннән яхшы холыклы булмакына язулы булмак вә болар өстенә мәдрәсәнең дөхулия [хак] акчасын тулысынча биреп, кыш буенча кешегә ихтыяҗсыз уздырырлык булмак тиештер.

2. Һәрбер шәкерттән ун сум дөхулия илә өч сум тәэмин акчасы алына. Мәдрәсә нәрсәләренә зыян итмәгән шәкертнең тәэмин акчасы яз фасылында кайтарыладыр.

3. Мәдрәсәгә керергә теләгән шәкертләргә гаризалары илә бергә үк дөхулия вә тәэмин акчаларын мәдрәсә идарәсенә тапшырмак тиештер.

4. Мәдрәсәгә кабул ителеп укый башлаган шәкертнең дөхулиясе, гаскәргә алынудан башка, һичбер сәбәп белән кире кайтарылмас.

5. Тәрбиячесе Казанда булмаган шәкерт фатирдан йөреп укырга, шулай ук иреклe тыңлаучы сыйфаты берлә дә кабул ителмидер.

6. Бозыклыгы вә әхлакъсызлыгы күренеп торган иске вә яңа шәкертләрнең һичберсе кабул ителмидер.

7. Яңа шәкертләр кирәк каю мәдрәсәдән булсалар да, эстәгән [теләгән] сыйныфларына имтихан берлә кабул ителерләр.

8. Ибтидаиянең хәзерлек сыйныфына 7 дән түбән, 10 нан югары, беренче сыйныф — сәнәвийәгә 12 дән түбән, 15 тән югары яшьле шәкертләр кабул ителмидер. Югары сыйныфларда да ошбу кагыйдә иҗраэ ителәдер [үз көчендә кала].

9. Ибтидаиянең хәзерлек сыйныфына һичнәрсә укымаган балалар алынадыр.

Беренче сыйныф — сәнәвийәгә керер өчен, дүртенче сыйныф — ибтидаиядә күрелгән мәгълүматтан имтихан бирерлек булырга кирәк. Тәҗвид кагыйдәләре буенча дөрес итеп Коръән укырлык, һәрбер төрки китапны укып аңларлык, һәрбер төрки сүзне язарлык, дүрт гамәл эчендә хисап, башлангыч җәгърәфия вә тарихе ислам, русчадан букваларны аерган булмак тиештер.

Югары сыйныфларга керер өчен программа буенча түбәнге сыйныф дәресләреннән имтихан бирмәк тиеш буладыр.

МӘДРӘСӘГӘ КАБУЛ ИТЕЛГӘН ҺӘР ШӘКЕРТКӘ БЕЛЕРГӘ ҺӘМ ХӨРМӘТ ИТӘРГӘ ТИЕШЛЕ КАГЫЙДӘЛӘР

1. Мәдрәсәгә кабул ителгән шәкертләр, мәдрәсәнең дәресе укыла башлаган көннән тәгътиленәчә [имтиханга кадәр], җәдвәлләрдә күргәзелгән дәресләрнең һәркаюсына чигентесез йөреп, ел ахырында һәрбер дәрестән имтихан бирерләр. Гозерсез дәрестән калган шәкерт педагогик комиссиянең карары буенча мәдрәсәдән чыгарылыр.

2. Мәдрәсәнең идарә әгъзаларына итагать итмәгән, мәдрәсә кануннарына буйсынмаган, дәресләрендә ялкаулык күргәзгән, шәригатькә каршы эш эшләгән вә мәдрәсәнең тормышын боза торган эшләргә катнашкан, кәрт, шахмат, шашка, кубыз, тәмәке кеби вакыт уздыруларга, мәдрәсә эчендә сызгырмак, кул чапмак, әшәке рәвештә акырмак-бакырмак, җырламак, сүгешмәк, сугышмак кеби әдәпсезлекләргә катнашкан шәкертләр законлы рәвештә җәзага тартылырлар.

3. Шәкертләрнең киемнәре идарә тарафыннан билгеләнгән рәвештә булмакы хуп күрелә. (Тышкы киемнәре кара яки каралҗым төстә пальто, кечкенә кара бүрек, читек яки башка бер нәрсә өстеннән резин галош булыр. Суык көннәрдә башлык кияргә дә ярый, эчке киемнәре кәзәкин яки җөббә булыр.) Эшләпә, озын бүрек вә кыска киемнәр кеби халкыбыз тарафыннан кабул ителмәгән кием вә гадәтләрдә булмак тыела.

4. Ләйлә [төн] кунып йөрүче итеп кабул ителгән шәкертләргә, мөдир ярдәмчесе карават, простыня, кием шкафы һәм бикләүле тумба билгеләр. Шәкертләр һәрбер үзенә билгеләнгән нәрсәләрне саклап кулланырга вә мәдрәсәдән киткән вакытта яңадан мөдир ярдәмчесенә яки тәртип саклаучыга тапшырырга бурычлыдыр. Монда берәр җинаять күренсә, ул кем тарафыннан кылынган булса да, әйберләр башта кемгә билгеләнгән булса, шул адәм түләячәктер.

5. Гомуми аш вә чәй вакытыннан башка вакытларда аш вә чәй илә шөгыльләнмәк тыела.

6. Мәдрәсә эченә сәяси документлар вә рөхсәтсез китаплар кертмәк вә яннарында сакламак катгый тыела.

7. Билгеләнгән урыннарыннан башка җиргә төкермәк, сеңгермәк, су түкмәк, аяк киеме вә комганнар куймак, кыскасы, мәдрәсәнең чисталыгына зыян китерердәй эшләрне эшләмәк зур җинаять саналадыр.

8. Шәкертләр кич сәгать унда ятып, иртә алтыда торырга тиешледерләр.

9. Дәрескә керергә звонок булгач, мөгаллимнәренең булу-булмавына карамаенча, шәкертләр үзләренең дәрес бүлмәләренә кереп, мөгаллимнәренең килүен әдәп берлә көтәрләр. Мөгаллимнәре кергәч аяк үзрә торып хөрмәт белдерерләр. Мөгаллимнәре кичексә, яки бөтенләй килми калса да дәрес бүлмәләреннән чыкмаенча дәресләрен кабатлап вә киңәшеп-сорашып утырырлар.

10. Шәкертләр биш вакыт намазны мәдрәсә эчендәге намаз бүлмәләрендә фарыз вә вәҗепләре берлә, тыйнак тәртип саклап җәмәгать берлә баш-

карырлар. Мәгәр җомга намазын мәсҗеткә чыгып башкармак ляземдер. Җомга намазыннан берничә тапкыр качып калган шәкерт мәдрәсәдән чыгарылыр.

11. Дәрес көннәрендә шәкертләр, сыйныфларындагы дәресләр беткәч, ахшам азанынача, шәһәргә чыгып йомышларын үтәргә вә идарә тарафыннан тыелмаган урыннарга барырга ихтыярлыдырлар.

(Җомга, гает вә башка бәйрәмнәр сәбәпле тәгътил ителгән көннәрдә иртәннән үк ахшам азанынача ихтыяр биреләдер.) Моннан башка вакытларда мөгаллимнәреннән яки тәртипчеләрдән рөхсәт язуы алмаенча чыкмак тыела.

12. Рөхсәтле вакытта шәһәргә чыккан шәкертләр ахшам вакытында мәдрәсәгә кайтулары тиештер. Ахшамнан берничә тапкыр кичегеп кайтучылар мәдрәсә низамына хилафлык иткән саналалар.

13. Бәйрәмнәрдә, бирелгән тәгътил көннәрендә рөхсәт берлән өйләренә кайтучылар билгеләнгән мөтдәттән гозерсез бер атна кичегеп килсәләр, шулай ук гаскәргә каралучылар гаскәрлек эше тәмам булгач бер атнадан артык килми торсалар, мәдрәсәгә кабул ителмәсләр.

14. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» шәкертләренә дәрес вә тәгътил көннәренең һичкаюсында театр, кинематограф вә әдәбият кичәләренә барырга рөхсәт юктыр. Файдалы күрелгән татарча лекцияләргә барырга махсус рөхсәт илә вакыт һәм рөхсәт бирелер.

15. Мәдрәсә әйберләренә белә торып яки хата белән җинаятьчел мөнәсәбәттә булган шәкертләр шул әйбернең кыйммәтен түләргә тиешледер. Юри җинаять итүчеләр түләү илә бәрабәр җәзага да тартылыр.

16. Килеп укучы шәкертләр өйләренә кайткан вакытта урамнарда җыелышып тормаклары һәм юлда кычкырышып, уйнап, сугышып барулары әдәпсезлек саналадыр.

ИБТИДАИЯ КЫЙСЕМНЕҢ БЕР АТНАЛЫК ДӘРЕСЛӘР ҖӘДВӘЛЕ

Дәрес исемнәре	Хәзерлек сыйныфы	Беренче сыйныф	Икенче сыйныф	Өченче сыйныф	Дүртенче сыйныф	Бишенче сыйныф
Коръән	–	5	5	4	2	2
Диннең нигезләмәсе	1	2	3	2	2	2
Төрки тел кагыйдәләре	–	–	–	–	2	2
Төрки телдә уку	6	5	4	2	2	1
Имля (орфография)	3	2	2	1	1	1
Инша (сочинение)	–	1	1	1	1	1
Хәдис вә гарәпчә	–	–	–	2	2	2
Русча	–	–	3	6	6	6
Фарсыча	–	–	–	1	1	1
Хисап	3	3	3	3	3	3
Җәгърәфия	–	–	–	–	1	1
Тарих	1	1	1	2	1	2
Физика	–	–	–	–	1	1
Күркәм язу	3	2	1	1	1	1
Сызым	1	1	1	1	–	–
Счет	–	1	1	1	1	–
Коръән ятлау	–	1	1	1	1	1
Коръәнне көйләп уку (мәкам)	–	–	–	–	–	1
Җәмгысе:	18	24	26	28	28	28

[…]

ИБТИДАИ. БИШЕНЧЕ СЫЙНЫФ [2]

[…] Тарихлар (2 дәрес): 2 сәгатьтән берсендә милли тарих, икенчесендә рус тарихы укытылыр.

Милли тарихтан: болгарлар, болгарлар мәдәнияте, болгарларның дошманнары.

Татарлар, Чыңгыз хан, Җүчи хан, Батый хан. Алтын Урда вә аның мәшһүр ханнары. Казан падишаһлыгы вә аның мәшһүр ханнары.

Тарихе рустан: Шәркый Европаның борынгы халкы, елау [славян] кабиләләре, елауларның тормыш рәвешләре, сәяси тормышлары.

Русия дәүләтенең тәшкиле, князь Олег, Владимир һәм христианлык. Русиянең удельләргә бүленүе, Русия тарихында татарлар дәвере, татарлар, аларның мәгыйшәтләре, Русиягә икенче тапкыр килүләре.

Рус князьләренең татар ханнарына мөнәсәбәтләре, Куликово сугышы һәм өченче Иван, дүртенче Иван (Грозный) һәм Казанны алу, болгану дәвере, Михаил Фёдорович Романов, Алексей һәм аның балалары, бөек Пётр һәм аның дәвамчылары. Бөек Екатерина һәм угылы Александр I, Николай I, Александр II. […]

СӘНӘВИЙӘ ИЛӘ ГАЛИЯГӘ МАХСУС АТНАЛЫК ДӘРЕСЛӘР ҖӘДВӘЛЕ

Дәрес исемнәре	Сәнәвийә						Галия		
Коръән	1	2	3	4	5	6	1	2	3
Гарәпчә	2	2	1	1	–	–	–	–	–
Шигырь теориясе (метрика)	–	–	–	2	–	–	–	–	–
Риторика һәм гарәп әдәбияты	–	–	–	–	5	4	3	3	3
Төркичә	2	2	2	2	1	1	1	1	1
Русча	6	6	6	6	6	6	–	–	–
Матур язу	1	1	1	–	–	–	–	–	–
География	2	2	2	2	–	–	–	–	–
Ислам тарихы	1	1	2	2	–	–	–	–	–
Төрек кавеме тарихы	1	1	1	–	–	–	–	–	–
Рус тарихы	–	–	–	–	1	1	–	–	–
Гомуми тарих	–	–	–	2	2	2	–	–	–
Гыйлем һәм сыйныфлар тарихы	–	–	–	–	–	–	2	–	–
Исламият һәм башка диннәр	–	–	–	–	–	–	–	1	1
Хисап	3	3	2	2	–	–	–	–	–
Геометрия	–	–	–	–	2	1	–	–	–
Шәригать белеме	1	1	2	2	2	2	3	3	3
Мирас бүлү фәне	–	–	–	–	–	1	–	–	–
Шәригать ысулы	–	–	–	–	–	1	3	–	–

Изге хәдис	1	1	1	1	2	3	5	6	6
Хәдис ысулы	–	–	–	–	1	–	–	–	–
Пәйгамбәрләр һәм хәлифәләре турында китап	–	–	–	–	3	2	–	–	–
Гакаиде [иман, инану]	–	–	–	–	–	1	–	2	2
Коръән сүзләренә аңлатма	–	–	–	1	1	1	5	6	6
Әхлак	–	–	–	–	1	1	–	–	–
Гигиена	–	–	–	–	1	1	–	–	–
Физика, табигать белеме	1	1	1	–	–	–	–	–	–
Фәлсәфә	–	–	–	–	–	–	1	–	–
Методика һәм педагогика	–	–	–	–	–	–	1	2	2
Җәмгысе:	29	29	29	29	29	29	24	24	24

СӘНӘВИЙӘ. БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФ

[…] Төрки кавемнәр тарихы (1 дәрес). Төрек атала торган кавемнең пәйда булуы, урыннары, яшәү рәвешләре, иске диннәре, тарала башлаулары, төрле исем алулары, сәбәпләре.

Ул заманнарда Европа һәм Азиянең хәле, аларда яшәүче халыклар, тормыш кору юлында дәрәҗәләре, төркиләр берлә мөнәсәбәтләре.

Төркиләрнең гареб тарафына хәрәкәтләре, Баламир һәм Атилла ханнар, халыкларның тоташ күченүе вакыйгасы.

Хәзәрләр, румнар берлә мөгамәләләре, мөселманнар берлә булган вакыйгалары, исламиятнең Хәзәрләрдә чагылышы, хәзәр исеме, (кыпчак-куманы — половцы) исемнәре калуы, хәзерендә Хәзәрләрнең калдыклары – караим яһүдиләр.

Төркиләрдән болгарлар, төркиләр хакында гомуми мәгълүмат. Болгар хөкүмәтенең урыны, чикләре.

Күршеләре: чувашлар, аларның асыллар, башкортлар, башкортларның болгар хөкүмәтенә табигь [буйсынган] заманнары, Казан хөкүмәтенә табигь заманнары, Русия хөкүмәтенә табигь булулары һәм мәшһүр фетнәләре, хәзәрләр, хәзәрләрнең асыллары (чыгышлары), славяннар, славяннарның асыллары вә кыска рәвештә башка хәлләре, болгарларның күршеләре берлә мөгамәләләре.

Сәүдә, һөнәр, кәсеп, мәгарифе, гадәт-йолалары.

Диннәре, ислам динен рәсми кабуллары, Багдад илчеләре килүе һәм шул вакыттагы вакыйгалар.

Болгар хөкүмәтенең шәһәрләре, алардан калган әсәрләр.

Татар атала торган кавемнең пәйда булуы һәм төрле вакытта болгар өстенә килеп тынычсызлаулары, болгарлар берлә, җәнүб [көньяк] тарафындагы иң уңган сәүдә урыннары булган, хәзәрләр арасына татарлар урнашкач сәүдә кимеп әһәмияте бетү һәм болгар дәүләтенең бөтенләй бетүе (икенче исемгә алышынуы). […]

СӘНӘВИЙӘ. ИКЕНЧЕ СЫЙНЫФ

[...] Төрки кавемнәр тарихы (1 дәрес). Татарлар кемнәр, магул [монгол] кабиләләренең башлыгы Ясүкәй батырның алар берлә булган вакыйгалары.

Тимучин тууы, яшьлек вакыты.

Ясүкәй батырның үлүе, Тимучин һәм кардәшләренең Ясүкәй үлгәннән соңгы хәлләре.

Тимучинның баш булуы. Чыңгыз исемен алуы.

Чыңгызның шәрык һәм гареб тарафына булган сәфәрләре, ислам хәлифәләре берлә булган вакыйгалар.

Чыңгыз гаскәренең Европага беренче тапкыр килүе һәм руслар берлә булган вакыйгалары.

Чыңгызның гаскәре, гаскәренең тәртибе.

Чыңгызның шәхесе һәм төзегән дәүләте.

Чыңгызның балалары һәм туруннары [актыклары, токымнары].

Һулагу, аның Багдад шәһәрен җимерүе.

Кублай, аның заманында хөкүмәт.

Чыгатай, идарә итә торган урыны, чыгатай теле — әдәбияты атала торган әдәбиятның пәйда булуы.

Җүчи хан, Дәште Кыпчак, Алтын Урда хөкүмәтенең тәшкиле, Җүчинең шәхесе, вафаты.

Бату хан, тәхеткә утыруы, корылтайга баруы, болгар һәм рус җирләрен алуы.

Бату ханның Киевне алуы, гаребкә борылуы, Сарай шәһәрен кору, кахан сайлау.

Алтын Урдада идарә һәм хөкүмәт, сәүдә, игенчелек.

Рус кенәзләренең Алтын Урдага буйсыныргa барулары.

Бату ханның тормышы, шәхесе, үлүе.

Бәрәкә хан, Алтын Урдада дин исламиятне кабул итү.

Бәрәкә хан берлә Һулагу арасында булган вакыйгалар.

Бәрәкәнең дин исламны таратуы, шәхси падишаһлыгы, вафаты.

Нугай мирза, аның заманында эчке фетнәләр. Нугайның үтерелүе.

Үзбәк хан, Һулагу балалары берлә булган вакыйгалар, рус кенәзләренең дәгъвалары, Тверь вакыйгасы.

Үзбәкнең Иван Калитаны олугь кенәз итүе, Мәскәүнең көчәя башлавы.

Үзбәк ханның, падишаһлыгы, Сарай шәһәренең биналары, төзелеше. Үзбәк дип атала торган халыкның пәйда булуы.

Җанибәк ханның тәхеткә утыруы, ханнарның чиркәү милке булган нәрсәләр тугрысында тоткан юллары. Рус кенәзләре арасындагы дәгъваны бетерү, рус җирләре хакындагы сәясәте.

Бирдебәкнең хан булуы, башбаштаклык, Алтын Урданың күп өлешләргә бүленүе. Мамай мирзаның өсткә чыгуы, русларны иркәләүнең нәтиҗәсе, Куликово сугышы – Мамайның качып китүе, үтерелүе.

Туктамышның хан булуы, Мәскәүгә сәфәре, Туктамыш хан берлән Аксак Тимер арасы бозылу, Аксак Тимернең Дәште Кыпчакка килүе һәм вәйран итүе. Туктамыш берлә Идегәй мирза арасындагы вакыйгалар, Туктамышның актык көннәре, Идегәй мирзаның рус җирен басуы, Туктамыш хан балалары һәм Идегәй.

Олуг Мөхәммәднең хан булуы, рус кенәзләреннән Василий берлә Юрий арасындагы низаг, Олуг Мөхәммәднең Сарайны ташлап чыгуы, Кечек Мөхәммәднең хан булуы.

Сәед Әхмәднең хан булуы, Иван III нең кенәз булуы, Кырым ханнарының Алтын Урдага дошманлыклары, Алтын Урданың зәгыйфьләнүе, татарларның Мәскәү өстенә актык сәфәрләре, Әхмәд ханның үтерелүе, русларның татарлар кул астыннан чыгулары, Алтын Урданың егылуы.

Баруди Г. Мөгамәлят. –
Казан: Элктр-тип. «Миллят», 1910 ел

Баруди Г. Сөаль вә җаваплы бәдәэлмәгариф. –
Казан: Лито-тип. Н.Н.Харитонов

Чыңгыз дәүләте астында булган төрекләрнең татар аталулары, Чыңгыз — Алтын Урда дәүләте беткәч, шундагы төрки кавемнәрнең урыннарына карап, кырым татарлары; казан татарлары; әстерхан татарлары; себер татарлары исемнәрен алулары. [...]

СӘНӘВИЙӘ. ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

[...] Тарихе каүме төрки (1 дәрес). Казан падишаһлыгы. Болгар шәһәрләреннән саналган иске Казанның урыны, хәзерге Казанның төзелүе, Олуг Мөхәммәд ханның Казанга килеп, Казан падишаһлыгы тәшкил итүе, Мәскәүгә сәфәрләре, Олуг Мөхәммәднең, шәхесе һәм төзегән дәүләте, Мәхмүднең хан булуы, Касыйм ханлыгының тәшкиле. Ибраһимның хан булуы, Касыйм ханның рус гаскәре илә Казанга килүе, Мәскәү илә солых, Казанның Мәскәү тәэсире астына керүе, Ибраһим хан үлгәннән соң хан сайлау турысында каршылыклар, Илһам хан, Ибраһимның ике угылы рус хезмәтенә керүе, Илһам ханның әсир булуы һәм зинданда үлүе.

Мөхәммәд Әмин хан — Мәскәү файдасына тырышуы, казанлыларның Сибириядән Мамук ханны чакырулары, Мөхәммәд Әминнең Мәскәүгә качуы.

Мамык хан — дәүләт хезмәтендә тора белмәве сәбәпле Казан халкының аны куулары, Габделлатыйфны чакыру.

Габделлатыйф хан, ханлыктан төшерелеп үлгәнче ятырга зинданга салынуы.

Мөхәммәд Әмин ханның икенче мәртәбә хан булуы, Мәскәүгә дошманланып сугыш ачуы, Иван III нең үлүе, Өченче Василий берлә сугыш, Мөхәммәд Әминнең үлүе, Габделлатыйф ханның үлүе һәм Олуг Мөхәммәд сөләләсенең [династиясенең] киселүе.

Казанга Касыймда торучы Шаһ Галинең хан булуы, Кырым ханы Сәхибгәрәйнең Казанга килеп Шаһ Галине куып чыгаруы.

Сәхибгәрәй хан, агасы Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй берлә берләшеп

Мәскәүне басулары, Мөхәммәдгәрәйнең Әстерханны алырга баруы һәм аннан максуды, үтерелүе. Сәхибгәрәй ханның төрек солтаныннан ярдәм соравы, Истанбулга баруы, солтанның игътибарсызлыгы.

Сафагәрәй хан, русларның Казанга килеп җиңүләре, Сафагәрәйнең ханлыктан төшерелүе.

Җангалинең хан булуы, Сафагәрәйнең Кырым тарафыннан килеп Мәскәүгә һөҗүме, Василий үлеп, Иван IV нең кенәз булуы. Җангалинең Сөембикәне алуы. Җангалинең юк ителүе.

Сафагәрәйнең икенче мәртәбә хан булуы, Шаһгалинең икенче мәртәбә хан булуы, Сафагәрәйнең 3 нче мәртәбә хан булуы — Казан дәүләтенең зәгыйфьләнүенә сәбәп.

Үтәмешгәрәйнең хан булуы, аның әшен анасы Сөембикә башкаруы, солтан Сөләйман Канунидан Кырым шаһзадәсен сорау, Иван Грозныйның Казанны басуы, Казан җиренә русларның Зөя каласы салулары, Казанны яңадан биләп алу, кырымлыларның Казаннан качулары, казанлылар өчен авыр булган шартлар берлә солых ясалу, Сөембикә һәм угылы Үтәмешнең Казаннан китүләре.

Шаһгалинең 3 нче мәртәбә хан булуы, җитмешләп Казан олугларын суйдыруы, Казанда тынычсызлык башлануы, Шаһгалинең Казанны русларга бирергә юл хәзерләве һәм качуы.

Шаһгалинең Касыймга кайтып Сөембикәне алуы. Казанга рус наместник билгеләү. Мәскәү кенәзенең Казанны алырга хәзерләнүе, Казанга Ядкәр ханны китерү.

Ядкәр ханга буйсынырга ант итү, чирмеш һәм чувашларның казанлыларга кушылулары, русларның Казанны алырга килүләре, казанлыларның актык сулышларына кадәр ватаннарын сакларга тырышулары. Казанның алынуы, Сөембикә манарасы, Сөембикә һәм угылы Үтәмешнең соңгы хәлләре…

Кырым ханлыгы, Алтын Урда дәүләтен бетерергә тырышулары, мөстәкыйльлек дәверләре, рус һәм казанлылар берлә мөнәсәбәтләре, Төркия солтаны кул астында Русиягә кушылулары.

Сибирия ханлыгы, урыны, чикләре, ханнары, русларның Сибирия берлә танышулары, Ермак кем булган, Күчүм хан, Күчүм ханның Сибирияне агартырга тырышуы, руслар берлә сугыш, Сибириянең Русиягә кушылуы.

Монда кадәр язылган төрки кавемнәрнең хәзерендә калдыклары.

Төрекләр вә гарәпләр. Ислам гарәпләренең төрек җирләренә керә башлаулары, Күлтәкин һәм Билкә каханнар, алар исеменә утыртылган һәйкәлләр.

Төрекләрнең ислам хәлифәләренә сыенып әмирлекләр тәшкил итүләре, газнәвиләр, сәлҗүкиләр, сәлҗүкиләрнең бүленгәләве, Иран сәлҗүкиләре вә Алып Арслан, Хөрасән сәлҗүкиләре вә Мәлкәшаһ, сәлҗүкиләр һәм сәлҗүкиләрнең соң көннәре, Госманбәк вә Төркия хөкүмәтенең тәшкиле, уйгурлар.

Кыргыз-казах атала торган төркиләр, соң вакытларда алар арасында булган фетнәләр, Русия тәхете астына керүләре.

Төрки кавемнәренә гомумән бер назар, төркиләрнең мәгыйшәт [яшәү] рәвешләре, мәдәният, игенчелек, сәүдә вә тиҗарәт.

Төркиләрдә сәнәгать, язу, калма әсәрләр [ядкәрлекләр].

Хөкүмәт, хакимнәр, хөкүмәт низамнары, гаскәриләр.

Гыйлем, мәгарифтә дәрәҗәләре, электә һәм хәзергедә төрекләрнең диннәре. […]

СӘНӘВИЙӘ. ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФ

[…] Гомуми тарих (2 дәрес) [3].

[…] Төрек [төркиләр] тарихы: Туран кавемнәре дип кемнәргә әйтелер, Төркиләр кемнәр? Төркиләрнең борынгы гасырлардагы әхвәле хакында чыганаклар. Бу чыганакларның аз булуының сәбәбе. Төрек [төркилек] тарихыны вөҗүдкә чыгарыр өчен ни кирәк? Төрекләрнең [төркиләрнең] төп чыгышлары. Чыганакларны чагыштыру васитасы илә төркиләр хакында мәгълүмат. […]

СӘНӘВИЙӘ. БИШЕНЧЕ СЫЙНЫФ

[…] Тарихе рус (1 дәрес). Русия дәүләтенең тәшкиле: Көнчыгыш Европаның табигый шартлары, борынгы иләте (население), славян кабиләләре, литвалылар, төрки кабиләләр, фин кабиләләре, норманнар, борынгы шәһәрләр, диннәре, әхлак вә гадәтләре, идарә вә тормышлары, славяннарның читтән кенәзләр дәгьват итүләре [чакырулары], греклар, хазарлар, печенеглар белән сугышлары.

Русиягә христиан диненең керүе: князь Владимирның христиан динен кабул итүе, Русиядә язу вә мәгарифнең башлануы, Владимирның балалары, Ярослав Мудрый, беренче мәктәпләр, Рус тугрылыгы (Русская Правда).

Русиянең уделларга бүленүе: кенәзләр, Ярослав Мудрыйның токымнары заманында кенәзләр арасында олуг кенәзлек тәхете өчен көрәш, Владимир Мономах, кыпчак кабиләсе белән сугыш. Юрий Долгорукий белән Изяслав арасында Киев өчен талаш-тартыш, Суздаль җире вә Андрей Боголюбский.

Төньяк Русиянең күтәрелүе: Новгород җире, Новгород шәһәре, кенәз, идарә, сәүдә, колонияләре, Суздаль кенәзләре белән сугышлары, Ливонский Орден, татар хакимлегенә кадәр Русиянең эчке әхвәле, сәнәгать, мәгариф, тиҗарәт [сәүдә].

Русиядә татар дәвере: татарлар, Чыңгыз хан, аның Азиядә бөтен төрек кабиләләрен басып алуы, Кытай вә Иран сугышлары, Чыңгыз гаскәренең Русиягә килүе. Батый ханның Русиягә һөҗүме, Алтын Урда ханлыгының тәшкиле, Александр Невский, Галиция кенәзлеге вә Литва.

Мәскәү кенәзлеге. Иван Калита, Алексий вә преподобный Сергий [Радонежский], Димитрий Донской, Куликово сугышы, Алтын Урданың бетүе, 3 нче Иван вә уделләрнең бетүе, Новгородны басып алу, русларның татар хакимлегеннән чыгулары.

4 нче Иван, Казан ханлыгын басып алу, беренче матбагa [типография], Әстерхан ханлыгын Русиягә кушуы, Себер ханлыгы вә аның Русиягә кушылдырылуы, көнбатыш (гареб) белән мөнәсәбәт, Ливония сугышы, Ливонский орденның бетүе, Рюрик нәселенең киселүе.


اوچنچی جلد بشنچی سان اوچنچی یل میمون (میچن) یلی

انّ الدین عند الله الاسلام

بو سنه ربیع اول باشی پنجشنبه مولد نبی علیه السلام اون ایکنچی کونی دوشنبه کونیدر الله تعالی هر بنده گه دین محمدی برابرنده شکر نصیب ایلیه.

الدین والادب

سنه ۱۳۲۴ نامنده ۵ صفر الخیر

آیده ایکی مرتبه نشر ایدلور

مجلهٔ اسلامیه در

سنه ۱۳۲۶ غرهٔ ربیع الاول
۱۹۰۸ ۱۹ مارت

محرر وصاحب امتیازی :
ملا عالمجان البارودی.

خاریطونوف مطبعه‌سی
قزان.

Лито-Типографія И. Н. Харитонова. Казань

«Әдип вәл-адәб» журналының титул бите
(1908, 19 март, Казан: Харитонов матб.)

Дәрес китабы: Острогорскийның «Русия тарихы» исемле китабыннан тәрҗемә ителеп укытыла. [...]

СӘНӘВИЙӘ. АЛТЫНЧЫ СЫЙНЫФ

[...] Рус тарихы (1 дәрес). Русиядә үзгәрешләр дәвере. Борис Годунов вә аның падишаһлыкка сайлануы, вә аның падишаһлыгы. Беренче [Ялган] Димитрий, Шуйский, Тушин карагы, Мәскәүгә читләрнең һөҗүменнән коткару. Минин вә Пожарский, Михаил Фёдоровичны падишаһлыкка сайлау.

Романов нәселенең падишаһлыгы. Михаил Фёдоровичның падишаһлыгы, Алексей Михайлович. Алексей Михайловичның закон мәҗмугасы ясатуы, Малорусиянең Русиягә табигъ булуы.

Пётр Великий вә аның тәрбиясе, Азов сугышлары, Европага сәяхәте, Төньяк сугыш кыры, Полтава җиңүе, реформалары, Петербургны төзү, Пётр Великийның дәвамчылары.

Екатерина Икенче, эчке реформалар, Төркия белән сугышлар, Польшаның бүленүе, Павел, Суворовның Италия вә Швейцариягә сугышка баруы.

Александр Беренче, Ватан сугышы, Николай Беренче, Төркия белән сугышлар, Польша ихтилялы [восстаниесе].

Александр Икенче вә аның реформалары, Кавказ вә Төркестан ханлыкларын басып алуы, крестьяннарны азат итүе.

Александр Өченче вә аның дәври [вакытлы] хөкүмәте.

Дәрес китабы: Острогорскийның «Русия тарихы» исемле китабыннан тәрҗемә ителеп укытыладыр. [...]

ГЫЙЛӘВӘ [ӨСТӘМӘ]

1. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия». Асылы вә башлангычы мәгълүм булмаган заманнан бирле дәвам итеп гыйлем хадимнәре вә байларның инициативасы вә иҗтиһатлары сәясендә [аркасында] бу көнге хәленә ирешмеш бер мәдрәсәи диниядер.

2. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең тәэсис ителүеннән [нигезләнүеннән] асыл максуд – милләтемез өчен зарур булган дин һәм гыйлем хадимнәре, мөдәррис вә мөгаллимнәр, имам вә мөәзиннәр җитештерүдер. Бинаән галәйһи [югарыда әйткәнебезчә], «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дә якынча бербөтен гасырдан бирле – һәрвакытта да бер тәртиптә булмаса да – укыла килгән дәресләр һәркаюсы шәригатебез тарафыннан йә фарыз вә йә лязем, яки яхшы нәрсә вә хупланмыш диелгән; шәригать гыйлемнәре вә тормышта кирәкле фәннәрдер.

3. 1300 [һиҗри] сәнәдән [елдан] бирле [1882] мәдрәсә һәр ел әкренләп рациональләштерү вә яхшырту юлына куелып, утыз сәнә кадәр дәвам иткән тәҗрибәләрнең нәтиҗәсе буларак, бу сәнә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең ибтидаия, сәнәвийә вә галия исемнәрендә 3 кыйсемгә [өлешкә] бүленүе мәслихәт күрелде.

4. Ошбу кыйсемнәрдә [өлешләрдә] гыйлем вә дәрес бирү илә мәшгуль булган мөдәррис вә мөгаллимнәргә, шулай ук танышырга һәм файдаланырга теләгән шәкерт вә мөгаллимнәргә кулланма булачак бер программаның төзелүе тиеш табылып, ошбу программа нәшер ителде.

5. Бу кыш программада куелган укытылу материалы буенча дәресләр, ибтидаия [башлангыч], алтынчы сыйныф вә галия [югарыгы] икенче, өченче сыйныфлардан башкаларында дәвам итмәктәдер. Мәзкүр калган

сыйныфларда да, иншаллаһ, киләчәк сәнәләрдә гамәлгә куелыр.

6. Хәзер дә программага дәхеле булмаган [кертелмәгән] вә шәригатемезчә хуплану гына түгел, вә бәлки тиешле дип хисап ителгән һәм тыйбб [медицина], астрономия, алгебра вә табигать гыйлеме кеби бәгъзе кирәкле фәннәр хәл вә вакытның мөмкинлек бирүенә карап, хосусый [фәннәр] буларак укытылачак.

7. Ошбу программада күрсәтелгән дәрес материалы күләмендә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»не хәтем иткән [тәмамлаган] яшь руханиларыбыз үз алларына мәгълүматларын киңәйтү вә тирәнәйтү өчен һәртөрле васитага малик [ия] булсалар кирәк дип зан [ышаныч] кылынадыр. Гарәп телен белү илән ислам гыйлеменең чыганагы вә мәгълүмат башы булган текстларны файдалана вә сылтама ясый алулары, аз булса да рус теле өйрәнү илән гыйлемләрен кабатлау, бигрәк тә дин гыйлеме хакындагы яңа әсәрләрне, мәдрәсәдән аерылгач булса да, махсус өйрәнеп белергә муафыйк булулары тәэмин ителә.

8. Галия кыйсмендә [өлешендә] укырга муафыйк булмаган, ялгыз сәнәвийәне тәмам кылып чыккан шәкертләрнең имам вә мөгаллим булыр өчен тиешле булган шәригать гыйлемен вә дөньяга кирәкле фәннәрне күргән булулары, үз алларына мәгълүматларын киңәйтү өчен җитәрлек дәрәҗәдә белем базасына ия булулары өмет ителәдер.

9. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә кабул ителгән шәкертләрнең мәдрәсәнең дәресе укыла башлаган көннән каникулларгача җәдвәлләрдә (расписаниеләрдә) күрсәтелгән дәресләрнең һәркаюсына дәвамлы катнашып, уку елы ахырында һәрбер дәрестән имтихан бирүләре лаземдер. Имтихан идарә тарафыннан тәгаен кыйлынган махсус имтихан комиссиясе илә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең үзендә башкарыла. Еллык имтиханда һәркаю дәрестән «2»дән югары дәрәҗә алган шәкерт кенә сыйныф ашырыладыр. Әгәр алган дәрәҗәләре эчендә «2»лек дәрәҗәләре өч данә яки өчтән ким булса, шәкерт шул дәресләреннән өстәмә укуга калган хисап ителеп, көзен өстәмә уку имтиханы соңында тиешле дәрәҗә алыр исә генә укыган сыйныфыннан күчерелер. Сәнәви [еллык] имтиханда алган дәрәҗәләре [билгеләре] эчендә «2»лекләре өч данәдән артык өстәмә укуга калган дәресеннән көз көне имтихан соңында тиешле дәрәҗә казана алмаса, ул шәкерт бөтенләй сыйныфта калдырылыр.

10. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» идарәсе үзендә торган шәкертләренең әхлак вә дәресләренең әхвәлен тәрбиячеләренә [ата-анага] белдерүне тиеш табадыр. Шуның өчен һәр сәнә кыш ахырында була торган гомуми имтихан шәһадәтнамәсе илә генә канәгать итмәй, кыш эчендә дә берничә тапкыр шәһадәтнамәләр [табель] биреп [тәрбияче ата-аналарын] хәбәрдар итәдер.

11. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең галия сыйныфларын тәмам иткән шәкерт низам буенча мәдрәсәне тәмамлаган хисап ителер вә горефчә хәтме көтеп кыйлыныр [укуын тәмамлады, диелеп] мәдрәсәнең камил шаһәдәтнамәсенә лаек булыр. [...]

Искәрмәләр:

1. Текст «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе» (Төзүчеләр Н.Г.Ханзафаров, Р.У.Әмирханов, Р.Г.Әхмәтҗанов. – Казан: Мәгариф, 1998. – Б.32-93.) китабыннан кыскартып алынды.
2. Бары тик төрки-татар һәм Россия тарихы дәресләренең генә эчтәлеге бирелә, ә дини һәм дөньяви фәннәрнең эчтәлекләре, шул исәптән, тарихе исламия, тарихе әнбия (пәйгамбәрләр), гомуми тарих фәннәре төшереп калдырыла.
3. Монда төркиләрнең тарихы гомуми тарих фәне кысаларында укытыла.

ГАБДРАХМАН ФӘХРЕДДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

МИЛЛИ МУЗЕЙ ПРОЕКТЫ

ПУБЛИЦИСТ, МӨХӘРРИР ҺӘМ ТӘРҖЕМӘЧЕ ГАБДРАХМАН ФӘХРЕДДИНОВ (1887-1937) — ИСЕМЕ ҺӘМ ИҖАТЫ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР УКУЧЫСЫНА БИК АЗ БИЛГЕЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРСЕ. Ә БИТ БУ ШӘХЕС ӘТИСЕ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИНОВ БЕЛӘН XX ЙӨЗ БАШЫНДА ИҢГӘ- ИҢ КУЕШЫП ИҖАТ ИТКӘН, ӘТИСЕННӘН ГЫЙЛЕМ, ИЛҺАМ АЛЫП, АНЫ ТАГЫН ДА ЮГАРЫРАК ҮСТЕРГӘН, ТАТАРЛАР ӨЧЕН РУС ҺӘМ ЕВРОПА ӘДӘБИЯТЫНА ТӘРӘЗӘ АЧКАН.

Ризаэддин Фәхреддин гаиләсендә 6 бала исән-сау үсеп җитәләр. Алар — Габдрахман (1887), Габделәхәт (1889), Габдеррәшит (1892), Зәйнәп (1893), Сәгыйть (1900), Әсма (1906). Габдрахман Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы авылы хәлфәсе Ризаэддин бине Фәхреддин гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә [1]. Р.Фәхреддин 1889 елны Кичүчат авылына кайтып, берничә айдан гаиләсе белән имам һәм мөдәррис буларак Илбәк авылына, ә Диния нәзарәтенә казый итеп билгеләнгәч, гаилә Уфага күченә [2]. Габдрахман Фәхреддин иң әүвәле әтисеннән гыйлем ала, аннары Оренбург каласындагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый, 1904 елда тиз арада Уфа шәһәренең дүртеллык рус училищесын тәмамлый. 1905-1906 елларда Семипалатинск шәһәрендә мануфактура кибетендә приказчик булып эшли [3]. 1906 елда

1.Фәхреддин Р. Тәрҗемәи хәлем: Ризаэддин хәзрәтләре Фәхреддиннең 150 еллыгына багышлана. / Р.Фәхреддин. — Казан: «Иман» нәшрияты, 2009. — Б.70.

2. Шунда ук. — Б.67-68.

3. Шараф А. Сведения о детях Ризаэтдина Фахреддина // Ризаэддин Фәхреддин: Фәнни-библиографик җыентык = Ризаэддин Фәхреддинов: Научно-биографический сборник / Төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. — Казан: «Рухият» нәшрияты, 1999. — С.189.

Габдрахман Фәхреддинов хатыны белән. Оренбург. 1912 ел.
Фото «Мемориальный музей Ризаэддина Фахретдинова» альбомыннан

Оренбург каласында бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр наширлегендә «Вакыт» газетасы дөнья күрә башлый. Рәмиевләрнең чакыруы буенча, 1906 елның май аенда Ризаэддин Фәхреддин гаиләсе белән Оренбургка күченә. Аталы-уллы Ризаэддин һәм Габдрахман Фәхреддиннәр шушы әдәби, сәяси газетада хезмәт итә башлыйлар [4]. Дөрес, Р.Фәхреддин 1908

4. Шәрәф Ә. Әткәем турында истәлекләр // Ризаэддин Фәхреддин: Фәнни-библиографик җыентык=

«Вакыт» газетасы редакциясендә (сулдан өченче – Габдрахман Фәхреддинов).
Фото «Мемориальный музей Ризаэддина Фахретдинова» альбомыннан

елдан бертуган Рәмиевләр наширлегендә дөнья күрүче «Шура» журналының баш мөхәррире вазифасын башкаруга күчә. Әтисе Ризаэддин Фәхреддин ун ел буе (1908-1918) «Шура» журналының мөхәррире булып эшләсә, улы Габдрахман ун ел дәвамында (1906-1916) танылган татар журналисты Фатих Кәрими мөхәррирлегендә дөнья күргән «Вакыт» газетасының җаваплы сәркатибе, аннары икенче мөхәррире булып хезмәт итә. Р.Мәрданов тикшеренүләренә караганда, Г.Фәхреддиннең 1914 елның 14 мартында бирелгән шәһадәтнамәсе нигезендә әтисе, «Шура» журналы мөхәррире Р.Фәхреддин авырып яки башка сәбәпләр белән мөхәррирлек вазифасын башкара алмаса, 2 нче мөхәррир буларак, бу вазифаны башкару хокукы булган. Әмма, 1916 елның 16 ноябреннән 2 нче мөхәррирлек вазифасы Җамал Вәлидигә тапшырылган [5]. Габдрахман Фәхреддин 1916-1918 елларда армиядә хезмәт итә [6].

Революциягә кадәр Габдрахман Фәхреддиннең мәкаләләре «Вакыт» газетасында һәм «Шура» журналында басылган. Аның «Вакыт» газетасында эшчәнлеге әле җентекләп тикшерүне сорый. Безгә аның «Вакыт» газетасында күренекле татар галиме, татарлар арасында авыл хуҗалыгы әдәбияты таратучы, тәрҗемәче, галим Ибраһим мирза Вәлиулла улы Терегуловның 30 еллык гыйльми хезмәтенә багышланган мәкаләсе мәгълүм. Бу әсәр 1908 елда китап буларак та басылып чыга [7]. Шул ук

Ризаэддин Фәхреддинов: Научно-биографический сборник / Төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. — Казан: «Рухият» нәшрияты, 1999. — Б.49.

5. Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре. — Казан: Рухият, 2001. — Б.57.

6. Шараф А. Указ. соч.

7. Фәхереддинов Р. Тәрҗемәи халь вә табакат китаплары (Русия мөселманнары тарафыннан тәртип

елда «Фәлсәфәдән бер кыйтга: яшьләребездә дин вә монизм» исемле хезмәте дә Оренбург каласында Кәримов, Хөсәеновлар матбагасында дөнья күрә [8].

Авторның «Шура» журналында 5 мәкаләсе басылып чыга [9]. Алар — «Милли музәханәбез» (1909. — №5. — Б.146-147), «Мәскәү дарелфөнүне» (1910. — №3. — Б.93-94), «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хәдисләр» рубрикасы астында рус классик әдибе Граф Лев Николаевич Толстой (1910. — №23. — Б.705-706, №24. — Б.737-739, 1911. — №1. — Б.1-4), һинд шагыйре Рабиндранат Тагор (1913. — №23. — Б.708) һәм шәрык белгече Г.Н.Перовскийлар (1909. — № 7. — Б.213-215) турында мәкаләләр.

Революциядән соң Габдрахман Фәхреддинов Уфа шәһәрендә гаиләсе белән яши. «Башкортстан хөкүмәте теле», «Башкортстан», «Яңа авыл» газеталары редакцияләрендә эшли, дәреслекләр, фәнни әдәбиятларны рус теленнән башкорт, татар телләренә тәрҗемә итә, төрле дәүләт оешмаларында тәрҗемәче була. Ул 1936 елның 14 нче июлендә репрессияләнә, ә 1937 елда төрмәдә вафат була [10]. Әлеге шәхеснең эшчәнлеге турында кыскача булган мәгълүматлар менә шулар.

Габдрахман Фәхреддинов фәнни һәм тәрҗемә эшендә тулысы белән диярлек әтисе Ризаэддин Фәхреддин традицияләрен дәвам итә, аның рухында яза. Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителгән «Милли музәханәбез [музеебыз]» исемле мәкаләдә публицист милли музей оештыру, тарихи-мәдәни истәлекләрне музейларда туплау, саклап калу һәм киләчәк буынга җиткерү мәсьәләләрен күтәрә. Бу мәкаләдә китерелгән мисаллар XX йөз башында татар халкының милли үзаң үсешен, милли тарихны өйрәнүгә һәм пропагандалауга ихтыяҗның зурлыгы турында сөйли. Бу проект, кызганычка каршы, тормышка ашмый кала. Ризаэддин Фәхреддиннең 1916 елда иске әйберләрне, китапларны саклар өчен бер генә гомуми китапханә һәм музей булмавы турында ачынып язуы мәгълүм [11].

МИЛЛИ МУЗӘХАНӘБЕЗ

«Вакыт»ның үтмеш номерларының берсендә милли тарихыбызның нигезе вә халкыбызда милли хиснең үсүе өчен иң кирәкле нәрсәләрнең бере — милли музәханә ачмактыр, димеш идем. Дөресен әйткәндә, моны инкарь итә алучы табылмас.

Мин ул мәкаләне язган чагымда: «Иртәрәктер әле, халык аңа җитешмәгән. Шул сәбәпле тавышым сахрада калыр», — дип курыккан идем. Халкыбыздагы авырлык, хиссезлек, кирәкне исәпли, исәпләгәнне сөйли вә сөйләгәнне эшли белмәү — хакыйкатьтә, һәрбер яңа эш тәклиф итүчене [эшкә керешүчене] куркытырлык, кул селтәтерлек дәрәҗәдәдер.

ителгәннәре) / Р. Фәхреддинов // Шура. — 1915. — №2. — Б.45.; Фәхреддинов Г. Ибраһим мирза Терегуловның 30 сәнәлек хезмәт гыйлмиясенә ядкәр / Г.Фәхреддинов. — Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәс»нең паровой матб., 1908. — Б.16

8. Әхмәтҗанов М. Габдрахман Фәхреддинов // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиографик сүзлек. — Казан, 2005. — Б.210.

9. Госманов М.Г., Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. — Казан: Милли китап, 2000. — Б.251.

10. Шараф А. Указ соч.

11. Фәхреддин Р. Иске әсәрләрне саклау хакында. — Шура. — 1916. — №16. — Б.387.

12. Биредә сүз 1753 елда врач, натуралист Ганс Слоан, сәясәт эшлеклесе граф Роберт Харли, антиквар Роберт Коттон коллекцияләре

Ләкин курыкканым ул кадәр булып бетмәде. Бу эшнең вакыты җиткәнлеге, аны кирәксенгән вә исәпләгән кешеләрнең барлыгы аңлашылды. Бу мәкалә басылып чыгар-чыкмас, кыргыз сахрасы эчендәге бер Кустанай приказчигы шатлана-дәртләнә кулыннан килгәнне ачылачак музәханәгә берникадәр матди ярдәм илә бераз кыргыз нәрсәсе табып җибәрә алу мөмкин идеген вә шул хезмәтне шатлык илә өстенә алачагын бәян итә. Бер Каргалы мелласы иске нәрсәләр эзләп йөри башлый. Бәләбәй өязенең бер яшьрәк мелласы: «Милли музәханәбезне күреп үлү насыйп булыр микәнни?» — дип сорый. Ерак Читадан бер татар: «Казан вә Оренбург яшьләре бу эшне тизрәк мәйданга чыгарсыннар иде», — дип яза. Әстерханның «Идел» газетасы милли музәханәнең фәүкыйльгадә [гадәттән тыш] кирәк бер шәй булдыгын исбат илә бәрабәр, мәкаләне үзгәртмичә күчерә.

عدد ٥ — شورا — صحيفه ١٤٥

ملی موزه خانه‌مز .

«وقت» نڭ اوتمش نومرلرینڭ برسنده ملی تاریخمزنڭ احیاسی و خلقمزده ملی‌حس‌نڭ اوسوی ایچون الڭ کرکلی نرسه‌لرنڭ بری «ملی موزه خانه» آچمقدر، دیمش ایدم. ظن ایدرسه‌م، ــ بونی انکار ایته آلوچی تابلماس.

مین اول مقاله‌نی یازغان چاغمده: «ایرته‌ره‌کدر ئلی. خلق آڭا یتشما گان. شول سببلی طاوشم صحراده قالور، ایشتلماز» دیه قورقغان ایدم. خلقمزده‌غی آورلق، حسسزلك، کرکنی ایسابلی، ایسابله‌گاننی سویلی و سویله‌گاننی اشلی بلماو حقیقتاً هر بر یاڭا اش تکلیف ایتوچینی قورقتورلق، قول سلته‌تورلك درجه‌ده‌در.

لکن قورققانم قدر بولوب بتمادی. بو اشنڭ وقتی یتکانلگی، آنی کرکسنگان وایسابله‌گان کشیلرنڭ بارلغی آڭلاشلدی. بو مقاله باصیلوب چقار چقماس، قرغیز صحراسی اچنده‌گی بر «قوستانای» پریقاشچیغی شادلانا، دردله‌نه؛ قولندن کیلگانی ـ آچیلاچق موزه‌خانه‌گه بر آز مادی یاردم ایله بر آز قرغیز نرسه‌سی طابوب یباره آلو ایدیکینی و شول خدمتنی شادلق ایله اوستینه آلاچغینی بیان ایته؛ بر قارغالی ملاسی ایسکی نرسه‌لر ازله‌ب یوری باشلی؛ بلبه‌ی اویازی‌نڭ بر یاشرك ملاسی: «ملی موزه خانه‌مزنی کوروب اولو میسر بولور میکاننی؟» دیب صوری؛ یراق چیتادن بر تاتار: «قزان و اورنبورغ یاشلری بو اشنی تیزرك میدانگه چغارسونلر ایدی» دیب یازه.

استرخان‌نڭ «ایدل» غزته‌سی ملی موزه خانڭ فوق العاده کرك بر شی اولدیغنی اثبات ایله برابر مقاله‌منی عینا کوچره.

ئه بونی کرکسنوب ده سویلی آلماغانلر یا که سویله‌بده سوزلری بزگه ایشتلماگانلر نه قدردر؟ ....

میڭا بو حقده کیلگان خطلرنڭ بر نیچه‌سنده «ملی موزه خانه کرك نرسه ـ اشانامز. لکن آنی آچوب بولورمی؟ آڭا نرسه تابلورمی؟ بزده آثار عتیقه بارمی؟» دیب صوریلر.

کتبخانه آچوب بولغان کبی موزه خانه ده آچوب بولا. مسلمان جمعیتی کتبخانه آچا، شولایوق «مسلمان تاریخ جمعیتی» اوزینه بر موزه خانه ده آچا آلا (قزان ترقیپرور بای بتچه‌لرندن ایکیسی‌نڭ تاتار تاریخ جمعیتی آچلسه آڭا بر مڭ صوم اعانه وعده قیلدیقلری تلده یوری. درستمیدر، بلمیم). نرسه ایسه بیك کوب تابیلاچقدر.

موزه خانه‌لرنڭ نه روشده اوسدیکلرینی کورساتور ایچون دنیانڭ الڭ زور موزه‌سی اولان «لوندون» موزه‌سن کورساتو یته‌ر. بوندن ١٥٠ بیل ایلك لوندونده بر انگلیز بایی، اوزنده صاقلانغان ٤٠ مڭ صوملق یازمه کتاب و کاغدلرنی هم رسملرنی صاقلار ایچون بر کچکنه‌گنه یورتده «موزه خانه» آچقان و بونی تاریخ محبلرندن بر کامیسیه قارامغینه تابشرغان، بو کامیسیه موزه خانه‌گه قارارغه کروچیلردن جیغان اون تینلرگه، شهر اداره‌لرندن وخصوصی آدملر طرفندن بیرلگان اعانه‌لرگه تورلی ایسکی نرسه‌لر جیا باشلاغان. کوب مشهور آدملر اوزلرینڭ اسملرن خلقغه قالدرو ایچون یازغان کتابلرن، دفترلرن، قزقلی نرسه

Г.Фәхреддиновның «Милли музәханәбез» мәкаләсенең 1 нче бите

Ә моны күрсәтеп тә сөйли алмаганнар, яки сөйләп тә сүзләре безгә ишетелмәгәннәр никадәрдер?

Миңа бу хакта килгән хатларның берничәсендә: «Милли музәхана кирәк нәрсә, ышанабыз, ләкин аны ачып булырмы? Аңа нәрсә табылырмы? Бездә асаре гатика [археология, иске заман әйберләре] бармы?» — дип сорыйлар.

Китапханә ачып булган кеби музәханә дә ачып була. Мөселман җәмгыяте китапханә ача, шулай ук мөселман тарих җәмгыяте үзенә бер музәханә дә ача ала. (Казан тәрәккыйпәрвәр байбәтчәләреннән икесенең татар тарих җәмгыяте ачылса, аңа бер мең сум иганә вәгъдә кылдыклары телдә йөри. Дөресмедер, белмим.) Нәрсә исә бик күп табылачактыр.

Музәханәләрнең ни рәвештә үстекләрен күрсәтер өчен дөньяның иң зур музей булган Лондон музеен күрсәтү җитәр. Моннан 150 ел элек Лондонда бер инглиз бае үзендә сакланган 40 мең сумлык язма китап вә кәгазьләрне һәм рәсемнәрне саклар өчен бер кечкенә генә йортта музәханә ачкан вә моны тарих

нигезендә оешкан Лондондагы Британия музее турында бара.

13. Хәсән Тимербулат улы Акчурин (1855-1916) — Сембер фабриканты, татар халкы тарихи истәлекләрен, кулъязма китапларны һәм нумизматика чыганакларын туплаучы коллекционер.

14. Дибердиевлар танылган татар морзала-

мөхибләреннән [сөючеләрдән] бер комиссия карамагына тапшырган. Бу комиссия музейны карарга керүчеләр җыйган ун тиеннәргә, шәһәр идарәләреннән вә хосусый адәмнәр тарафыннан бирелгән иганәләргә төрле иске нәрсәләр җыя башлаган. Күп мәшһүр адәмнәр үзләренең исемнәрен халыкка калдыру өчен язган китапларын, дәфтәрләрен, кызыклы нәрсә вә киемнәрен шунда бирергә васыять итеп үләләр икән [12].

1909 елның гыйнварендa бу музейның ачылуына 150 ел тулды. Хәзер моның мисалы дөньяда юк, төрле адәмнәр тарафыннан һәдия [бүләк] ителгән йөз миллионлы асаре гатикадан [борынгы әйберләрдән] вә башка нәрсәләрдән тыш, акча илә сатып алынган нәрсәләре генә 60 миллион сумлыктыр. Ялгыз китаплары гына ике миллион җилдтән [томнан] артык булып, ел саен 50 мең төрле китап арта бара.



«Шура» журналының титул бите. 1909 ел, №5

Бездә дә асаре гатика [борынгы әйберләрне] мөхибләре [сөючеләр] бар. Малын, гомерен кызганмый иске нәрсә вә әсәр җыялар. Хәсән Акчурин [13] вә Дибердиевлардагы [14] китап, аеруча Ауропада матбуг [басылган] иске ислам әсәрләре илә язма китаплар әйтеп бетерерлек түгел. Хәсән Акчуринның иске акча, аеруча ислам акчалары коллекциясе шулкадәр бай ки, өстән генә карап бетерү өчен көннәр кирәк. Дөньяның иске ислам акчалары илә иң бай музәханәсе булган Петербургтагы Эрмитаж да (Мисыр падишаһларының җыеп килгән иске ислам әсәрләре вә акчалары хәзер моның кулына төшмештер) Хәсән Акчуриндагы иске акчаларның бик күбесенә малик [ия] түгелдер. Моның коллекциясендә гасыр сәгадәттән [Мөхәммәд с.г.в. һәм аның сәхабәләре заманы] әүвәлге фарсы акчаларыннан башлап, Габделмалик, Хиҗаҗ дәверләре, гарәп, төрек, Мисыр хәлифәләре вә татар ханнары акчалары — һәрбере дә диярлек бардыр. Казанның Мөхәммәдрәхим Юнысов кулында иске вә кыйммәтле әсәрләр бик күптер, «Хәзрәти Госман каны тамган» дип йөртелгән мосхәф шәрифнең [Коръәннең] бәгъзе кәгазьләре, Казан мөселман байларының Император Александр II [15] илә бергә төшерткән рәсемнәре вә башка бик күп надир [сирәк] шәйләр болар кулында [16]. Шиһаб хәзрәтнең [17] амбарларда череп ятмакта булган бөек җилдләрчә [томнарча] әсәрләре, телебездә чыккан барча китап вә газеталар,

ры нәселеннән. Ибраһим Дибердиев — «Икътисад» журналында авыл хуҗалыгы темасына караган мәкаләләр авторы. Йосыф Дибердиев — фабрикант, шагыйрь, хикәяләр һәм «Шура» журналында дини темага карган мәкаләләр авторы. Мөхәммәдкәрим Дибердиев — публицист, тәрҗемәче, мәкаләләре «Казан мөхбире» газетасында дөнья күрә.

15. Александр II — 1855-1881 елларда Россия императоры.

аларның асыл язма нөсхәләре, хәзерге халык хәдимнәребезнең [хезмәткәрләренең] вә мөхәррирләребезнең рәсме хат [кулъязмалары] вә рәсемнәре, иске киемнәр, иске өй әсбабы вә кораллар, башкорт вә кыргызларның нәрсәләре — һәрбере музәханә өчен зур байлык тәшкил итәчәкләрдер.

Ышанабыз ки, Акчурин вә Дибирдиев кеби асаре гатика мөхибләре [сөючеләре], гомер буенча сөеп җыйган нәрсәләренең үзләре соңгында таралып бетүен теләмәсләр вә башында ышанычлы кешеләр торган милли музәханәләрдә үз исемнәренә бүлемнәр ачып исемнәрен мәңгелек яд иттерүгә [хәтердә саклауга] каршы тормаслар.

Хәзер милли музәханә ачу өчен иң яхшы урыннар Казан илә Оренбургтыр. Чөнки боларның һәр икесендә тарих мөхибләре [сөючеләре] вә тарих җәмгыятьләре башында тора алачак, аларны йөртә алачак кешеләр бар. Һәр икесендә дә байлык бар, һәр икесендә дә алардан кызык табучылар бар. Мин казанлыларның бу хакта тик ятмаячакларын өмет итәмен.

Оренбургта милли музәханә ачып, аны тәрбия иттерергә имкян [мөмкинлек] бар. Мондагы Учёная архивная комиссиянең [18] рәисе доктор Попов, бу тарих җәмгыяте вә музәханәнең уставын ясап тасдыйк иттерергә [раслатырга] ярдәмләшергә вәгъдә бирде. Төркстан, Тургай областе, аеруча Үргәнеч харәбәләрендә күп йөреп, иске әсәрләр илә танышкан вә Төркстан асаре гатикасе хакында бер мең битлек бик мөһим бер әсәр язган, Оренбург гимназиясе мөгаллиме Кустания (аслы французлдыр) татар музәханәсе ачылуга бик яхшы күз илә карый вә ярдәмләшәчәген, һәм дә үзендәге иске нәрсәләрдән беразын моңа һәдия [бүләк] итәчәген миңа сөйләде.

Оренбург музәханәсе хөкүмәтнеке булдыгыннан, андагы һәрбер нәрсәне Петербургка алдырту ихтималы бар. Шул сәбәпле, тарих мөхибе [сөючесе] булган Оренбург руслары үзләрендәге иске әсәрләрне анда бирергә курка иделәр, шулардан берничәсе миңа, шул нәрсәләрдән татар музәханәсенә бирәчәкләрен аңлаттылар. Ниһаять, Учёная архивная комиссия рәисе, доктор Попов бер мөнәсәбәт илә миңа: «Безнең музәханәбездә ике-өч нөсхәле нәрсәләр, аеруча иске акчалар күп. Безгә аларның берсе генә кирәк. Урыныбыз тыгыз булганлыктан башка нөсхәләрне куя алмыйбыз. Шулардан беразын ачылачак музеегызга бирдермәк мөмкин булыр», — димеш иде.

Шушы сүзләрдән соң мин бу эшнең мәйданга чыга алачагына ышандым вә озакламый вөҗүдкә чыгар [барлыкка килер] дип өмид тә итәмен.

(Шура. — 1909. — №5. — Б.145-147)

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага
Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

16. Юнысовлар — Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре һәм хәйриячеләре.

17. Шиһабеддин Мәрҗани (1818-1889) — танылган татар тарихчысы, мәгърифәтчесе һәм дин эшлеклесе.

18. Оренбург гыйльми архив комиссиясе — 1887 елда Археология институты тәкъдиме белән генерал-губернаторның канцеляриясе архивын һәм башка оешмаларның архивларын тасвирлар һәм фәнни өйрәнер өчен оештырыла. Оешма архив белән бергә төбәкнең тарихын, этнографиясен һәм археологиясен өйрәнү белән дә шөгыльләнгән.

ТАТАР ИЛЕ

ЗӨЛФӘТ ХӘКИМ

Д.Бунтуков фотосы

Тагын ярсу хөкем сөрә күңелләрдә,
Идел өстен тибрәлдерә кыйбла җиле.
Әллә йөрәк, әллә өмет
Сулкылдыйдыр күкрәгемдә,
Уятырга ният итеп Татар илен.

Саклап килдек гасырлардан гасырларга
Бәгырьләрдә чәчәк аткан өмет гөлен,
Ул чәчәкләр ташны тишеп
Шытып чыга дастаннарда,
Мин ышанам, калкып чыгар Татар иле.

Табынам мин бүген һаман синең рухка,
Безнең көннәр ташу кебек шаулап килер.
Үткәннәрне генә түгел,
Киләчәгеңне сагынам,
Сагынам сине, бөек Татар иле!

Фото автор коллекциясеннән

ХАҖИ АБДУЛЛА ДУБИН,
журналист,
төбәкне өйрәнүче, филокартист

АЛЕКСАНДРОВ ПАССАЖЫ

КРЕМЛЬ УРАМЫНДАГЫ АЛЕКСАНДРОВ ПАССАЖЫ – XIX ЙӨЗНЕҢ СОҢГЫ – XX ГАСЫРНЫҢ 70 НЧЕ ЕЛЛАРЫНА КАДӘР КАЗАНЛЫЛАР ҺӘМ БАШКАЛАБЫЗ КУНАКЛАРЫНЫҢ ЯРАТКАН УРЫНЫ БУЛЫП, СОҢГЫ ЯРТЫ ГАСЫРДА ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮНЕ КӨТКӘН ТАРИХИ-АРХИТЕКТУРА ЯДКӘРЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ.

Пассаж күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәүдәгәр Александр Александров акчасына төзелгән. Ул булачак керемле урынга заманы өчен шактый зур сумма – 800 мең сум акча, мал-мөлкәтенең күп өлешен сарыф итә.

Проектлар конкурсында Петербург сәнгать акдемиясен яңа гына тәмамлаучылар, киләчәктә танылачак яшь архитекторлар Н.И.Поздеев һәм В.В.Суслов җитәкчелегендәге төркем җиңүгә ирешә. Төзелешне шушы шәхесләргә ышанып тапшыралар. Алар белән В.Сусловның өлкән һәм тәҗрибәлерәк курсташы – архитектор Генрих Бернардович Руш җитәкчелек итә.

Пассаж 1883 елның 8 ноябрендә ачыла. Ул – Россиядә барокко һәм модерн стилендә пассаж тибында төзелгән сирәк биналарның берсе. Бина Казан халкын, архитектура үзенчәлекләреннән кала, күпсанлы яңалыклары белән үзенә җәлеп иткән. Биредә Париждан кергән яңалык – калын пыяладан эшләнгән идән, һава белән җылыту системасы, хәтта лифт та булган. Казанлылар бирегә тагын моңарчы күрелмәгән «шәмсез яктылык»ны күрергә килгәннәр. Пассажны электр белән яктырту Германиядән китерелгән электрогенератор ярдәмендә башкарылган.

Бу затлы бина табыш китерү өчен кулай булып чыкмаган. Аны тәэмин итү кыйммәткә төшә һәм шул сәбәпле төзелеш өчен тотылган чыгымнарны каплау хыялыннан ваз кичәргә туры килгән. Пассаж бинасы хуҗасы өчен, бертуктаусыз борчу-мәшәкать тудырып, баш авыртуына әйләнгән. Тиздән А.Александров пассажны үзенең кыз туганы – генерал тол хатыны Ольга Александрова-Гейнска сата.

Яңа хуҗа башта бинаны фән-сәнәгать музеена бирергә тели, әмма бина әлеге максатка яраклы дип табылмый. Андрей Лихачёвның коллекцияләре һәм башка

шәһәр музее өчен җыелган экспонатлар Кәрван сарайга урнаштырыла. Ә пассаж керем китерә торган йорт булып кала бирә.

Пассаж эчендәге мәйданнарны кибетләр, остаханәләр, төрле идарәләр вакытлыча арендалый. Берара өченче катта татар китабын бастыру өлкәсендә шөһрәт алган Иван Николаевич Харитонов типографиясе эшли, ә 1908 елның декабреннән бу бинада Гирш Розенберг «Пассаж» электротеатры оештырып җибәрә. Нәзакәтлелегенә сокланып, аны «Казанның энҗе бөртеге» дип атаганнар. Театр турында шәһәр газетасы түбәндәгеләрне язган: «Гипслы экран — техникадагы иң соңгы яңалык. Купшы тирәлек, фонтаннар, фантастик барельефлар. Купшы мәгарәләр. Сеанс вакытында шәхси симфоник оркестр уйный. Пассажның галереясе кичке 11 сәгатькә кадәр ачык».

Шуның өстенә революциягә кадәр пассажда «Пале де Кристаль» дип исемләнгән танылган ресторан эшли. Безнең замандашларыбыз, мөгаен, аның алмашчысы — керү ишеге Ленин урамы яклап булган «Ял» кафесын — аның дәвамчысын хәтерли торганнардыр. 1930 нчы елдан пассажда «Пионер» балалар кинотеатры эшли. Шулай ук бинада яшәү өчен дә бүлмәләр булган. Бөек Ватан сугышы чорында пассаж диварлары йөзләгән эвакуацияләнгәннәрне кабул итә.

1977 елның 28 апрелендә бина җимерелә башлый. Ә берничә көннән бинаның Черек күл ягындагы блок дивары җиргә убыла.

Казан инженер-төзү тикшерүләре тресты белгечләре объектны өйрәнеп, җимерелү сәбәпләрен бинаның подвалын 1950 елдан даими рәвештә су белән батырылудан күрәләр.

1979 елдан фундаментны ныгыту эше башлана. 1981 елның 23 сентябрендә Пассажның исән калган өлеше республика күләмендәге тарихи һәм мәдәни ядкәр буларак дәүләт сагы астына куела. Аннары берничә мәртәбә бинаны төзекләндерергә омтылып карыйлар. Әмма өлешчә төзекләндерү эшләре 2003 елдан гына башлана. Эшне шәһәр төзекләндерү идарәсе заказы белән «Будимэкс» исемле Варшава шәһәре фирмасы алып бара. 2007 елның 29 августында Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты пассажны аукционга куя һәм Санкт-Петербург каласындагы «Балтийский банк» ААҖ компанияләре төркеменә 280,5 млн сумга сата. Яңа хуҗага бинаның тарихи йөзен, интерьерын саклау бурычы йөкләнә.

Хәзерге вакытта бина Петербургның «ПАН» (Петербург күчемсез милек агентлыгы) ЯАҖнә караган «Күчемсез милек һәм реконструкция» ҖЧҖ милкендә. Соңгы ел ярым вакыт эчендә бинаның эче чүп-чардан арындырылган, диварлары чистартылган, тәрәзәләре куелган, түбәсе ябылган. Оешманың җитәкчеләре вәгъдә итүенчә, бинаның фасады һәм түбәсе 2013 елның җәенә төзекләндереләчәк, ә тулысынча реставрация-төзекләндерү эшләре якынча 2-3 елдан тәгәлләнәчәк. Фасад реставрациясе проектының авторы — Фәридә Зәбирова. Белгечләр бинаның эчке һәм тышкы архитектура үрнәкләрен, орнаментларын тарихи фоторәсемнәр, документларга таянып тулысынча саклап калырга тырышалар. Киләчәктә Александров пассажын 5 йолдызлы кунакханә, ә астагы катлары ресторан һәм кафе булыр дип планлаштыралар. Кунакханәнең проекты танылган Петербург архитекторы Лидия Ухованың иҗади остаханәсендә эшләнә. Шулай ук бинада Санкт-Петербург каласыннан килгән 50 тәҗрибәле реставратор эшләячәк.

ӨМЕТ БЕЛӘН ЯЗНЫ КҮТЕП АЛДЫК

БИКӘ РӘХИМОВА

Өмет белән язны көтеп алдык,
Өмет безне алга карата.
Гүя апрель-егет май кызына
Бер йомарлам калган кар ата...

Бөртек кенә булса да ул өмет,
Куып җитә хыял артыннан,
Карлар китсә, сулар кипсәләр дә,
Кемнәр әйтер: «Хыял, — дип, — тынган?»

Өмет белән — яшел байрак белән
Килеп кердек ирек алырга,
Мәйдан исме-җисме бердер, диеп,
Күңелдәген әйтеп калырга.

Кечкенә лә йодрыгымны төйнәп,
Һава тиштем, даулап азатлык.
Ташкын булып минем халкым бара,
Ә халкымның хакы — тик хаклык...

Трибуналар — курку катыш ачу,
Йөзләре лә гүя газаплы...
Без бит кешенекен сорамыйбыз,
Без алырга тиеш азатлык!

بسم الله الرحمن الرحيم
كتاب فصلت آياته

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

Мин пәйгамбәр түгел, ә нигәдер
Күкләр миңа алдан сиздерә.
Пакь ураза аен тәмамларга
Уйламагыз быел тиз генә...

Рөстәм Мингалим

19 АВГУСТ — УРАЗА ГАЕТЕ

РАМАЗАН...

ӘНВӘР ХӘЙРИ,
галим һәм язучы

Бисмилләһиррахмәниррахим.

Мәгълүм булганча, Ислам диненең нигезен тәшкил иткән биш терәк — биш рөкен бар. Беренчесе — Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең — Аның илчесе икәнлегенә ышанып, иман китерү, ә калган дүртесе: намаз уку, ураза тоту, зәкәт (ягъни еллык керемнең 40 тан бер өлешен Аллаһ ризалыгы өчен бирү) түләү һәм хаж кылу. Рамазан аенда 30 көн ашау-эчү һәм башка төрле ләззәтләнүләрдән тыелып тору — гарәпләрдә Ислам дине иңгәнче үк булган. Мөхәммәд пәйгамбәрнең өйрәтүе һәм Мәдинә шәһәренең яһүд динен тотучы өстен катлау вәкилләре йогынтысы белән Ислам диненең иң башлангыч көннәрендә ун көнгә бер тапкыр ураза тоту (гашура) булган. Ләкин соңрак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәдинәдәге яһүд кабиләләре белән арасы суынгач, әлеге ун көнгә бер тапкыр тотыла торган һәм яһүдләрдән кергән бер көнлек ураза Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан үзгәртелеп, бер ай буена тотыла торган уразага әйләнгән. Рамазан ае — Ислам дине барлыкка килгәнче үк кулланылышта йөргән дүрт изге айның берсе булган. Шушы айда Мөхәммәд пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә аркылы Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәхи, ягъни Коръәннең эчтәлеге иңдерелгән һәм бу ай — айларның ае, ягъни иң

изге ай булып санала башлаган. Шуңа күрә ураза да, шул айга туры килеп, мөселманнар башкарырга тиешле иң зур бурычларның берсенә әверелгән. Һәр мөэмин мөселманның үтәргә тиешле, ягъни фарыз бурычлы икәнлеген күрсәтеп, ураза тоту турында Коръәни Кәримнең «Бәкарә» («Сыер») сүрәсенең 182 аятендә болай диелә: *«Йә әййүһәл-ләзинә әмәнү күтибә галәйкүмүс-сыямү кәмә күтибә галәл-ләзинә миң кабликүм ләгалләкүм тәттәкун»* («Әй, мөэмин бәндәләр, әүвәл замандагы мөэминнәргә фарыз кыйлынган кебек, диндарлыгыгыз артсын өчен, Рамазанда ураза тоту — сезгә дә фарыз кыйлынды»). Моннан тыш, ураза турында пәйгамбәребезнең бер хәдисе дә бар: *«Ликүлли шәйэин зәкәтүн вә зәкәтүл-җәсәдис-сыям»* («Һәрнәрсәнең бер зәкәте, ягъни пакьләүчесе була, ә тәннең зәкәте — ураза»).

Рамазан ае дәвамында тотылган зур ураза гарәпчә «саум», фарсыча «руза», төркичә «ураза» дип атала һәм аны буй җиткән, сау-сәламәт барлык мөселманнар да тотарга тиеш. Ураза тотудан йөкле, бала имезүче һәм авыру кешеләр, балалар, көчсез картлар һәм җитди сәбәбе булган кешеләр генә, мәсәлән, авыр эшләрдә эшләүчеләр, сугышта катнашучылар, сәяхәтчеләр азат ителә. Рамазан аенда тотылган ураза ел буе кылынган гөнаһлардан арынуның бердәнбер юлы. Шунысын да истә тотарга кирәк: христиан диненнән аермалы буларак, Ислам динендә Аллаһы Тәгалә белән кеше арасында арадашчылар юк. Ураза тотудан вакытлыча азат ителгән һәм уразасын ялгыш бозган кешеләр, Рамазан ае тәмамлангач, тотылмаган яки бозылган көннәр өчен уразаларын тотарга тиеш. Мәҗбүри тотылган уразадан тыш, ирекле ураза тоту да бар, алар нигездә рәҗәб, шәгъбан, шәүвәл һәм мөхәррәм айларында үтәлергә тиеш. Ике олы бәйрәмдә — Рамазан һәм Корбан гаетләре көнне һәм җомга көнне ураза тоту тыела.

Рамазан аенда ураза тотучы кояш баегач авыз ача, ягъни ифтар кыла. Гадәттә, ифтар кылырга туганнарны, якыннарны, күршеләрне һәм хезмәттәшләрне чакыралар. Авыз ачарга чакырып сыйлаучы мөэмин мөселман гөнаһларының ярлыкавына һәм урыны оҗмахта булуына өмет итә. Таң алдыннан сәхәр ашала. Авыз ачар алдыннан дога кылына, Коръәни Кәрим укыла. Аллаһы Тәгаләне һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламне искә алу турында да сөйләнелә.

Ураза тоту — кешедә булган көчле нәфесне тыяр өчен көчле бер чара. Ураза вакытында, мөселман кешесе, үзенең ихтыяр көчен бергә туплап, хайвани дәртләрдән арына һәм үзенең калебен чистарта, һәрнәрсәдән тыелып тору — кешене рухи пакьләндерүдә зур әһәмияткә ия. Ураза вакытында мөэмин мөселман тулысынча үзен Аллаһы Тәгаләгә багышлый. Бу ай — Коръәни Кәримнең ае, Изге Китапны уку мәҗбүри. Мөселманнар күп вакытларын намаз укып, мәчетләрдә вәгазьләр тыңлап, анда Аллаһы Тәгаләгә мәдхия укып һәм Аның ярлыкавын ялварып үткәрәләр. Авыз ачкач, тәравих намазын кылалар.

Аллаһы Тәгалә, ай буе ураза тотучыларга, Рамазан аеның ахырында — «Кадер кичәсе», гарәпчә «Ләйләтел-кадер» дип атала торган («язмыш хәл ителә торган төн», «көч-кодрәт төне») төнне бүләк итеп биргән һәм бу төндә изге гамәлләрнең әҗер-саваплары башка кичәләргә караганда бик күпкә артык. Бу төн — мөселманнар тарафыннан аеруча хөрмәтләнә. Әмма Аллаһы Тәгалә Рамазан аеның бу төнен мөселманнардан яшергән һәм



айның соңгы өч җөп төнендә (23, 25, 27) эзләргә кушкан. Кадер кичәсе хакында Коръәни Кәримнең «Сүрәтүд-дөхан» дип аталучы 44 сүрәсендә «ләйләтүл-мөбарәкә», ягъни «мөбарәк — кадерле, бәхетле, хөрмәтле төн», дип телгә алына. Бу төндә, бик мөһим мәсьәләләр хәл ителүгә ишарә ясалып, Коръәни Кәримнең «Сүрәтүл-кадри» дип аталучы 97 сүрәсендә *«Ләйләтүл-кадри хәйрүм-мин әлфин шәһрин»*, ягъни «Кадер кичәсе (төне) мең айга караганда да хәерлерәк», дип ассызыклап әйтелә. Бу төннәрдә һәртөрле могҗизалар, гаҗәеп хәлләр, вакыйгалар була, ә аларны күрү яки ишетү бәхетенә ирешкән кешеләрнең хыяллары тормышка ашырыла, язмышлары хәл ителә икән. Рамазан аеның бу төннәре йокламыйча, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылып чыга торган төннәрдән санала. Кадер төнендә Коръән Җәбраил фәрештә тарафыннан күкнең Җиргә иң якын катына күчерелгән һәм шуннан торып, аның эчтәлеге 22 ел дәвамында

Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән. Аллаһы Тәгалә нәкъ менә шушы төндә фәрештәләренә киләсе ел өчен алдан бөтен дөньяга һәм колларының язмышына кагылышлы күрсәтмәләрен өләшә. Аллаһы Тәгаләдән тәкъдир ничек булса, бөтенесе дә шулай булачак. Бу төндә Аллаһы Тәгаләнең әмере белән һәр вазифаны башкарырга сәләтле фәрештәләр җир йөзенә иңеп, таң беленгәнче кешеләрне һәртөрле бәлаләрдән саклап торалар.

Рамазан ае тәмамлангач, ислам диненең иң зур бәйрәмнәренең берсе — Ураза бәйрәме билгеләп үтелә. Мөселманнар Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынауны сабырлык һәм авырлык аша үтеп чыгуларын тантана итәләр. Бергәләп ифтар ашаулар, мәчетләрдә төнге намазны һәм тәравихны кылу аларны өммәт буларак туплый. Бәйрәм көнне барлык мөселманнар бергә җыелып, гает намазы укыйлар һәм бу намазда катнашу мөэмин мөселман кешегә мәҗбүри, гыйбадәттән соң Аллаһ ризалыгы өчен мәхәлләгә, ятимнәр, картлар йортларына, фәкыйрь-фөкарәгә йә акча, йә азык-төлек белән хәер-садака бирелә, туганнарның каберләре зиярәт кылына, аннан соң бәйрәм табынына утыралар. Моннан тыш, тагын ел саен, Диния нәзарәте карары белән билгеләнгән күләмдә, гаиләдәге һәр кеше исеменнән «фитыр зәкәте»н ихтыяри тапшыру каралган. Хәер өләшүне Мөхәммәд пәйгамбәр үзе васыять итеп калдырган икән. Ул бу хакта: «Аллаһы Тәгаләнең бәндәсе үзеннән тиешле хәерен бирми торып, Рамазан аенда тотылган ураза — Күк белән Җир арасында асылынып торыр», дигән. Кем өчендер бу Рамазан иң тәүгесе, ә кемдер өчен — соңгысы. Унбер ай буе ару-талусыз эшләгән тән һәм акыл — берлектә күңел хозурлыгына ирешеп тынычланып, пакьләнеп кала. Алар яңа сулыш ала. Рамазан аенда кеше белән Аллаһ арасы якынлаша, моның белән ул җәннәткә якыная. Бу үзе бер форсат һәм моны кулдан ычкындыру мөмкин түгел.

ӘДӘБИЯТ

Очрак чыгып,
Шигырь дәфтәремне актарсагыз,
Аннан...
Бервакытта да...
«Минем хыялларның хәрабәләре»,
дигән шигырь эзләмәгез.

Ростәм Мингалим

РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ 75 ЯШЬ

«МИН – ИДЕЛ КЕШЕСЕ»

ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН,
филология фәннәре докторы, профессор

Мин — Идел кешесе.
Бар узганым, киләчәгем белән.
Мин Иделгә
Бик еш киләм.
...Яратам Иделне.
...Һәрвакыт
Туасы язлар турында,
Үбәсе кызлар турында
Уйлана идем.
Шушында килсәм...
(«Мин — Идел кешесе»)

Һәр олы шагыйрьнең иҗат юнәлешен, кыйбласын, сурәтле фикерләү үзенчәлекләрен чагылдырган әсәре була. Ул иҗат юлы башында, тулпар атын иярләгән чорында, иң соңгы сагыш кылларын чиертеп ятканда туарга мөмкин. Р.Мингалим «Җиргә бер сүз» дип аталган программ шигырен 1965 елда, әле тәүге җыентыклары басылып чыкканчы (балаларга атап язылган «Әйт, Кояшым» һәм зурлар өчен «Эзләр» җыентыклары 1966 һәм 1967 елларда дөнья күрә) иҗат итә. Ни гаҗәп, биредә җиргә без күнеккәнчә турыдан-туры табыну да, үзенә җан биргән, кендек канын тамызган өчен, рәхмәт йөзеннән авызына туфрак тутыру да, чирәменә ятып аунау да юк. Аның каравы, «Җиргә бер сүз»дә яшь шагыйрьнең тормыш һәм яшәеш күренешләренә фәлсәфи-әхлакый бәясе, мөнәсәбәте һәм дөньяны образлы күрү үзенчәлекләре, шактый тулы ачыла; кеше гомеренең мәгънәсе, яшәү белән үлем арасындагы мәңгелек тар-

тыш, һәр җан иясенең бәхеткә хакы барлыкны раслаган, яклаган кануннар калкытып куела. Җирдә туып, җиргә кайту мәҗбүриятен бөтен гаҗизлеге белән аңлаган каһарман, Аллаһ тарафыннан бирелгән гомер кысаларында үз хокукларын дәгъвалаудан, Җиргә «син» дип эндәшеп, бөердән сөйләшүдән дә тайчанып тормый.

Кадер-хөрмәт күрсәталам диеп,
Кызыктырма минем күңелне.
Каберлекләр күрсәталам диеп,
Бозып торма минем күңелне.
Каберлекләр белән кадер-хөрмәт
Арасында эшем бар әле.

Язылачак җырларында халкына туры сүзен әйтү өчен, аңа вакыт һәм мәйдан кирәк икән: *«Әнкәй мине шушы төштә тапкан, Син шушыннан миңа мәйдан бир»*. Еллар агышын, вакытны туктатырлык көч булмаса да, җырларны теркәп куярдай дәфтәр бите һәрдаим ачык: яз да яз... Җир белән әле генә эре «сөйләшкән» лирик затның кояшны гына гүргә кертеп булмаганлыгын аңлавы тонны йомшартырга мәҗбүр итә, ул мәхәббәткә, назга сусаган гадәти адәм баласы да икән ич: *«Берәр ана, бәлки, Минем өчен кыз үстереп йөргәндер монда»*. Лирик каһарманның рухи дөньясындагы психологик кичешләрне нечкә күзәтү, магик сурәтләү чаралары ярдәмендә ачу дөньяның фанилеген, бер-березнең кадерен белү мәүзугын калкытып куярга мөмкинлек бирә. Җиркүк даирәләре белән кәперәебрәк сөйләшкән яшьлек максимализмына күз йоммастан, бу шигырьдә кешегә тирән ихтирам, аның язмышын, гадәти сөенечләрен йөрәк хисләре аша үткәрү, бәхетле киләчәккә ышану, үз хокукларын даулауда почмакларны әйләнеп үтә белмәү яки теләмәү — Р.Мингалимнең күпчелек шигырьләренең уртасыннан ярып барган мотивлар.

Р.Мингалим татар шигъриятенә 60 нчы елларда Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Г.Рәхим, Р.Гаташлар белән бер чорда килә. «Хрущев җепшеклеге» дип аталган җылы җилләр искән дулкында татар шигъриятенә язгы ташкын кебек килеп кергән буынны берләштергән уртак үзенчәлекләр байтак иде.

Остазларга, мираска яңача мөнәсәбәт. Уйлану киңлеге, кичереш тирәнлеге. Шәкелне төрләндерү, ритмик ачыклык, кыска мәйданда төгәлләнгән фикер әйтүгә омтылыш, метафорага өстенлек бирү алып килгән динамизм. Шагыйрь Гәрәй Рәхимгә багышланган «Без бер дөнья» шигырендә Р.Мингалим үзләренә мондый бәя бирә:

Безне аерым-аерым танып булмас,
Бер-беребезгә шундый охшаштык;
Теләкләребез дә, киемнәр дә,
Тиеннәр дә безнең тоташты.
Без — бер дөнья,
бер якадан тоткан
Ун бармаклы мифик кул төсле.
Без — бер дөнья
һәм шыр ачык дөнья,
Яңгыр астындагы кыр төсле.

Яшь сүз осталарын халыкка хезмәт итү теләге, шигырьне мәгънә һәм сурәтлелек яссылыклары җәһәтеннән яңарту, «эчтән шартлату» якынлаштырса да, бу шагыйрьләр һәркайсы кабатланмас шәхси көчкә ия шигъри шәхесләр буларак күтәрелделәр. Табигый сәләтләре ныгыган, көч вә куәт ала барган саен, хәзер татар поэзиясенең төп көчләре саналырга лаеклы буын вәкилләре арасындагы аерма ачыграк төсмерләнә барды, татар шигъриятенә яңа темалар, аһәңнәр, бизәлеш моңнары өстәлә торды.

Рөстәм Мингалим араларында яше белән иң өлкәне, тормышяшәеш мәктәбен узу микъдарыннан иң тәҗрибәлесе иде. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә килгәнче, ул

Бөгелмә авыл хуҗалыгы училищесын тәмамларга, Казахстанның Күкчәтау өлкәсендә тракторчы вазифасында чирәм җирләрне сөрергә, берничә ел «ипиле як» — Ташкент заводларында слесарь, станоклар көйләүче, янә Бөгелмәсенә кайтып, йөк ташучы, нефтьчеләрдә электр җиһазларын көйләүче булып эшләргә өлгерә. Әйтелгәнчә, «Эзләр» исемле беренче җыентыгы 1967 — университетны тәмамлаган елда укучыга ирешә, шагыйрьне хуплап, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Харис дәртле рецензияләре белән чыгалар.

Берничә елдан соң ул С.Хәкимнең игътибарына һәм хуплавына лаек була, ягъни олуг шагыйрьнең фатихасын ала («Әнвәр Давыдов эзе буйлап», 1971). Р.Фәйзуллин, Ш.Маннапов, Р.Миңнуллин, А.Хәлим кебек таләпчән каләмдәшләре гаҗәпләнү һәм сөенү хисләре белән уртаклашырга ашыгалар, Р.Мингалимне яңа чор эзләнүләр буразнасын ерып баручыларның берсе итеп таныйлар. Нәтиҗәсе гаҗәеп: аның шигъри дөньясы турында вакытында матбугатта язып чыккан чордашлары аннан алдарак Тукай премиясен дә алдылар, Татарстанның халык шагыйрьләре дә булдылар, «Сайланма әсәрләре»н дә чыгардылар. Шигърият каһарманы Р.Мингалим, мәгърур һәм башбирмәс Дон Кихот кебек, һаман тегермән канатларын әйләндерерлек җил чыкканын сабыр гына көтеп, ахыр чиктә лаеклы бүләкләрен алды.

Р.Мингалим — иҗаты гражданлык пафосы, дөньяга тәнкыйди карашы, масштаблы фикерләве, бай сурәтлелек чаралары һәм сүзгә игътибарлы булуы белән мөһим шигърият. Аның иҗат диапазоны шактый киң. Ул табигать матурлыгы белән тәэсирләнә («Сары көз», «Быелгы кыш», «Урманнарда йөрим»), гомернең аккан сулардай тиз узуы өчен сыктана («Китәселәр»), Казанга мәдхия җырлаганнан соң («Без җырлаган көйләр»), аның татарча сөйләшә торган шәһәр булып китә алмавы өчен гарьләнә («Җизле йөгән, җирән атың») һәм, әлбәттә, нәрсә турында язса да, үзәктә татар халкының ачы язмышы, өстендә кара болыт шәүләсе асылынып торган ана телебезнең киләчәге борчый.

«Елаучылар» («Буйсындырылган илләр-халыклар хәленә бер караш») исемле тирән фәлсәфи эчтәлекле шигырендә барлык буйсындырылган халыклар язмышын Дәрдмәнд иҗатында яңгыраган символлар аша чагылдыра. Кол халыкларның күз яшеннән океан туган, шул океанга хәсрәт төяп кораб килгән. Шул ук вакытта лирик зат төшенкелеккә бирелми, бүген кимсетелгән, изелгән, сытылган милләтнең яшәешенә, киләчәккә дәшеп, олы үткәне дәртләндереп тора. Р.Мингалим — метафорага, пластик детальгә өстенлек бирүче шагыйрь. Иркен, ирекле форманы үстерә. Сәләтенең әлеге үзенчәлеге «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күк астында» кебек поэмаларында, «Еракларда», «Хәзер», «Сиңа нәрсә җитмәгән», «Җыр язып, ул көй чыгарган», «Кешелек белән сөйләшү» һ.б. шигырьләрендә ачык күренә. Вакыты белән шигырь прозага барып тоташа, тезмә белән чәчмә арасында чик югала.

Сакларлык, горурланырлык,
Кызыгырлык иде, дидем.
Кирәк иде, безнең өчен
Бер горурлык иде, дидем.
Югалды, югалды, дидем...
«Нәрсә, нәрсә?» — дип сорыйлар.
Ни өчен соң бу кешеләр:
«Кем?» — дияргә ашыкмыйлар?..
(«Сорыйлар...»)

Тулысынча китерелгән бу шигырьнең рифмасы да урынында, хыял уены, антитеза да композицияне бизиләр, ләкин биредә шагыйрь өчен иң мөһиме — фикер, күңелен борчыган, әрнеткән уен әйтеп калу. Аны

бизәкләү чаралары борчымый диярлек. Ә бу инде табигыйлек дигән сүз.

Р.Мингалим ачык төгәл төсләрне, катлаулы фикер борылышларын ярата.

Торган җирең яхшы булу белән,
Туган җирне онытып буламы?!
(«Кеше күңеле»)
«Узган гомер
Искән җил» дип
Әйтәсе килми әле.
(«Кышкы шигырь»)

Мәкаләгә исем биргән, гаҗәеп бай эчтәлекле «Мин — Идел кешесе» (1967) шигыренең үзәгендә дәвамлылык фикере ята. Шагыйрь, татар халкының тарихи үткәнен иңләп, хыялында туган манзара белән рухланып, зирәк, акыллы, батыр, «сайрар поэмалар» тудырган бабаларына соклана.

Р.Мингалим шигырьләрендә фикер, җегәрле деталь, рационалистик башлангыч өстенлек итә дигән идек. «Булма», «Иллә мәгәр», «Сабыйлар көлә», «Җинаять», баштарак язылган «Гел» шигырендә Акмуллалардан килгән хикмәтле сүз, яхшы мәгънәсендәге дидактик фикерләү традицияләре үстерелә.

Шагыйрь булсаң,
Ике төрле фәлсәфәгә
Уртак булма.
....
Шигырьләрдә
Бабай булсаң,
Бул син әйдә, —
Малай булма.
(«Булма»)

Кискен фикергә, төгәл бәяләмәгә, афористик төгәллеккә өстенлек бирү, проза алымнарын куллану, Р.Мингалим шигырьләренә лиризм, шәхес хисләрен чагылдыру осталыгы җитми икән дигән нәтиҗә ясауга этәрми. «Сорыйлар», «Әнкәйне хәтерләү», «Сорама, Камышлы», «Тумый калган балага» шигырьләрендә моң, сагыш, кичерешне үсештә тасвирлау үзенә җәлеп итеп тора. Катлаулы фәлсәфи юнәлешле «Шигъри сагыш» (1967) хис-тойгының фикергә үрелеп үсүенә мисал була ала. Беренче юллардан ук сине давыллы, шашкын хисләр өермәсе үзенә суырып ала. Лирик каһарман сәер холыклы шәхес булып күз алдына килә. Минем гашыйк булганым, сөйгәнем, сөелгәнем, шигъри аваз биргәнем юк, мин алдый, алдана, күрә һәм сөйләшә белмим дип, лирик зат бик җитди шаярта. Ул кем соң? *«Мин тик еллар күкрәгендә яралган шигъри сагыш»,* дип укучыны тәшвишкә сала. *«Гомумән, мин юк ич үзем, юк тавышым, юк көем»,* дип, үзенә тәнкыйди, ироник мөнәсәбәтне иңдерүен дәвам итә. Чынында шигырьнең үзәгендә төрлечә сыналган, ватылган, сындырылган, әмма чын ләззәт үзәге — «шигъри сагыш» ята икән, чөнки ул *«еллар күкрәгеннән чыккан тавыш кына».*

Бөтен иҗат дәвере буенча Р.Мингалимне озата барган, хәтта эзәрлекләгән мотивларның берсе, бәлки, иң мөһимедер — сагыну мотивы. «Яна-яна киткән торналар» (1969), «Сабырлык алам хәзер» (1973) кебек шигырьләренең үзәгендә яткан *«Сагынмый килдемме? Сагынып килдемме?»* сораулары үзәк өзгеч сентименталь мәгънә алып үстереләләр.

Сагыну-сагышның иң югары үре лирик каһарман өчен шигъри сагыш, дидек. Нерв үзәген тәшкил иткән, үткән белән хәзерге, яшәү белән үлем арасында торган «сагыш» шагыйрь үзе икән.

Мин тик еллар күкрәгендә
Яралган шигъри сагыш.

Шунда ук ул, аң төпкеленнән килгән тавышны ишетеп: *«Шигырьдән елау тавыш килсә, мин түгел»,* — дип, үзен аңлау юлына баса. («Шигъри сагыш»).

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Р.Мингалим җир шары,

күк гөмбәзе, океан, кораб, тарих кебек күләмле, масштаблы образлар белән янәшәдә үк кызыл чәчәк, урман куагы, чәчәк тулы бал кебек төгәл, анык, пластик һәм шул ук вакытта киң мәгънәле, сыйдырышлы детальгә, метафорага мөрәҗәгать итә, шул төшенчәләр арасында рухи һәм җисми якынлык эзли.

Борынгы аң калдыкларына, анимистик чорда барлыкка килгән ышануларга таянып эзләнү мәгънә чиксезлегенә, сурәтлелек киңлегенә алып килә.

Кеше рухы киңлекләре, тормыш муллыгы турында уйлану-борчылу, сөенү нәтиҗәсе буларак туган «Бeләм», «Җинаять», «Ялгыз карчык», «Укытучыларыма», «Ни күрсәң дә» кебек шигырьләрдә сурәтле фикерләү индивидуальлеге ачык сизелә. «Ялгыз карчык»та тормыш фаҗигасенә, кеше язмышына төшкән авырлыкны йөрәге аша уздыра белү әсәрнең ышандыру көчен арттыра.

Яшьлеген, матурлыгын хирург пычагы кебек «эченә урнашкан сугыш йөге» алып киткән карчыкның җанлы портретын тудырып кына чикләнми автор, шуннан фәлсәфи нәтиҗәгә килеп чыга. Шигырьнең эчке логикасы, драматик пружинасы шуны таләп итә:

Бара ул, ялгыз көймәдәй,
Бара офыкны куып.
Күзләреннән шаулап тула
Көймәгә вакыт суы.

Табигый интонация, лирик гомумиләштерү алымы — Р.Мингалим өчен тормыш катлаулылыгын, кеше хисләре тирәнлекләрен сурәтләү юлында иң ышанычлы алым.

Турыдан-туры табигать тормышына багышланган шигырьләре күп түгел Р.Мингалимнең, ләкин берсендә дә диярлек ул аның күренешләрен читләтеп үтми. Кеше күңеленә, кеше йөрәгенә, үз кичерешләренә иң туры юлның табигать образлары аша икәнен шагыйрь яхшы сиземли.

Ул каеннар күккә ишарәләп,
Җир туганнан бирле тора бугай:
Шуның өчен генә бөтен дөнья —
Йортын өскә таба кора бугай.
(«Каеннарны үтеп өскә мендек»)

Кышкы таңнар туган чакта,
Дөньямы соң, Татарстан,
Казан шулай чибәрме?
Иделеңне сөлге итеп,
Сөлге итеп тезгә салып,
Сәйлән белән чигәрлек.
(«Аерылса синнән»)

Татар поэзиясендә кышкы таңнар турында шулай матур итеп, яратып язган башка шагыйрь юктыр. («Кышкы шигырь», «Кышкы көнгә багышлау», «Кыш түренә ут ягып...», «Кышкы суыкларга кердек исә», «Кар» (чуваш шагыйре М.Сениэлдән). Кыш аңа ак төсе белән ошый. Ә ул төс шагыйрьнең күңел түрендә утыра, илһамына якын тора. Сурәтне кат-кат, төрле тезмәләрдә кабатлаудан тартынып тормау да шул хакта сөйли:

Илкәемнең ак кырында
Ак юллар салып уздым.
(«Кышкы шигырь»)

Төрле милләт кешеләре арасында аларны аерып торучы сыйфатбилгеләргә караганда, уртаклык, рухи якынлык зуррак икән. Р.Мингалимов тән төсләре, холыклары, яшәү һәм фикерләү рәвешләре төрле булган халыклар арасында уртак өлгеләр, уртак билгеләр таба.

Яшик әле сокланышып,
Сокланырга күпме төс бар:
Күпме илләр, төрле милләт —
Нинди келәм, матур, чуар.
(«Күпме илләр»)

Шагыйрь олы дөнья проблемаларын йөрәге аша уздыра, алар турында үзенчә һәм масштаблы итеп яза белә.

Бу яктан «Җинаять», «Сабыйлар көләләр» шигырьләре, «Иртәгә» поэмасы игътибарга лаек. «Нәкъ унбиш ел», «Уздылар», «Борчулы минутта» шигырьләренең үзәгендә экзистенциаль сагыш, үткәнгә фәлсәфи караш, гомернең кадерен белүгә чакыру ята.

«Үлән бүтән, яфрак бүтән» шигыре самими интонация, лирик гомумиләштерү, тормыш драматизмын, кеше кичерешләрен табигыйлегендә яңгыратуга омтылышы белән хәтердә кала.

Күптән киттең, озак тордың,
Анда нәрсә аңладың?
Бүген кайтып туган якка,
....
Тар басмадан эчкә кереп,
Дулкыннарга үрелдең.
Алып-алып елгадан су,
Койдың аны җилкәңә:
— Яшь чагымда мине, — дидең, —
Кочты бу су иркәләп. —
Тик су сине белми иде,
Яры шул да, су бүтән...
Үлән бүтән, яфрак бүтән,
Кайтмадың шул бик күптән.

Р.Мингалим шигъриятен берничә сүз белән генә аңлатуы кыен. Аның поэзиясе шактый катлаулы, сыгылмалы, самими. Ул — риторикага, ясалма купшылыкка каршы; публицистик шигырьләр язуны да кулай күрми, аның ритмикасы җыр өчен дә артык килешеп тормый, Р.Мингалим шигырьне, тормышның үзе шикелле, табигый яшәтергә омтыла. Бизәкләрне сайлап, нечкә иләк аша уздырып, эчтәлек агышына буйсындыра белә.

Мин гаҗәп төн булыр идем
бер генә тапкыр.
Кешелекне
үзем аша
уздырыр идем
бер генә тапкыр.
...Бер генә тапкыр...
Ләкин шушы гаҗәп төннән
Чыгармас идем
бозык уйлы кешеләрнең
берсен дә, —
Таңның ал капкасы аша,
Яңа якты көнгә
Керерләр иде
Чиста уйлы кешеләр генә...
(«Җинаять»)

Р.Мингалим башка шагыйрьләрдән кайсы ягы белән аерылып тора дип сорасалар, мин әйтелгәннәргә өстәп, фикерләү, дөньяны күрү үзенчәлегенә хас контрастлылык, кылану дәрәҗәсенә барып җиткән, төрле яссылыкларда яткан төшенчәләрне капма-каршы кую, дияр идем.

Кеше кайдан чыккан дигән, бигрәк тә кызыксынучан балаларны «борчыган» фәлсәфи сорауларга да ул, кәбестә арасыннан таптык яисә ләкләк томшыгында алып килде дип, хәрәмләшү юлына басмый: *«Аналары су сибә дә кызлары чәчәк ата», «Әнә дөлдел-канатлы тай-очкан йолдыз тамызып»* («Күкләр соравына бер җавап»).

Тупасрак тоелса да, хакыйкатькә туры килүен, дөреслекне чагылдыруын инкарь итеп булмаган, *«Ашап дуңгыз да булалар, укып дуңгыз булмыйлар»* («Ике такта, бер басма») гыйбарәсен Р.Мингалим каләме генә тудыра ала.

Шагыйрь, тулаем алганда, табигый нәфислек, табигать яме белән кеше акылы, кеше зиһене, кеше иҗаты тудырган төшенчәләр арасында якынлык эзли, яшәеш проблемаларын төрле образлы рәтләр, бер-берсенә охшамаган борылышлар, төсләр, нәкышләр белән сурәтләү юлын табарга тырыша.

Безнең чорда фән һәм техника тормышның барлык өлкәләренә, шул исәптән шигъри фикерләүгә, сурәтлелек алымнарына тирән үтеп керә, интеллектуаль башлангычны, динамизмны көчәйтә. Чор кешесенең эшенә, фикерләү рәвешенә якынлык

— заманга якынлык — шуның бер чагылышы дигән сүз.

Тормышта һәр көнне, һәр сәгатьтә туа килгән яңалыклардан курыкмыйча, заман рухы, чор сулышы белән яшәгән шагыйрь туктаусыз яңа төшенчәләр һәм яңа мохитләр белән таныша һәм бу танышлык күп очракта шәхеснең сурәтләү чараларын яңартуны, камилләштерүне сорый, төрле өслүб юнәлешләре арасында торгызылган ясалма киртәләрне алып ташлый. Кешенең рухын, тирән кичерешләрен, «җан диалектикасын», фикер хәрәкәтен ачу максаты белән язылган шигырьләрдә төрле яссылыкта яткан әйберләр үзара аралашалар, кушылалар. Мәсәлән, нефтьчеләр, химиклар, машина ясаучылар тормышына, шәһәр ритмын сурәтләүгә багышланган шигырьләрдә «сандугач моңы», «каеннар рәте», «чишмә сафлыгы» кебек образлар бик табигый яңгыраса, авыл тормышын, игенче хезмәтен олылап язылган шигырь, поэмаларга, җырларга галәм, дөнья хәлләре турында фәлсәфи, публицистик уйланулар килеп керә.

Бу сыйфат Р.Мингалимнең Чаллы шәһәрен төзүчеләргә багышланган «Күз карасы» поэмасында, «Казан аэропортында», «Минем яшьлек», «Нәкъ унбиш ел үткәч», «Шпаллар», «Килә тезелеп машиналар» кебек шигырьләрендә ачык күренә.

Шулай да Р.Мингалимовны урбанистик поэзия тарафдары итеп бәяләү дөрес булмас иде. Ул язарына азыкны хәзерге чынбарлыктан чумырып алса да, төп игътибарын лиризм, моң ярдәмендә кеше кичерешләрен ачуга юнәлтә. Бу сыйфаты аның поэмаларына да хас. Саннары күп түгел: «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күз карасы», «Күк астында». Аларда шагыйрьнең лирикасында алып барган эзләнүләренә нәтиҗә, йомгак ясала.

«Шигырьләр, поэмалар» (1983) җыентыгына рецензия язган шагыйрь Ш.Маннапов та аның поэмаларын уңай бәяли. «Рөстәм Мингалимнең шигъри сулышы поэмаларында аеруча киңәеп китә. Гүяки, шигырьләрендәге чылтыр чишмәләр бергә кушылып, киң Иделне тәшкил итә. Төрле темага багышланып, һәркайсы үзенчәлекле формада язылган «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күз карасы», «Күк астында» поэмаларын зур бер фикер кадагы беркетеп тора. Бу — тормыш төяп, Кояш тирәсендә әйләнгән гүзәл планетабыз язмышы, кешелек язмышы турында борчылып уйлану. Әнә шушы проблема һәр әсәрдә төрле аспектларда, үзенчәлекле образлар ярдәмендә ачыклана».

Коры хикәяләү, вакыйганы энәсеннән җебенә чаклы түкми-чәчми сөйләп бирү алымыннан баш тартып, шагыйрь динамика һәм сурәтлелек, метафора һәм аллегория аша рухи дөньяга юл ала. Замандашының фәлсәфи-әхлакый эзләнүләре, сагышлары, табышлары, киләчәккә омтылган хыяллары турында уйлана.

Лирик һәм публицистик эскизлардан торган «Күз карасы» поэмасы Чаллы шәһәренә һәм аны төзүчеләргә багышланган. *«Яңа үсеп чыккан Чаллы ул сабый кебек әле: кайдадыр күке кычкыра, ул саный кебек әле»*. Шагыйрь үз бурычын түбәндәгечә аңлый:

Миңа хәзер
Шигырьне
Кирпеч, балчык, ком итәргә түгел,
Комны, балчыкны, кирпечне
шигырь итәргә кирәк,
Кешеләрне шигырь итәргә кирәк.

Шулай да поэзия өчен «ком, балчык, кирпеч»нең шигъриятен ачу гына җитми. Аны эшчән егетләр, уңган, чибәр кызлар бизәргә тиеш. Р.Мингалим бер каһарманны үзәккә куеп, поэманың фикер-хис агышын аңа бәйләү юлын сайламаган. Олы төзелешкә ул кадрлары күз иярмәс тизлек белән алышынып торган кине-

матограф күзе белән карый. Экранда «озын рус», «чандыр казах», «төп кебек татар» шофёрлары образлары күренеп үтә. Икенче рәттә алар янына Рәис, Умат Нурбиев, Карпенко кебек үз исем-фамилияләре сакланган реаль шәхесләр өстәлә. Хезмәт хорының, матур җырның дәвамы туйга, дөресрәге, туйларга килеп тоташа; *«Ә бер өйдә ял сәгате — туй сәгате, Нәсыйх белән Мәдинәгә текәлгәннәр»*, *«ә бер өйдә ял вакыты — туй вакыты, кияү кеше — дагыстанлы — сөйли басып»*. Бу туйлар дәвам итсен, Чаллы мәңгегә яшәсен өчен, җиргә иминлек кирәк.

«Иртәгә» (беренче варианты «Юл өстендә тургай» дип аталган иде) поэмасының төп иҗат принцибы — конкрет тормыш, көнкүреш вакыйгалары аша гомумиләштерү юлына чыгу. Шагыйрь үзен борчыган вакыйга-хәлләр, Татарстаны, туган җире турында түкми-чәчми, эзмә-эз сөйләп бирү юлына басмый, әһәмиятсез, төссез нәкышләрне сурәткә кертми, заманны үзенчә күрүе-аңлавы аша иңләргә омтыла. Табигать күрке, матурлык символы — тургай җыры, тургай моңы турындагы сөйләү чорыбызның шатлыклары һәм каршылыкларына бәйле уйлануларга алып чыга.

Поэманың үзәк фикере Вакыт агышы турында фикер йөртү белән бәйле. Шагыйрь Вакытка мөнәсәбәтен берсенберсе кысрыклап һәм ачыклап килгән катлаулы образлы рәтләр аша ача. Дөньяның тизлегенә иярә алмаучылар да бар. Берәүләр *«Канатсыз кош булып утырып кала. Ятып кала башсыз яу булып…»*, икенчеләре *«Ак күбеккә баткан ат кебек…»* бәйгедән төшеп кала. Шул уйланулардан соң шагыйрь җитди нәтиҗәсен чыгара:

…Ниләр кала шулай, кемнәр кала?
Көйләр кала микән, илләрме?
Мөмкин түгел җиңел генә бару
Дөнья тизлегенә ияреп.
Бүген алган тизлек бүген ярый, —
Яңа тизлек кирәк иртәгә.

«Иртәгә» поэмасы *«Шомырт чәчәкләре ап-ак дәрья, Ак дәрьяда хыял көймәсе»* кебек сыйдырышлы детальләргә, лирик чигенешләргә бай. «Хыял көймәсе» метафорасы халыкның иҗтимагый тарихы, тормышның кыйммәте хакында уйлануларга алып чыга.

Шагыйрь туган иленең матурлыгын дәртләнеп җырлый, аның башкалар күрмәгән кыйммәтен табу рухы белән яши. Тургай җыры туган ил җыры белән кушыла.

Р.Мингалим «Минем дәүләт» поэмасында да туган иленең тарихи үткәнен, бүгенге олы адымнарын дәртләнеп җырлый, аның башкалар күрмәгән матурлыкларын табу һәм сурәтләү рухы белән яши. «Күк астында» әсәрендә исә бер урамлы авыл, бер карт язмышы аша яшәүнең мәгънәсе, кеше акылының куәте турында уйлана.

Карап үткән поэмалар арасында мәгълүм уртаклык бар. Поэмаларда лиризмның көчәюе, сурәтле фикерләүнең катлаулануы, күләмнең кыскаруы күз алдында. Шуның өстенә авторның, үз шәхесе белән тыгыз бәйләнгән лирик герой үзәк фигура булып бара, шигъри деталь гомумиләштерүгә юл ача.

Поэма тукымасында барлыкка килгән үзгәрешләр борынгы жанрның яңаруы, чор таләпләренә, кешенең фикерләү үзенчәлекләренә якынлаша баруы турында сөйли.

Р.Мингалим «шигырь һәм шагыйрь» проблемасы хакында күп яза: «Булма», «Шигырьләрем белән сөйләшү», «Яшь шагыйрьгә», «Карт шагыйрьгә».

Р.Мингалим Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким, Ә.Давыдов кебек остазлары алдында баш ия, аларга шигъри һәйкәл куя. Аның 1968 елда ук иҗат ителгән «Галимҗан ага Ибраһимовка» исемле шигыре бар. Ул В.Маяковскийның «Товарищу Нетте,

пароходу и человеку» әсәренә якын. Сүз иң элек Казан белән бергә нурга төренеп, үсеп килгән һәм Галимҗан Ибраһимов исеменә лаек булган урам турында бара. Шуннан сүз шәхескә күчә:

Ибраһимов —
ул бер урам исеме,
Ул бит кеше булган. —
Кайберәүләр куркып
тынган чакта,
кыю телгә килгән.
Кайберәүләр куркып
шаулашканда,
тыныч бара белгән.

Берничә юлга кеше характеры сыйган. Вакыт аңа үз бәясен биргән, «аны тотып тарих иткән, җиргә яшереп куйган». *«Эзләгәннәр аны, Кирәк ирләр — онытыламыни? Тарихны җиргә яшереп саклап буламыни?»* Ибраһимов якты урам, биек йортлар булып шытып чыга.

«Язучы һәм тормыш» темасына язылган әсәрләре арасында әдәбиятта арабыздан тирән эз калдырып киткән шәхесләргә багышламалары аерым урын тота («Шагыйрь Илдар Юзеевка», «Калуыбыз кирәк булса да», «Сорама, камышлы», «Илһам Шакировка» һ.б.)

Бөтен иҗади гомере дәвамында мөкиббән китеп, җае чыккан саен хөрмәтен сиздереп яшәгән остазы — Тукай. Турыдан-туры аңа багышланып язылган шигырьләре күп булмаса да, әдәби мохит әгъзаларына бәя биргәндә, рухи дөнья катлаулыкларын сурәтләгәндә, ассоциатив фикерләү үзәгенә Тукай таяныч ноктасы, киңәшче, арадашчы буларак килеп керә. Җөмләдән, язучы Альберт Хәсәновка багышламасында, Тукай образының пәйда булуы әүвәл бераз сәеррәк тоелса да, бу алымның шагыйрьгә сурәтләү объектын «котырынып» мактарга мөмкинлек бирүе өчен килеп керүе аңлашыла. Аннан килеп, Тукай артык вак, пүчтәк кеше белән кызыксынып та тормас иде.

Тукай сорый:
Кем бәйрәме?
Нишләде соң ул Хәсән?
Альберт Хәсән —
Ул бит безнең прозада,
Прозада зур чәчән.
(«Альберт Хәсәновка»)

Өлкәннәрнең рухын олылауны, буыннар алышынуын экзистенциаль сагыш дәрәҗәсенә күтәргән «Сагыну» (1983) шигыре Р.Мингалим иҗатында аерым урын били.

Үзәкләр өзелә тора,
Кемнедер сагындыра.
Сагындыра Тукайларың,
Җәлилләр истә тора.

Шигырьнең кичереш дәрәҗәсен билгеләгән «сагыну дәрьясы» бөтен татар шигъриятен, аның талантлы вәкилләрен, якташларын тәсбих төймәләредәй бер җанлы җепкә тезеп торган үзәк дәрәҗәсенә күтәрелә.

Истә Шәрәф, истә Әнвәр
Сагындыра югалган.

Сагыну, шул ук вакытта исәннәр өчен чистарыну, сафлану чарасы, катарсис та икән: «Якты безнең күзләребез сагынуларда юганга».

Такташны бик сагынганда,
Туфанга карар идек...
Инде Туфан сагындыра,
Фаилләр... ярар инде.
(«Сагыну»)

«Язгы Тукай янында» (1977) табигатьнең иң ямьле фасылы турында уйлану рәвешендә язылган. Җиһанга уяну («Ачылды тау»... диләр язда»), яшәрү, дәрт алып килгән яз Тукайны искә төшерә.

Йөз кабат яз килер тагын,
Инде исән булмасак...
Җирдә язлар, язда шигырь
Һәм Тукайлар булачак!
(«Язгы Тукай янында»)

Офык боҗрасы ничек кенә кысылмасын «Без аякта, без исән», шуңа күрә иелергә, таралырга ашыкмагыз, дигән нәтиҗәгә килә шагыйрь.

«Тукайга» шигыре бөек әдипнең татар мәдәни дөньясында тоткан урынын ачыкларга омтылган гомумирәк рухтагы бәясе белән үзенчәлекле.

Күпчелек шагыйрьләр, аерым алганда, чордашы Р.Харис иҗатында мөһим урын тоткан шигъри багышлауларга — мемуар жанрга Р.Мингалим шактый өлеш чыгара. Ул «Күктән йолдыз чүпләми», бөекләр турында гына язмый, ә күңеленә якын каләмдәшләрен, сәнгать әһелләрен яратып тасвирлый, җанлы образларын тудыру рухы белән яши. Бер-бер артлы Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Р.Гаташ, К.Булатова, Л.Шагыйрьҗан, Ә.Рәшит, Ф.Зыятдинов һ.б. исем-образлар тезелеп китә. Шигъри бизәлеш, характер ачылышы ягыннан бәяләгәндә алар төрле, әдәбиятта калырлыклары белән янәшәдә туган көн уңаеннан тезмә котлаулар да бар. Тулаем алганда, багышлаулар циклында да шагыйрь телне баету юнәлешендә эзләнә, сүзнең төрле төсмерләрен ачу турында уйлана.

Р.Мингалимнәр буыны фәлсәфи лириканы үстерүгә, тарих-заман-вакыт кебек төшенчәләрнең эчтәлегенә, фәлсәфи мәгънәсенә үтеп керүгә зур көч куя. Р.Мингалимнең бу мәсьәләләргә үз карашы бар. «Сез» шигырендә Р.Мингалим кеше язмышы турында уйлануын киңрәк җирлеккә күчерә. Кеше чакырымнар, вакыт һәм буыннар аша атлый: *«Сезнең шатлык, сезнең елмаюыгыз киләчәккә төшә безнең каберләр аша... Буыннар алышыну борынгыдан, Моңа борчылмыйбыз сыман, Шулай да моңсу әзрәк кенә».*

Вакыт, заман, мәңгелек — берәүгә дә буйсынмый торган изге төшенчәләр. Алар белән шаярып булмый. *«Заман шулай куша инде, Тормыш шулай куша инде: Күп йөрергә, Күп күрергә, Күп эшләргә; күп белергә»* («Ашыгасың»). «Гомер язында», «Нәрсәсен төшенмисең» шигырьләрендә дә ул вакыт һәм кеше гомере, тормышның эчке мәгънәсен аңлау хакында сүз алып бара *(«Туу да үлү генә ул, Уртада — кыска гомер... Кыска гомердә үзеңә Син төшенергә өлгер»).*

«Әйтерсең вакыт — аучы» шигыре кискен драматик нотада башланып китә: *«Вакытның бер күзе — Кояш, Ә икенче күзе — Ай».* Димәк, кеше галәмнең ике күзәтчесеннән, аучысыннан берничек тә качып котыла алмый. Вакытның кулында «өр-яңа мылтык», чакмага басты исә, кемдер егылыр. Дөрес, бу фаҗигаи интонация шактый кискен ноктада өзелә, дөресрәге, шагыйрь аңа башка, ироник юнәлеш бирә: «Мин куркаклар нервысында юри бераз уйнадым».

Әлбәттә, кызык, хәтәр бетем, ләкин шигырьнең гомуми төзелеше, олы төшенчәсе югала, тормыш драматизмы бутафория чүбенә урала. Бу сюжет җитдирәк нәтиҗәгә лаеклы. «Иллә мәгәр» шигыренең дидактикасы да, әхлакый сентенциясе дә ясалма тоела.

Башың җитмәсә — уйлама,
Башың җитсә — уйла.
Көчең җитмәсә — уйнама,
Көчең җитсә — уйна.

Алдагы юлларда да шундый ук дөрес киңәшләр бирелә, антитеза шагыйрь логикасына, бакыр солдат кебек, намус белән хезмәт итә. Шуннан нәтиҗә: *«Гел дөньяга күренмәвең Шәптер иллә мәгәр».* Сораулар туа. Беренчедән, тәнкыйть утында көйдерелгән герой дөньяда күренү-күренмәү мәсьәләсен үзе хәл итә аламы, икенчедән, әгәр ул дөньяга килгәнче үк шундый акыллы

булып, безнең гөнаһлы чынбарлыкны бизи алмавын аңлап, үз урынын акыллырак бирәүгә бирергә риза булса, аны тәрбияләп тору ихтыяҗы бар микән? Кеше тормышының тиз узучан мизгелләрен үкенеч-хәсрәт белән искә алу *(«Эссе табада май сыман сәгатьләрем сыза, сыза җегәр, җаным сыза»)*, яшәешнең ямен вакытлы бәхет буларак тасвирлау җәһәтеннән аңлы пессимистик дулкында язылган, А.Ахматова, А.Блок, Б.Пастернаклар дәрәҗәсендә торган «Бары вакыт-вакыт...» шигырендә сүз шул хакта бара:

Җәйләрнең дә тулы чагы,
бары вакыт-вакыт,
кәккүк булып кычкыра,
хәтеремә кайтып.

Р.Мингалим иҗатында сатирик фикерләү әһәмиятле урын тота. «Табут хәтле алтын», «Идарә чылбыры», «Алдагы сайлаулардан соң», «Чиксезлек һәм күзге чебен турында» шигырьләрендә кешегә һәм илгә хас кимчелекләр басынкы, әмма шактый усал гыйбарәләр аша утка тотыла.

Р.Мингалимнең шигъри дөньясы турында сүз алып барганда, аның Тукай, Бабич, Г.Афзалларны хәтерләтеп куйган ачы телле һәм күп очракта сәяси сатирик икәнлеген дә онытырга ярамый. Вакыты белән аның кыюлыгы куркытып та куя.

Ышанмагыз, Русиянең:
— Яратам! — дигәненә.
Ярата белми,
Русия ул —
Көчли генә белә.
(«Табут хәтле алтын!»)

«Идарә чылбыры» (1989), «Алдагы сайлаулардан соң» (1995), «Гариза» (1999), «Әй, шаян тормыш» (1996) кебек иҗтимагый-сәяси рухлы шигырьләрендә ул *«һаман өмет өзмәүчеләр, бәхет эзләүчеләр, өметсезләр, алдакчылар, эчкечеләр, караклар, үтерүчеләр, үлүчеләр...»* («Әй, шаян тормыш») исеменнән илдә барган тамашаны фаш итә, каһкаһә белән көлә.

Киртлә, Аллам, Мәскәү колагына,
Мөстәкыйльлек бирә күрмәсен!
Шуны бирсә — халкым бүләк яулап
Һәм кәнәфи бүлеп... үләчәк.
Ярый Мәскәү пока моны белми,
Әгәр белсә — тиз үк бирәчәк.
(«Гариза»)

Сайлаулар алдыннан кибетләргә затлы тауарларның шыплап тутырылуы, яхшы ризыкларның кайтарылуы һәркемгә мәгълүм. *«Тик» чәчәк кебек чәчелгән яңа өйләр, якын һәм ерак илләрдәге виллалар «кемнәр өчен төзелгәннәр соң?»*

Затлы туннар, «дыңгычлап доллар тутырылган сейфлар» да шул ук шәхесләр өчен, ә сайлаучы Габидуллага «кәҗә таягы» һәм ямаулык сорап торган иске тун гына өлешенә тигән көмеше икән.

Безнең сатириклар Мәскәү түрәләрен, укымасларын тәгаен белеп, курыкмыйча, кәттә сүзләрне кызганмыйча тәнкыйть итсәләр дә, үзебезнең җитәкчеләргә киная белән генә дә тел-теш тидермиләр. Р.Мингалим бу тарафтан да, күпчелек сатирик каләмдәшләреннән аермалы буларак, үзебезне чеметеп алудан тартынып тормый. Бу яктан аның «Гаярь татар» шигыре бик үзенчәлекле. Ничек кенә көлми ул яраткан татарыннан. Үз халкының энә белән кое казу кебек иң авыр гамәлләрне башкарырга, кушканны үтәргә әзер торган йомшак якларыннан, коллык психологиясеннән шулай аны ихласи яраткан, җанын ярып бирергә әзер кеше генә көлә ала.

Онытма, Мәскәү,
Татарның барын:

— Һәрчак әзер! —
Татарларың.
Син:
— Сыйлыйм! — дисәң,
Кунак булып барачак.
— Җигәм! — дисәң,
Ул ат булып барачак.
Мылтык бирсәң —
Солдат булып барачак.

Татар түрәсе дә үткен каләм чәнчүеннән читтә кала алмый: *«Әй, аның түрәсе, татарның түрәсе, әз генә елмаеп, бер генә үбәсе, — май бит ул, татар!»* «Гаярь татар» туры мәгънәле шигырь генә түгел, аның икенче, өченче катламнарында татарның теләсә нинди катлаулы эшне булдыра алуына, хезмәт сөюенә киная дә бар. Тик шигырьнең «булдырам бу эшне! — дип әйтер дә татар һәм чукыныр да», дигән бетеме генә күңелне тырнап уза. Мөртәт татарларның булуын таныган хәлдә дә, гомумән ислам диненә тугрылыклы татарларга күләгә төшерәсе килми. Татар кавемен үз гореф-гадәтле, үзаңлы милләт итеп дин һәм ул тудырган мәктәп-мәдрәсәләр саклап калуы турында үзебезне оялтып искә төшереп тормыйм.

Хакимияттә утыручыларның күбесеннән шагыйрь игелек көтми, шуңар да ул аларга хәерхаһ түгел: *«Киләчәкнең тимер түрәләре — ни күрсәтер тагын кешегә»* («Томаннарга таба илттеләр»). Кайбер тискәре күренешләрне күпертебрәк сурәтләсә дә, Р.Мингалим — халкының, җөмһүриятенең иң турылыклы, патриотшагыйрьләренең берсе. Моңа инану өчен, «милләтен сатучыга» аңлатмасы белән ачылган «Синең базар» (1992), «Туган як кырларына» (1971), «Читтә яшәп калган якташларыма» (1970), «Үпкәләрмен кебек» (1975) шигырьләрен укып карау да җитәр. Беренче шигырьдә дан-дәрәҗә алу, кәеф-сафа корып яшәү өчен халкын саткан затларны хурлык тактасына «кадаклый»:

Авыр туфрак телим сиңа,
атың корсын,
Ата-анаң рухы шуны сизеп торсын:
Син яхшырак киенер өчен —
халкың саттың,
Кәеф-сафа сөрер өчен —
халкың саттың.
(«Синең базар»)

«Үпкәләрмен кебек» шигыренең лирик каһарманына «Казан — шәһәрләрнең иң гүзәле кебек», ә «Татарстан — Җир үзәге кебек», аңа хәтта Татарстан ул сөйгән дөньяның «бер өлеше кебек», «Мәскәү — Татарстан шәһәредер» кебек тоела. Әгәр аңа син хаклы түгел, хаталанасың дип әйтсәләр, «шул кешегә мәңге үпкәләр» кебек. Менә шундый инде ул татар Дон Кихоты Рөстәм Мингалим: камчылый да, яратып аркадан да сөя.

Р.Мингалим иҗатының үзенчәлекле төре — мәхәббәт хисенә, мәхәббәт чыганагы — «дәрт чүлмәкләре» — хатын-кызга багышланган шигырьләре. Бу темада да шагыйрь үзгәрә, үсә, татлы агудай кичерешне, изге хатирәләрне сурәтләүнең яңа юлларын барлауны дәвам итә. «Иделдә», «Өч урын»да мәхәббәт сөенечен чагылдыруның нигезендә — үзенә һәм сөйгәненә, мәхәббәт сагышына (анысы күбрәк үткәндә булган) ироник мөнәсәбәт ята. «Кояшлы язда» шигырендә исә чибәркәйнең иреннәрен, сүзләрен лирик зат балга тиңли. Үзенең бәясен, чибәрлеген аңлаган кыз «Сөйләшә дә белмим», «Үбешә дә белмим», «Дәртсез бала булдым» дип чытыкланa да бәйләнчек заттан котылу нияте белән соңгы дәлилен китерә: «Син карт», «абзый», ди. Лирик каһарман әүвәл кызның кыланышларын юри «чеп-чи ялган», «чүтеки ялган», «бу да ялган», «тагын ялган», дип «коры» кире кагуы нәтиҗә бирмәгәч, гиперкүпертү юлына баса:

Әнә, күкне үпкәнсең дә —
эзе кояш булып калган.

Күкнең, кояшның үз вазифалары баштин ашкан, алар җирдә яшәүче һәр кемсәнең эшенә тыгыла алмый. Шагыйрь шул ук ироник тонда гадәтилеге, гадилеге белән сокландыргыч нәтиҗәсен ясый:

Ялган булыр менә:
мондый язда —
дәрт чүлмәге
тышыннан беленә.
(«Кояшлы язда»)

Халык әкиятендәге шикелле бакага гашыйк (аның туйда гүзәл кызга әверелүе ихтимал дигән мифологик фикерләүгә ышану ята) гөнаһсыз фәкыйрь («Нарасый»), «туң җаннарның туң колагын эретерлек кызчык» («Ялгыш яраттым»), «үбешергә ирнең бирсәң суырып башыңны йотар» («Уйнабрак уйлану»), «җитмеш кыз сыйган күңелне бер хатын биләп тора» («Ә хәзер без акыллылар») юлларында да шул ук ироник караш, үткәнне «ат күзеннән» һәм «ак күбектәй кабарган» хәзерге тәҗрибәле акыл белән бәяләү ята.

Мәхәббәткә, табигый матурлыкка шундый олыларча, үзе үткән юллар биеклегеннән юмор бәпчекләре белән бизәлгән, фаҗигале куныктан азат бәя (поэзия мәхәббәттә күбрәк үкенечле сагыш, фаҗига эзли) шигърияткә яңа нәкышләр, шигъри пластика, сыгылмалылык алып керә.

Аның интим лирикасы тормыш драматизмына сизгерлеге, кеше кичерешенә нисбәтән нәзакәтлелеге, олы күңеллелеге белән аерылып тора. Лирик геройның тойгылары кешене күтәрә, сафландыра: тормыш мәшәкатьләрендә, дөнья ваклыкларында югалып калмаска, дөреслеккә, ахыр хаклыкка таянырга, кеше кичерешләренең муллыгына ышанырга өйрәтә.

Р.Мингалим мәхәббәт турында ипле һәм матур итеп, шигъри сурәткә натуралистик ваклыкларны кертмичә, үз януын синең януыңа күчереп яза белә («Бу нинди яз?», «Иделдә», «Карап тора», «Ерактагы зәңгәр офыгым бул», «Яз очрашу», «Шәт», «Кызыл чәчәк» «Бер танышлык турында» һ.б.).

Р.Мингалим лирикасына сынландырулар, көтелмәгән чагыштырулар, метафора үзәктә яткан кичереш мантыйгының дәвамы буларак килеп керәләр: «Урман, кырлар көннең чәчен тарады» («Көн килде»), «безнең тормыш — шайтан төше», «шәрә туташ кебек шәрә бүлмәм» («Уйнабрак уйлану»), «өмет яна — сары башны табалырмын шикелле» («Ялгыш яраттым»), «Күкрәгенә чәчәк кадап көн килде, көзнең чәче йомшак җил иде» («Көн килде») кебек гаҗәеп матур, нечкә күзәтү тудырган сурәтләрне чын рәссам гына иҗат итә ала. Аның поэзиясендә таушалган гыйбарәләр, халык җырларыннан «прокатка» алынган сурәтләр очрамый диярлек.

Чынбарлыкны хисси кабул итү, һәр вакыйга, күренешнең эчке мәгънәсен ачу сәләтенә ия булган, үз шигъри интонациясен, кабатланмас өслүбен тапкан шагыйрь буларак танылгач, 70 нче елларның икенче яртысында Р.Мингалим драматургиягә мөрәҗәгать итә. «Әйт, Кояшым» (1966), «Ә сәгать келт-келт итә» (1967) кебек иң тәүге җыентыкларын балаларга багышлаган шагыйрь сәхнә әсәрләрендә дә әүвәл кече яшьтәге тамашачылар ихтыяҗы турында кайгырта. Балаларны могҗизалы дөнья белән таныштыру аша фикерләү дәрәҗәләрен баеткан, уйларга, кичерергә өйрәткән «Урман улы Зурмөгез» (1975), «Сихерләнгән урман» (1981), «Шүрәлеләр үч алмый» (1982), «Сәер кешеләр, батыр малай һәм артист попугай» (1988) әкиятпьесалары курчак театрында зур уңыш белән барды. «Сихерләнгән ур-

ман» әсәре Мәскәүнең Үзәк курчак театры репертуарына да керде. Халык иҗаты мотивларына таянып язылган яисә яшәешнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең четерекле якларын үзенчә яңгыраткан, яңача күреп иҗат ителгән пьесалары балалар күңелендә үз урынын алды. Р.Мингалим яшь буынның рухи дөньясына да юл тапты. Табигать күренешләрен, хайваннар тормышын мөлаем юмор, шуклык, шаянлык, фикер һәм сүз уйнату аша автор яшь дусларын олы дөньяны таныргa, аңларга өйрәтә, аларга тормыш көнитеш, әхлак кагыйдәләрен сеңдерә.

Драматургия жанры белгечләре, А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, Ә.Закирҗанов кебек галимнәр Р.Мингалимнең олылар тормышын, психологиясен яңача сурәтләгән «Мин сине шундый сагындым» (1978), «Кире уйларга соң иде» (1978), «Тау астында илле бүре» (1979), «Өченче бүлмәдә эт яши» (1980), «Кунак кызы гел килмәс» (1984), «Әгәр булса борчуларың» (1986), «Сабый туды» (1988) исемле комедия һәм драмаларының заманча эчтәлекләре, фәлсәфи тирәнлекләре, татар драматургиясенең реалистик көчен модернистик алымнар белән тулыландырып, кеше зиһененең тирән катламнарына үтеп керү, үзүзенә ироник бәя бирү алымнарын киң куллану (исемнәре үк шуңа киная ясый) аша драма сәнгатебезнең офыгын киңәйтүен билгеләп үтәләр. Драматург буларак аны 1981 елда Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгән «Кайда сез, ирләр?» комедиясе таныта.

«Шагыйрь Мингалимне борчыган кебек үк, драматург Мингалимне дә җәмгыятебез үсешендә баш калкыткан яисә инде ныгып ук җиткән аерым күренешләр, аларның яшәешкә, җәмгыятьнең рухи дөньясына тискәре йогынтысы борчый», — дип яза А.Әхмәдуллин. — Шигъриятендә ул мондый күренешләрне аңларга һәм аңлатырга тырыша, аңа төрле позициядән торып якын килә — фикер киңлегенә ирешә. Драмаларында исә болар конкрет ситуцияләр үзәгенә куела».

Р.Мингалимнең шигъри дөньясы тормышның үзе кебек бай, шәхес кичерешләре кебек катлаулы. Ул үзенең хыял-уйларын, йөрәк серләрен, әхлакый нәтиҗәләрен тиз генә, гади генә ачып сала торган шагыйрь түгел, чөнки бу шигъри дөнья күп еллар буена аерым сүзләр, образлар, җөмләләр ярдәмендә төзелгән. Ә алар артында еллар чалымы һәм реаль шәхес тора. Бу шәхеснең рухи дөньясын аңлауга шактый кыйммәт бәя — чирек гасырдан артык вакыт түләнгән. Иң шатлыклысы шул: Р.Мингалим поэзиясе, драматургиясе бу олы бәягә лаеклы. Еллар заяга узмаган. Халык күңеленә үтү юлларын эзләүгә багышланган.

Башлам кәлимәбездә искә алынган «Җиргә бер сүз» исемле шигырендә Р.Мингалим болай дип язган иде:

Кадер өчен мин кечкенә булсам,
Кабер минем өчен тар әле.

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ

ИРТӘГӘ...

(Поэма)

I

Нидер кала дөнья тизлегеннән,
Кырга яфрак кебек ягылып,
Канатсыз кош булып
Утырып кала,
Ятып кала
Башсыз яу булып...
Кала соңгы тапкыр үрә баскан,
Ак күбеккә баткан ат булып...
Дусың булып кала кулын болгап,
Кала арттан аткан ят булып.
...Ниләр кала шулай, кемнәр кала?
Көйләр кала микән, илләрме?
Мөмкин түгел җиңел генә бару
Дөнья тизлегенә ияреп.
Бүген алган тизлек бүген ярый, —
Яңа тизлек кирәк иртәгә.
Гел үзгәреп очкан дөнья белән,
Әй, китәргә ерак! Китәргә!
Бүләгем бар ерак ул көннәргә,
Илтә барам Тукай якларын,
Бәрхет түшле яшел тауларымның
Язмышлары бездә чакларын.
Борынгыдан килгән кырлар монда.
Шәһәрләре — исән килмәгән.
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән...
Читекләре килгән Идел белән,
Кешеләре тузып килгәннәр.
Җайдагы юк атлар йөзеп килгән,
Агып килгән атсыз иярләр.
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән.
...Борынгыдан килгән кырларында
Шәплекләре исән килмәгән.
Җир астында килгән
җиз комганнар,
Алкаларның — алтын-затлысы;
Хәрабәләр арасына посып,
Поэмасы килгән, эпосы...
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, барыбер, белмәгән.
Борынгыдан килгән кырларында
Шөһрәтләре исән килмәгән.
Алар янган борынгы йорт белән,
Тукай ягы — бетеп янмаган...
Борынгыдан килгән кырларында
Без яшәргә булдык яңадан!
Юкса безгә Рәсәй патшалары
Урын бүлгән музей түреннән...
Унҗиденче елда
Китеп бардык
Музееның ишеге төбеннән!
Көлдек шунда карап бер-беребезгә:
— Үзебез дә кызык икәнбез...
— Килеш-килбәтебез музей өчен,
Тәмам әзерләнеп җиткәнбез...

— Киемебез, хәтта биюебез,
Җырларыбыз — музейныкылар…
— Юк, музейга безгә иртә булыр!
— Йә, сезнеңчә ничек, сынчылар?
— Ә рәссамнар безнең нәрсә диләр?
— Музейларга рәсем, сын кирәк!
— Музейларга үле корал кирәк!
— Без бит әле тере төслерәк?
— Юк, музейга безгә иртә булыр!
Без яшәргә булдык яңадан…
Гел үзгәреп алга дөнья оча,
Без калмаска булдык аңардан.
Оча дөнья алга гел үзгәреп,
Илтә барам Тукай якларын:
Аэропортлар, юллар,
Байракларның
Язмышлары бездә чакларын.
Иксез-чиксез әрәмәләр илтәм,
Эче тулы шомырт, бал исе;
Шомырт чәчәкләре ап-ак дәрья,
Ак дәрьяда — хыял көймәсе.
Йөзә һаман, йөзә сары көймә,
Малай-шалай карый кызыгып.
Аннан йөгерә алар егетлеккә,
Акбай чаба арттан, сузылып…
……………………………………………
Кызлар җитә монда, җыйнаклана,
Күз алдында бераз суырылып.
……………………………………………
Монда җылы сөю җиле исә,
Көннәр исә рәхәт җил булып.
Үсә монда каен һәм бозаулар,
Үсә фикер, үлән һәм тайлар…
Башын чайкап, бөгелеп, биеп кенә
Үсә кырда безнең бодайлар.
Ялган юллар, яулар авызына
Без бирмәскә тиеш аларны.
…Явызлык та алдым үзем белән,
Җиңәр өчен явыз җаннарны, —
Күңеле гаҗәп яхшы кешеләр дә
Көтмәгәндә каза күргәннәр.
Серләрем бар әле,
Киңәшем бар
Кабынасы яңа көннәргә…
Ни икәнен беләм юлларның да,
Озын юлда буш кул кем йөрсен?!
…Уенчыклар алдым онықларга,
Уенчыклар алдым,
Төрлесен…
Сыбызгылар…
Битлек…
Курчак алдым…
Бәлки, күп тә китә алмамын,
Янәшәмдә яхшы дусларым бар,
Юлда калмас кебек алганым.

II

Юл өстендә, кыр өстендә
Сайрый тургай биектә.
Ничек болай сайрый тургай,
Борчак кына кебек лә?!

Сайрый тургай, өзә тургай,
Каян алган шундый көй?
Эче тулы шатлык кына,
Шатлык кына микәнни?!

Җирдә тургай бәхет кенә,
Бәхет кенә күргәнме?
Бәхетле кыяфәтенә
Әллә юри кергәнме?!
Әллә болай кирәкмиме,
Әллә шулай кирәкме?
Күтәрә бит, күтәрә бит,
Күтәрә бит йөрәкне!
……………………………………………
Көе белән коендыра,
Яңарта бит, юа бит…
Якынайта өметләрне,
Борчуларны буа бит!
……………………………………………
Кыр өстендә, чор өстендә —
Кыл өстендә бугай ла?!
Җыр ягына көн тартыла,
Гөл тартыла тургайга.
Көй артыннан тал сузыла,
Үлән күккә үрелә,
Таш, үрелеп көйгә таба,
Йортларга әверелә…
Кынысында кылычы бар
Ир тартыла тургайга.
Тартылмаска уйлап торган
Ил тартыла тургайга.

Уйламагыз тартылмый дип, —
Җир тартыла тургайга!

Чор өстендә, кыл өстендә...
Ни хикмәте бар аның?
Уйный тургай,
Сайрый тургай —
Безнең белән барадыр?!
Әллә соң ул бер-бер серле,
Җанлы рәсем икәнме?
Киң кырларны ул үзенә
Сихри канат иткәнме?
Әллә үзе киң кырларга
Сихри канат булганмы?
Чор өстендә, кыл өстендә —
Хикмәте бар тургайның?!

Әллә тургай түгелме ул,
Ул очар шигырь микән?
Ник булмасын
Тургай шигырь,
Канаты булган икән?!
...Килә-килә,
Тургай көнне
Тутырып ала бугай?!
Сайрый-сайрый китә тургай,
Ядрәгә кала бугай...
Кыл өстендә, чор өстендә
Үз урыны тургайның.
Бу чор аша канатсызлар
Уза алмас, мөгаен.
Чор юлында —
Татарстан,
Чор юлында —
Чал Идел...
Канат булса хезмәтебез,
Безнең сәнгать, безнең тел
Канатлыдыр Татарстан
Һәм канатлыдыр Идел!

III

Зур дөньяда үз ягымның
Чын кыйммәтен беләм мин.
Шагыйранә сөйләп аны
Арттырырга теләмим.
Шаярмыйм мин чынлык белән,
Ялган белән уйнамыйм.
Татарстан, Идел диеп,
Мактанырга уйламыйм.
Идел икән, Идел инде! —
Җанга якын, туган бит.
Бабайларның канлы йөзен
Юган чагы булган бит.
Идел икән, Идел инде! —
Яратыйк та кадерлик.
Әмма моннан зур суларның
Җирдә барын кем белми?!
Тормышка Татарстанмы
Иң кирәкле, иң матур?
Кай шәһәрдән Казан артык,
Кешеләре кемнән зур?
Зур булсалар,
Андый зурлар —
Бездә генәме алар?
Бездә генәме яшь алмаш —
Үсеп килгән алыплар?!
Аксакаллар булган икән,
Алмаш булырга тиеш!
Без ничек язмыйк ди икән,
Кол Гали язган килеш.
«Безнең халыкның үткәне,
Зур юлы булган», имеш.
Халкы булгач,
Аның инде
Юлы булырга тиеш!
«Тарихи истәлекләре,
Сөембикә манарасы,
Мәрҗани мәчете...», имеш.
...Истәлек океан булыр,
Истәлек булыр — инеш...

Истәлекләр булыр алар,
Күргән дә бар аларны.
Хөрмәтлик истәлекләрне,
Хөрмәтлик бабайларны.
Һәм узганга салават та,
Шуны да уйлау кирәк:
Чыгышы бөркет икәннең
Очышы ничегрәк?
Ачышларда, очышларда
Бүген хәбәр өр-яңа?
Суны кысып металл итә
Сәхнәсендә замана.

Тезләнеп сәҗдә кылсаң да
Болгарларың ягына,
Ир дигәннең — бүгене ир,
Узганы — малай гына.

IV

Без очышта, без очышта,
Мин моны тоеп барам;
Мин тумыштан дорфарактыр,
Сөйләшәмдер дорфарак.
Тик очышта, без очышта, —
Гел шуңа сөенеп барам.
Сәйдәшләр алган алкышның
Җилләрен сизеп барам...
«Китмибез»не «Төшмибез» дип
Әйтәсеңмени аны?!
Бар чагында Мулланурың,
Туфаның, Тукайларың...
Көмеш сулар, яшел ярлар,
Илебез бар — йөрәктә.
Эшләребез, эзләребез,
Кызларыбыз — еракта.
Ераклыклар, дәүләтләрнең
Асларында торбалар
Татарстан куәтенең
Киңәйгәнен тоялар.

Без очышта, без очышта,
Әй, Җәлил егетләре!
Тизлекне үзгәртәбезме?
Җегәрлек бармы әле?
Ярсудыр сезнең күңел дә,
Минем дә ярсу күңел.

Елмаеп сорау бирсәм дә,
Шаярып сорау түгел.
Шаярыр заман түгел бу,
Очмасаң, туктау кирәк —
Инде күккә күтәрелмәс
Самолётлар төслерәк.
Озак уйлар заман түгел,
Очсаң — очарга кирәк,
Шәүләсе дә җирдән купкан
Ракеталар төслерәк.

Күзендә күкнең очарга,
Дөньядан гыйбрәт алып.
Очарга янып-янып та,
Очарга — исән калып!
Хәерле юл тели Ватан,
Алда нинди зәңгәрлек!
Халкыңны, оча алмаса,
Ник туган дип җәлләрлек.
Ярсудыр синең күңел дә,
Минем дә ярсу күңел.
Елмаеп сорау бирсәм дә,
Шаярып сорау түгел.
Тизлекне үзгәртәбезме,
Татарстан, бергенәм?
Улың булып, хуҗаң булып
Киңәшәм синең белән...

Аңлар мине синең киңлек,
Анда бар да минеке:
Төлкеләр дә, куяннар да,
Боланнар да минеке.
Суында балык чиртүе,
Камышы да минеке.
Торналарың, бүреләрең
Тавышы да минеке.
Яккан учак, пешкән шулпа,
Аксыл пары — минеке.
...Малайлары, әнкәләре
Һәм кызлары минеке.
Шаулы Казан минеке ул,
Юкәләр дә минеке.
Синеке түгел дисәләр?
Дисәләр дә — минеке!
Урам саен мәрмәр такта,
Алары да минеке.
Кичләре дә, төннәре дә,
Таңнары да минеке.
Зур тәрәзләр, киң мәйданнар
Һәм гөлләр дә минеке...
Гөл куяр кешесе беткән
Каберләр дә минеке!
Мин аларга шигырь куям!
Куярлык шигырь микән?
Безнең шәплек, яшәү тавышы
Шуннан иштелер микән?
Мин аларга шигырь куям,
Җыр куегыз, җырчылар!

Кайсыгызда сан бирерлек,
Сан алырлык тавыш бар?
Кайсыгызда дөнья тавышы
Саналырлык тавыш бар?!

V

Син башласаң,
Без дә кушыласы —
Әйдә килешеп алыйк, булмаса?!
Чыдарбызмы, әгәр синең җырың
Ил өстенә җәелеп еласа?
Чыдарбызмы? Никтер безнең халык
Әллә нинди җырлар чыгарган;
Зур Җир шары төшеп тирбәлерлек
Кайгы диңгезедәй җырлар бар.
Чыдарбызмы? Болай чыдам да без,
Ә барыбер күпме еланган?!
Син җырлама инде авыр көйләр,
Мин теләмим хәзер еларга.
Син җырлама бүген авыр көйләр,
Күңелләрне генә йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Юлда һәркем күңеле йомшак түгел,
Алга бара ләкин барысы да.
Күренәләр генә тыныч сыман,
Бөтен кеше җирдә ярсыган.
Алышалар күпләр, бүлешәләр,
Көчләрәге тарта күбрәген, —
Бармакларын гына карасаң да,
Тишкәләнә йомшак йөрәгең.
Юлда әле бәхет эзләүчеләр,
Бәхетеннән шашкан кешеләр бар.
...Чишеләсе бәхәсләр бар юлда,
Үтерешкә җиткән эшләр бар.
Без барабыз тыныч тормыш яклап,
Дошман бара җыелып-серләшеп.
Йөкле ана уза киләчәккә,
Һәм танклар уза гөрләшеп...
Юк, җырлама моңлы озын көйләр,
Күңелләрне артык йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Син шуларны җырла —
борылышларны,
Дәүләтләрнең убылып беткәнен;
Упкыннардан кеше калыкканын,
Яшәү һаман җиңеп үткәнен.
Үзебезне җырла, гыйшкыбызны,
Чоры өчен без дә Таһирлар.
Эш күбрәктер бугай, вакыты шулай,
Ләкин азмы бездә шатлык бар?!
Мәңге яңа дигән шәп җырлар да
Искерәдер бераз, мөгаен, —
Җырладык ла инде андыйларны
Юл читендә оеп, моңаеп...
Ә бүгенгә безгә инде күбрәк
Лазер җыры кирәк, ут җыры!
Кыенлыклар моны сорый бездән,
Тизлек моны сорый, юл сорый.
Исән илтик юлда Кеше йортын,
Шатлык белән тулы йорт ясап.
Тукай ягын илтик, шәһәрләрен
Һәм шөһрәтен илтик исән-сау.
Ерак китик әле дөнья белән,
Чын бәйрәмнәр булыр шуннан соң.
Ул чакларда гөнаһ булмас йомшау,
Һәм җырларсың безгә...
Җырларсың...

VI

Нидер кала дөнья тизлегеннән
Кабат килер сыман яз булып;
Төркем-төркем кошлар сыман кала,
Канатлары кала язылып;
Кала тыныч кына, кайчан да бер
Адресатка җитәр хат сыман;
Калмас өчен кузгалырга кала,
Кешнәп үрә баскан ат сыман.
Гел үзгәреп дөнья алга оча,
Ярып керә кызыл таңнарга...
Оча дөнья алга гел үзгәреп,
Без калмаска булдык аңардан!

1975

ИСЛАХ ДӘВЕРЕ МИРАСЫННАН

ХАКЫЙКАТЬ

ГАБДУЛЛА БУБИ

Бисмилләһиррахмәниррахим
Беренче җөз’е (кисәк)
Хакыйкать
яхуд
ТУГРЫЛЫК
Наширләре:
Галиәсгар Камаледдинов вә шөрәкәсе
Дозволено цензурою. С.-Петербургъ,
9 Іюня 1904 г.
КАЗАНЬ
ГОРОДСКОЙ ПАССАЖЪ
Лито-Типографія И.Н.Харитонова
1904

Бисмилләһиррахмәниррахим.

Тугрылык бик күркәм вә кеше арасында бик кадерле бер нәрсәдер. Шуның өчен дә аны һәрбер шәригать кушкан кебек, һәрбер вөҗданлы адәмне дә үз вөҗданы аны эзләргә вә тугры юлга керү иҗтиһатында булырга өндидер. Бер юлның хаталыгын белә торып, анда дәвам кылган адәм бик аздыр. Бәлки һәр адәм үз юлын үзе тугры дип исәплидер вә юлын белгән адәм дә «синең юлың — хата» дип, кешедән ишетергә разый түгел. Бәс, моннан аңлашыладыр ки, һичбер адәмнең вөҗданы бозык юлда булуга разый түгел, ләкин бик күп адәмнәр белмәенчә тугрылыкны ата-баба юлы дип гөман кылалар вә шулай төрле хата вә бозыклыкларда дәвам итәләр. Андый хаталар безнең мөселманнарның да күбесенә бик күп җирләрдә йогыштырган. Арабыздан зур галим күренгән мөдәррис вә мөтәшәехләр [шәех кыяфәтендәге ялганчы] дә, хәзрәте Расүл вә сәхабәләр юлын карамыйча, Һүлагү, Чыңгыз сәбәпле, мөселманнарда булган гыйлем вә мәгарифнең инкыйразыннан соңгы галим-голәмә исемен йөрткән ялкауларга ияреп, динебездә булган иң әһәмиятле фарызлардан йөз чөерәләр һәм гамәлләрнең фазыйләтенә караган риваятьләр белән шөгыльләнәләр. Болар аңламыйлар ки: тугрылык ата-баба юлы түгел, бәлки Ислам кушкан бәхет-сәгадәт юлыдыр. Бәс, тугры юлга керү өчен, сәгадәт юлыннан гыйбарәт булган Коръәнне белергә вә аның буенча йөрергә тиешле. Бәс, [сәгадәт юлын ничек белергә кирәк?] соравына җавап бик ансат: Коръән вә хәдистән белергә кирәк. Коръән вә хәдиснең сәгадәт юлы икәнлеге бик күп мөхтәрәм галимнәрнең китапларында вә безнең «Борһаны сатыйгъ» [«Ачык дәлил»] дип аталган

рисаләбездә катгый дәлилләр белән исбатланганга, бу рисаләдә ул хакта махсус сөйләмәбез. Әмма кайбер урыннарда сүз уңаеннан моңа кагылышлы бәхәсләр чыкса — чыгар, анысы безнең файдага гына. Янә бер сорау бар: һәркемнең тугры вә сәгадәт юлы дип кергән мәсләге Коръән вә хәдистән алынганмы? Моңа да җавап бик ансат: юк. Ләкин мөшкелрәк берсе бар: Коръән вә хәдискә муафыйк булган сәгадәт юлы белән түбәнлеккә, бозыклыкка илтә торган юлны аеру. Моңа ирешү өчен, иң мөкәммәл юл — Коръән вә хәдисне барча хикмәтләре илә бик яхшы белеп, һәрбер мәсләк иясенең эш-гамәлләрен шуларның бизмәненә салып карау. Әлеге юл бик озак булганлыктан, без монда ул хакта сүзне озайтып тормабыз. Бәлки иң кыска юл булган капма-каршылык канунына игътибар юнәлтербез. Бу галәмдәге һәрбер нәрсә капма-каршылык канунына буйсынганга күрә, бер мәсләкнең дөрес булып-булмавын белер өчен, аны башка мәсләк белән чагыштырып карарга кирәк. Чибәрнең чибәрлеген — ямьсезгә карап вә Исламның шәрәфәтен гайре Исламга карап белгән кебек, бу замандагы мәсләгебезнең ни дәрәҗәдә бозык булуын Рәсүлүллаһ вә сәхабәләр мәсләгенә карап белә алабыз. Сәхабә вә табигыйннәр, Ислам сәбәпле, бик тиз бер заманда гакылларны хәйран кылачак дәрәҗәдә күтәрелеп, безнең бу кадәр түбән тәгәрәвебездән аңлашыладыр ки, безнең мәсләгебез бөтенләй сәхабәләр мәсләгенә капма-каршыдыр. Безгә әлеге дәгъвабызны тәфсилләп исбатлар өчен, бу рисаләдә вакыт кына юк. Юкса Пәйгамбәребезнең тормыш юлын вә сәхабәләр тарихын тикшергән адәмгә бу каршылык бик ачык мәгълүмдер. Иң күзгә күренгәннәреннән бере: алар һәрбер галимгә Коръәндәге аятьләр хакында фикер йөртүне рөхсәт итәләр вә үз иҗтиһатына каршы килгән адәмгә ачуланмаслар иде. Без исә Коръән аятьләрен фикер сөзгече аша үткәрүне тыябыз вә иске адәмнәрнең сүзләренә катып торуны тиеш дип табабыз һәм дә аз гына безгә хилафлык кылганны кире кагабыз. Хәлбуки, Коръән сәхабә белән табигыйнгә генә түгел, безнең өчен дә иңгән китап булганлыктан, аның хакында уйлану вә фикер йөртү безгә дә тиеш була һәм дә Рәсүлебезнең хәдисләре Коръәннең гаҗәеп хикмәтләре бетмәс, дип кычкырып торадыр. Әгәр иске тәфсирләргә генә катып торсак, Коръәннең гаҗәибе юкка чыккан һәм, Аллаһ сакласын, Рәсүлүллаһның сүзе ялган димәктер. Хәтта Әфәндебез галәйһиссәлам әйтәдер: «Минем өммәтем яңгыр кебек: әүвәлеме, ахырымы хәерлерәк мәгълүм түгел». Бәс, бу заманда да Мөхәммәд Габдүһ вә Әхмәд Мидхәт кеби бөек галимнәр чыгарлар да иске тәфсирчеләрнең хәтерләренә килмәгән бик күп хикмәтләрне Коръән аятьләреннән табып чыгарырлар. Ләкин Коръәндәге хакыйкатьләрне яхшылап аңлар өчен башка гыйлемнәрне бик гүзәл белү өстенә, иске тәфсирләрне вә Ислам кемнәр арасында килгән вә ни сәбәпле иңгән, шуларны да белергә кирәк. Мәсәлән, бер адәм миннән [рузәгә кайсы көн кердегез?] дип сорап, мин [шимбә көн] дип телеграф суксам, бу сорауны белмәгән адәм моннан бер нәрсә дә аңлый алмаган кебек, аятьләрнең иңү сәбәпләрен белмәгән адәм дә аятьләрдән бер хөкем дә чыгара алмас. Шуның өчен дә кайбер иске китапларда *[вә тәзәүвәдү фәиннә хайраззәәдит тәкъва* (…азык алыгыз, чынлыкта иң яхшы азык — тәкъвалыктыр, Бәкара, 197)] аятен почмакта гыйбадәттә ятуга вә [зәәд]не (азык)ны ахирәт азыгына вә [тәкъва]

ны (тәкъвалык) гыйбадәт мәгънәсенә кайтарып калдыралар. Хәлбуки, бу аять фәкыйрьлек илә хаҗга барган адәмнәр хакында иңгәнлектән, мәгънәсе болай булырга тиеш: *[сез азыгыгызны алып барыгыз, чөнки азыкларның хәерлесе кешедән сораудан сакланудыр]*. Дәхи дә бер адәм *[иннәмәл мүшрикүнә нәҗес* (чынлыкта мөшрикләр — нәҗестер, Тәүбә, 28)] аятен күрсә, кайсы кавем арасында иңгәнен исәпләмәсә, [мөшрикләр дә барыбер адәм бит, адәм нигә нәҗес булсын?] дип икеләнеп кала. Хәлбуки, бу аять җенси мөнәсәбәттән соңгы арусызлык хәленнән вә һичбер шакшылыктан сакланмаган вә кулларын тизәктән-фәләннән юмаенча, Кәгъбәне тоткан вә күлмәксезыштансыз таваф кылган [Кәгъбә тирәли әйләнү] гарәп мөшрикләре хакында иңгән ки, аларның нәҗес булуларында һичкем шөбһә әйләмәс. Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә хәзрәтләре бу сүз соңында ук *[фәлә йәкърабүл мәсҗидәл хәрамә бәгъдә гәәмиһим һәзә* (...алар ошбу елдан соң Хәрәм мәчетенә якын килмәсеннәр, Тәүбә, 28)] дип, мөселманнарга вә Кәгъбәгә тиеп, хосусан, тавафта тирләгән көенчә нәҗесләмәсеннәр вә сасы исләр илә хафаламасыннар өчен хаждан тыйды. Ягъни [мөшрик гарәпләр нәҗестән сакланмаслар, нәҗесләрдер. Бәс, аларны тугызынчы елдан соң хаҗга китермәгез. Алар мәсҗеде Хәрәмгә якын килмәсеннәр]. Бәс, боларны хаждан тыю кяфер булулары сәбәпле түгел, шакшылыклары өчендер. Юкса, безнең дине Ислам дине мөбиндер [ап-ачык дин] ки, һичкемнән һичбер нәрсәне яшермәс. Шуның өчен дә Шәфигый мәзһәбенәдәгеләргә каршы килеп, Хәнәфиләр имансызларны хәрәмгә вә мәсҗеде Хәрамга кертүне рөхсәт иткәннәр. Шуңа күрә, кайберәүләрнең [сезнең Исламда да яшерен эшләр бар, менә сез үзегездән башканы Мәккәгә җибәрмисез] дигән сүзләре дөреслеккә туры килми. Коръәндә каршылык бар дигән бәхәсләрнең дә сәбәпләре ошбу аятьләрнең иңү сәбәпләрен белмәгәнлектән килгән берәр хатадыр.

Безнең әһле Исламның искеләрендә дә бик гаҗәп кешеләр булган. Бер нәрсәне сөйли башлады исә, мөмкин кадәр аны күбәйтергә тырышкан. Менә берсе, һиҗрәттән 410 елда вафат булган мәшһүр карый Әбүл Касыйм Һибәтуллаһ бин Сәләмә бин Наср бин Гали әл-Багдадидыр ки, ялгыз бер Бәкара сүрәсендә 30 мәнсух [хөкеме бетерелгән аять] санаган. Бар санаган мәнсухлары 225тер. Хәтта *[Вәл гаср. Иннәл инсәәнә ләфии хүсръ. Илләлләзиинә әәмәнү вә гәмилүс саалихәәти вә тәвәсау бил хәккый вә тәвәсау биссабр* (Гасыр белән ант итәмен. Адәм баласы зыян-хәсрәттәдер. Иман китереп, изге гамәлләр кылган, бер-берсенә хаклык һәм сабырлыктан тайпылмаска киңәш иткәннәр генә (ошбу хәсрәттән имин булыр)] кебекләрдәге истисналарны да нәсехтән [хөкеме бетерелгән аять] санаган. Әгәр бу кебиләрне нәсехтән санаса, Зәйдтән башка барча кавем килде мәгънәсендә булган [җәәнил каүм иллә Зәйд] кебиләрдә Зәйд килде вә килмәде димәк булып, каршылык булмак кирәк, чөнки нәсех димәк, электән куелган бер хөкемне бетереп, яңа бер хөкем урнаштыру димәктер. *[Иннәл инсәәнә ләфии хүсръ* (Адәм баласы зыян-хәсрәттәдер)] дә ихбар [хәбәр итү] булганлыктан, аны нәсех кылу каршылык һәм Аллаһ сүзен ялганга чыгаруга китерә. Гарәп сөйләмендә мөстәсна минһүләрдә истиснасыз хөкем юк, шуның өчен дә Зәйдтән башка барча кавем килде дип мәгънә бирәбез. Бәс, Зәйдкә

башта ук килде дип, хөкем кагылмый ки, хәтта аны истисна нәсех [дөрес булмаган] вә ибтал [ялган] булсын! Ошбуның кеби мөэмин вә салихларга да башта ук хәсрәт илә хөкем кагылмый. Хөкемнән башта ук чыккан нәрсәне без сүзнең башында, әмма гарәпләр сүзнең ахырында зикер кылалар. Һәрбер телнең үз кагыйдәләре бар, аңа һичкемнең һичбер нәрсә дияргә хакы юктыр. Инде аятьнең мәгънәсенә килик: [гаср (гасыр)] йөз ел мәгънәсендәдер. Адәмнәр һәрбер заманда «бу заман бозык вә бу заман — заманы фасыйк» дип, заманны хурлап вә кабахәтне аңа аударганга, Аллаһы Тәгалә, заманда кабахәт юклыгын аңлатыр өчен, гасыр илә ант итте, ягъни «яхшылык та, яманлык та адәмнәрнең үзләреннән, заманда һичнинди кабахәт юк, теләсә нинди заман булсын, иман китереп, изге эшләр кылганнар вә Ислам үсеше өчен җан вә баш уйнатканнар бер дә хәсрәт күрмәсләр, намус вә абруйлары сакланыр, вөҗданнары рәхәт булыр, рәхәт-рәхәт дөньядан күчәрләр, әмма болардан башка һәммә инсан хәсрәттәдер: абруй-дәрәҗәсе төшәр, вөҗданы рәхәт күрмәс, коллык вә әсирлектә гомер уздырыр. Шушылай мең бәла белән газаплана-газаплана дөньядан узар. Шуның өчен дә сез халкыгызга хаклык вә сабыр илә васыять итешегез, хәтта алар милләт мәнфәгатьләре вә намус вә абруйларын саклап калу һәм кире кайтару өчен тырышсыннар вә хакыйкый мәдәнияттән гыйбарәт булган мөселманлыкны таратуга вә мөселманнарга куәт бирүгә иҗтиһат кылсыннар. Вә галәмне хөррият вә тигезлек илә тутырсыннар, бу юлда никадәр бәла вә михнәтләр юлыгып, никадәр киртәләр очраса да, сабыр вә ныклык илә каршы торсыннар. Чөнки Аллаһның вәгъдәседер: сабыр вә ныклык кылган бер адәм, ун кеше күрә алмаган эшне күреп, ахырда максудына ирешә алмаенча калмас». Әмма 911дә вафат булган Имам Суйути хәзрәтләре мәзкүр шәех Әбүл Касыймнан биш йөз ел соң була торып, борынгы галим дип, каршы чыгудан курыкмаган, мәнсух [хөкеме бетерелгән] аятьләрне бик азайткан, ике йөз егерме бишнең егерме бишеннән дә киметкән, хәтта исти'зан [рөхсәт сорау] вә кыйсмәт [мирас бүлешү] аятьләреннән башка бары егерме мәнсух санаган, әмма бу ике аятьне мәнсух түгел, мөхкәм [хөкеме дәвам иткән] дигән, чыннан да мөхкәм.

Исти'зан [рөхсәт сорау] аяте: *[Йә әййүһәлләзинә әәмәнү лийәстә'зинәкүмүлләзинә мәләкәт әймәәнүкүм вәлләзинә ләм йәблүгүл хулүмә минкүм сәләсә мәррат: мин кабли саләтил фәҗри вә хыйнә тәдагүнә сийәәбәкүм минәззаһиирати вә мин бәгъди саләтил гыйшәи сәләсә гаураатил ләкүм, ләйсә гәләйкүм вә лә гәләйһим җүнәһүн бәгъдәһүннә таувафунә гәләйкүм бәгъдакүм гәлә бәгъдин кәзәәликә йүбәййинүллаһү ләкүмүл әйәәти вәллаһү гәлиимүл хәкиим* (Әй иман ияләре! Кул астыгыздагылар (коллар, хезмәтчеләр) һәм сезнең әле балигълык яшенә җитмәгән (балаларыгыз) шушы өч вакытта яныгызга рөхсәт сорап керсеннәр. Иртәнге намазга кадәр, төшке йокыга дип өстегездән киемнәрегезне салган чакта һәм ястү намазыннан соң. Болар — сезнең өчен мәхрәм (аулак, шәхси) вакытлар. Башка вакытта рөхсәтсез кереп йөрү алар өчен дә, сезнең өчен дә гаеп түгел, чөнки болар янәшәгездә яшәгән, гел-гел күрешеп, очрашып торган кешеләрегездер. Аллаһ сезгә аятьләрен менә шулай ачыклый. Чыннан да Аллаһ чиксез гыйлем вә хикмәт ияседер, Нур, 58)]. Кайбер сәхабәләр йоклаган вакытларында коллары кереп, күренмәгә лаек бул-

маган бер хәлдә күрделәр дә, аларның бик кәефләре китте. Ошбу килешсез гамәлне бетерү өчен, Аллаһы Тәгалә бу аятьне иңдерде, ягъни *[Әй иман китергән адәмнәр! Сезнең колларыгыз вә азатларыгыздан балигъ булмаган хезмәтчеләр өч вакытта, ягъни йокы киемен салып, көндезге киемне кия торган, йокыдан тора торган вакыт — иртәнге намазга кадәр, вә төштән алда, кайлулә [төшке йокы] өчен киемнәрегезне салган вакыт вә ястүдән соң, киемнәрне салып, юрган ябынган вакыт сезнең янызга рөхсәтсез кермәсеннәр. Чөнки, күренде ки, бу өч вакытта сезнең гаурәтләрегез [оят урыннарыгыз] ачыла торган вакыттыр. Әмма бу өч вакыттан башкаларда сезнең берегез берегез янына кереп йөрергә мохтаҗ булганлыктан, рөхсәтсез керүләрендә сезгә дә, аларга да зарар юк. Менә, Аллаһ сезнең файдагызга булган хөкемнәрне шушылай бәян кыладыр. Аллаһ Галимдер ки, сезнең һәммә хәлегезне белә, Хәкимдер ки, һәрбер хөкемендә сезгә мәслихәт вә асанлыкны [җиңеллек] ригая кыладыр].* Кайберәүләр бу исти'зан хөкмен ни аятьсез вә ни хәдиссез, вә ни бер гакыл дәлиленнән башка мәнсух дигәннәр. Алар карап саташканнар бу хөкемнең мөселманнар арасында бер дә үтәлмәгәнлегенә. Болар исә белмәгәннәр ки, мәнсух димәк Аллаһның бер хөкмен бетермәк димәк булганга, һичбер хөкемне, хосусан, Аллаһ тарафыннан бик ачык дәлиле күрсәтелгән бу хөкемне һичбер дәлилсез мәнсух дияргә батырчылык итү бик бөек бер җөрьәттер. Хәлбуки, әлеге хөкемнең бу аятьтә Аллаһ тарафыннан күрсәтелгән дәлиле бу заманда да күз алдында күренеп торадыр. Әгәр бер хөкемнең мөселманнар арасында үтәлмәве аны кире кагу өчен җитәрлек дәлил булса, исраф кылуның хәрәмлеге вә гайбәт сөйләүнең тыелганлыгы кебек бик күп хөкемнәр мәнсух булып бетмәк кирәк. Нәсех — башка, тотмассызлык [үтәмәү]— башка. Әлеге исти'зан хөкмен мөселманнар никадәр тотмасалар да, бу заманда да сәбәбе дә, үзе дә бакыйдыр (дәвам итә). Хосусан, сәхабәләр заманында ыштан киелмәеп йоклады исә, гаурәт ачылу ихтималы бик зур булганлыктан, бу хөкемнең сәбәбе бигрәк ачык иде. Әмма безнең бу заманыбызда ыштан-фәлән бик нык булганлыктан, әгәр гаурәт ачылу ихтималы булмаса, сәбәпнең юкка чыгуы белән хөкем дә гамәлдән төшкәнлектән, бу хөкем лязем булмаса да булмас, ләкин һаман мәнсух диеп булмый. Чөнки бер хөкем мәнсух булдымы, ул хөкем илә гамәл аслан дөрес булмаска кирәк. Хәлбуки, әлеге сәбәп булган җирдә бу хөкем һаман дәвам итәдер.

Сәбәпнең юкка чыгуы белән хөкемнең дә гамәлдән төшүе — хак нәрсә. Аллаһы Тәгалә *[Иннәмәс садакатү лил фукараи вәл мәсәәкиинә вәл гәәмилинә гәләйһә вәл мүәлләфәти кулүбүһүм вә фиррикааби вәл гаариминә вә фи сәбилилләһи вәбниссәбиили фариидатүм минәллаһи вәллаһү гәлиимүн хәкиим* (Зәкят садакасы бары тик фәкыйрьләргә, мескеннәргә, зәкят җыючы махсус хезмәткәрләргә, күңелләрен Исламга тарту мәслихәт дип табылган кешеләргә, әсирлек вә коллыктан котылырга теләгәннәргә, бурычлыларга, Аллаһ юлына һәм дә мохтаҗ хәлгә калган юлчы-мосафирларга бирелер. Бу Аллаһ тарафыннан катгый сурәттә фарыз кылынган хөкемдер. Аллаһ чиксез гыйлем вә хикмәт ияседер, Тәүбә, 60)], дип, Ислам зәгыйфь вакытта дәрәҗәсе зур имансызларның сүзләрен Ислам вә мөселманнардан кисү вә

кайберләрен иярченнәре белән бергә мөселманлыкка якынлаштыру өчен, кыскасы, Ислам вә мөселманнарны куәтләү өчен мөәлләфәи көлүбкә [дингә якынайту өчен дошманның күңелен йомшарту] дә зәкят бирергә кушты. Соңра Ислам куәтләнде, мөселманнарны куәтләү өчен, андаен адәмнәргә мал, зәкят биреп, уңай карашларын казанырга хаҗәт калмады. Шуның өчен дә хәзрәте Әбү Бәкер аларга бу мал бирүне тыйды. Менә бу да сәбәпнең юкка чыгуы белән хөкемнең гамәлдән төшүенә бер мисал. Дөрес, нәсехтә дә бер хикмәтсез нәсех булмыйча, әүвәлге хөкемнең сәбәбе беткәнлектән, сәбәп бетү белән хөкем дә беткән буладыр. Ләкин нәсехтә, киләчәктә мәнсух аятьләрне, тәфсилдә аңлашылган кебек, гыйлләи үләнең [әүвәлге сәбәпнең] кире кайту ихтималы булмаганлыктан, әүвәлге хөкемнең кире кайту ихтималы юк. Әмма бу заманда, мөселманнар зәгыйфь булып, Ислам дине яңа башланган чордагы шартлар кайтканлыктан, аның хөкеме дә кайтмак, ягъни Исламияткә зарар ясый торган адәмнәрнең хәтерләрен табып, Исламияткә хезмәт иттерү өчен, аларга зәкят акчаларын бирү дөрес булса кирәк. Бәс, бу заманда зәкятне бирелергә тиешле урыннар аятьтәге кебек сигез буладыр, ягъни [Аллаһ тарафыннан фарыз кылынган зәкят сигез урыннан башка урынга бирелмәс. Кәсепкә көче җитмәгән мохтаҗ фәкыйрьгә; кәсепкә көче җиткән, ләкин кәсеп тапмаган мохтаҗ мескенгә; падишаһ тарафыннан зәкят җыярга куелган кешегә жалование вә кальбләрен Ислам тарафына җәлеп итү тиешле булган адәмнәргә; «фәлән кадәре мал бирсәң, азат буласың» диелгән мөкәтәбә коллыгыннан чишәр кадәре, бурычлы адәмгә бирәсе кадәре, Аллаһ юлына вә малы бетеп гаҗиз калган гази [дин юлында тырышлык куючы] вә хаҗи вә мосафирга, Аллаһ сезгә мәслихәтне Галим вә эшендә Хәкимдер ки, зәкятне фарыз кылып, сезгә бик күп файда ясады]. Чөнки күз алдыбыздадыр ки, чит милләтләрнең байлары фәкыйрьләргә тиешле өлешен бирмәгәнгә, социалистлар [иштиракиййун] чыгып, фәкыйрьләрне аздыралар вә байларның малын бүлешергә аякландыралар. Шуның өчен дә, Ислам малларының кырыктан бере ел саен фәкыйрь-фокарага бирүне байларга фарыз вә лязем кылды. Ошбу сәбәптән безнең Ислам фәкыйрьләре байларына дога кылмакта вә социалист-фәлән аслан күренмәктәдер. Бу хөкемгә каршы социалистлар ни дисеннәр? Бер диячәк булмаслар, чөнки аларча байларның бар малларын бер көндә өләшеп бетерәсең дә, икенче көн ни фокарага вә ни байларның үзләренә бернәрсә калмыйдыр. Әмма Исламча байлар кырык елда бар малларын фокарага өләшеп бетерәләр дә, шул мөддәттә кәсеп кылып, әүвәлге малларының 4-5 катын тагын казаналар. Бәс, бу вакытта фокарага да бар, байлар да мәхрүм түгел, һәр ике тарафка яхшы. Ислам моның илә генә дә куймый, бәлки ошбу кырыктан бер өстенә нәфел садака бирергә өнди вә аларга бик күп саваплар билгели, хосусан, ятим вә фәкыйрьләргә һәрвакыт шәфкать вә мәрхәмәт илә вә сату-алуда гаделлек илә гамәл кылганнарга җәннәт илә сөенче бирәдер. Хәтта файдасыз коры акча саклап ятмасын, бәлки акчасын сәүдәгә тыгарга мәҗбүр булсын да, вәкил вә хезмәтчеләргә, мескен вә фәкыйрьләргә вә милләтнең башка кирәкләренә файда әйләсен өчен, сатуга тыкмаган акчадан зәкятне лязем итәдер. Менә, зәкятнең бер файдасы социалистларны бетермәк

вә фокараны үзеңә дус ясамактыр. Моның өстенә бер адәмнән гомум халык разый вә аның өчен хәерхаһ [изге теләктә] булсалар вә дин вә милләтенә бөек-бөек файдалар ясаса, табигый, вөҗданы рәхәтләнә вә [әлхәмдүлилләһ, миннән адәмнәр разый бит, миңа изгелек телиләр] дип, шатлана-шатлана, ахирәт йортына юнәлә. Монысы икенче бик бөек бер файдадыр. Тагын да олырак өченче бер файдасы фәкыйрь-мескеннәрне ачлыктан коткару вә [фи сәбилилләһ (Аллаһ юлында)] сарыф кылып, мәсҗед вә мәдрәсәләр, вә дарелгаҗәзәләр [картлар, гарипләр йорты] салып милләтенә хезмәт әйләмәктер. Аятьтәге [фи сәбилилләһ] күпчелек дин белгечләре уйлаганча, бары тик хаҗ яки газатка [дин юлындагы сугыш] гына кайтып калмый, бәлки, Тәфсире Хазиндә вә Тәфсире Кәбирдә кайбер галимнәрдән китерелгәнчә, сүз сөрешеннән аңлашылган хәерле эшләрнең һәртөрлесен үз эченә ала. Шуңа да, зәкятне мәсҗед вә мәдрәсәләргә вә җәмгыяте хәйрияләргә бирүнең дөреслеге акыл белән аңлашылган кебек, шәригать күзлегеннән аять сүзе белән дә дәлилләнә. Боларга зәкят ничек сарыф кылына? Анысы мәгълүм, әмма фәкыйрь вә мескеннәргә ничек сарыф кылмак кирәк? Табигый, безнең Русия байлары кеби билгеле бер көндә зәкят чыгарам дип игълан кылып, сорап килгән бер адәмгә биреп җибәрү вә бер мәдрәсәнең гомум шәкертләренә өләштерү яхшы түгел, чөнки зәкят сорап фокарадан башка оятсыз ару адәмнәр дә киләдер вә мәдрәсәгә кергән зәкятне һәм шәкертләрнең байлары да аладыр. Зәкят алган теләнчеләрдән күбесе сатып эчеп, яки анда-монда куеп, зәкят малын әрәм итәләр. Кыскасы, зәкятне бу рәвешчә өләшү теләнче күбәйтү вә зәкят малын әрәм-шәрәм кылудан башка һичбер нәтиҗә тудырмады. Инде сез әйтерсез, Аллаһы Тәгалә зәкятне фәкыйрь вә мескеннәргә бирергә кушкан, синең сүзеңчә, бирүнең дөрес түгеллеге аңлашыла, Аллаһы Тәгалә белмәенчә кушкан микәнни? Юк, Аллаһ сакласын, нигә белмәенчә кушсын! Минем сүземнән дә бирүнең бөтенләй ялгышлыгы түгел, бәлки безнең байлар биргән рәвешчә бирүнең дөрес түгеллеге чыгадыр. Аллаһы Тәгалә хәзрәте фәкыйрь вә мескеннәргә бирергә куша, ләкин ничек итеп бирү рәвешен тәгаен кылмый, аны билгеләүне безгә тапшыра. Аллаһы Тәгаләнең зәкят бирдерүдән максуды — аларны фәкыйрьлек вә мескенлектән коткару. Моның шулай икәнлеген гакыл вә вөҗдан таныган кебек, шәригать тә хуплыйдыр. Һәрбер заманның вә урынның үзенә хас хәле була. Анысы табигый. Ләкин бу заманда, безнең бу җирлеккә, ягъни Русия мөселманнарына туры килгәне — сәнәгать мәктәбе салып, шуңа яки хөкүмәт тарафыннан салынган сәнәгать мәктәпләренә фәкыйрь кешеләрнең балаларын салып, киемсалым вә ашау-эчү хакын зәкят акчасыннан биреп, дини гыйлемнәр өстенә өч-дүрт ел сәнәгать өйрәтмәктер. Иштә, бу вакытта бу балалар тимерчелек, столярлык, тегү, буяу, кәрзинкә үрү вә гүзәл-гүзәл короблар ясау кеби сәнәгатьләрдән берәрсендә остарып, гомере буенча шул һөнәре белән үзен, хатынын, балаларын туйдырып, зәкят хуҗасына дога кылырлар. Менә бу вакытта мөселманнардан фәкыйрь вә мескеннәр азаер, Аллаһы Тәгаләнең зәкят илә әмере җиренә килер. Вә кыямәт көнендә хөрмәтле пәйгамбәрләр хозурында болай кылган байларның йөзләре ак булыр.

(Дәвамы алдагы санда.)

Басмага Ренат Миңнегалиев әзерләде.

В.Зотов фотосы

30 нчы АВГУСТ, ЯГЪНИ СҮЗ УРЛАУ

РӘНИФ ШӘРИПОВ

Борынгыдан дәүләт тоткан
горур халык...
Туфан Миңнуллин

Ахры, ашыгып өзгәнбез,
Өлгермәгән әле җимеш.
Утызынчы август җитсә,
«Җөмһүрият көне...» имеш.
Каян килгән безгә бу чир?
Әллә пешкәнгәме авыз?
Бүре өркеткән көтүдәй,
Почмак саен елышабыз.
Бәйсезлек сүзен әйтергә
Әллә тыйдылармы инде?
Утызынчы август көнне
Бәйсез, азат Дәүләт җиңде!
Кыямәт көне буладыр,
Килер җавап тотар көннәр.
Хыянәт көне бар хәзер...
Җавап тотар икән кемнәр?
Сүзе булса да калсын тик,
Үзе юк инде, күрәбез.
Аш суынган инде күптән,
Ә без һаман да өрәбез.
Кызыл түгел, яшел түгел,
Татар киләчәге — соры.
Хыянәт көненнән башлап,
Кузгалыр кыямәт чоры.
Килер ул, озак көттермәс,
Татарның кыямәт көне.
Ә бүген әле, бары тик,
Оятсыз хыянәт көне.
Ояты бар — күрә дөнья,
Кыен ашап күпкә түзгән
Батыр бу халыкның коты
Төшкән ботына бер сүздән.
Илаһи, татлы Азатлык... —
Гасырлар буена түзеп,
Миллионлы зур халыкның
Өзеп әйткән соңгы сүзе!
Уйнамагыз Тарих белән!
Бутамагыз сүз мәгънәсен!
Бу оят, бу хыянәтне
Үтәр дисезме әллә сез?
Сүзе калсын, һич югында,
Үзе ятсын кысып тешен.
Яңа буын үсеп килә,
Өмет булсын алар өчен.
Бары тик Азатлык көне!
Җөмһүрият көне башка.
Хәтерләрдә шулай калсын,
Чокып куйган кебек ташка.

Әллә ашыгып өзгәнбез,
Бик ачы булды бу җимеш.
Утызынчы август көне
«Җөмһүрият көне», имеш.
Аннан соң шәһәр көнеме?
Урам көне булыр аннан...
Бәдрәф көне булып җиткәч,
Юдырырлар тартып баудан...

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

ИКЕ БӘЕТ: УРТАК ҺӘМ АЕРМАЛЫ ЯКЛАР

ФЛЁРА СӘЙФУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы, профессор,
КФУның татар филологиясе бүлеге мөдире

МЕҢЬЕЛЛЫК ҮСЕШ ТАРИХЫ БУЛГАН ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ҮЗЕН ТУЛЫЛАНДЫРЫП ТОРГАН ЧИШМӘЛӘРЕ – ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ ЯШӘП ИҖАТ ИТҮЧЕ КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ ИҖАТЫ ХИСАБЫНДА ҮСӘ, БАЙЫЙ. КЫЗГАНЫЧ, СОҢГЫ ЕЛЛАРДА СҮЗ СӘНГАТЕНДӘ ТӨБӘКЛӘРДӘН КИЛҮЧЕ ЯШЬ ӘДӘБИЯТЧЫЛАРЫБЫЗ КИМИ БАРА.

Бу яктан караганда, XIX гасыр — әдәбият үсешендә аеручa нәтиҗәле, үзенчәлекле, шәрык һәм гареп әдәби традицияләренең татар әдәбияты үсешенә тәэсир итеп, бик кызыклы, гыйбрәтле әдәби мирас тууына китергән чор. Без аны хәзерге Татарстан җирлегеннән тыш, Башкортстан, Оренбург өлкәләренең иҗади туфрагыннан күтәрелгән шагыйрьләр иҗаты, Пенза, Ростов-Дон якларыннан чыккан язучыларның ауропача прозасы белән баетылган, катлаулы әдәби процесс буларак кабул итәбез. Бу беркатлы, наив фикерле әдәбият, үзенең иманлы, денле булуы белән дә игътибар үзәгендә торырга хаклы.

Әдәби әсәрләре бүгенге көнгәчә килеп җитеп, укучыны кызыксындырган, дулкынландырган сүз сәнгате тусын өчен, әлбәттә, әдәби мохит, рухи байлыкның кыйммәтен аңлау, укымышлылык — замана таләбе булуы мөһим. Тарихчы, дин белгече, язучы Ризаэтдин Фәхретдин

җәнапләре XIX гасыр Себер җирлеге хакында нәкъ шундый фикердә. Бөтен дөньяга танылган «Асар» биобиблиографик хезмәтендә ул Тобол губернасының XVIII-XIX гасырларда Себер, Идел буе, Урта Азия якларыннан чыккан мәгърифәтче-галимнәрне берләштергән билгеле бер мәдәни-белем бирү үзәге булуы, һәм монда төрле тугандаш төрки халыкларының — уйгыр, казах, татар әдәбияты, мәдәнияте кисешүе турында яза. Шунда ук Р.Фәхретдин кулында күп еллар Тубыл шәһәрендә ахун булып торган, җирле балалар өчен мәдрәсә ачкан, үзе әдәби иҗат эше белән шөгыльләнгән Хуҗашөкүр бине Гаузбайның таб халкына (Тобол елгасының уң тарафындагы билгеле бер җәмәгать яки кабилә) багышлаган кульязма нәсыйхәтнамәсе булуы турында яза [1].

Күрәсең, мәгърифәтле кешеләр өчен биредә әдәби эшчәнлеккә җирлек булуы дөреслеккә туры киләдер. Бу фикерне раслап, монда заманасында даны төрле якларга таралган Ямбай мәдрәсәсе эшләвен, мәдрәсәдә меценат, танылгын сәүдәгәр Нигъмәтулла Кармышаков тарафыннан 2200 китап һәм кульязмалар тупланган китапханә булуы мәгълүм. Болар арасында Бохарадан, Согуд Гарәбстаныннан, Төркиядән һәм башка мөселман илләреннән китерелгән сирәк очрый торган китаплар тупланган булуы билгеле. Моннан тыш Тобол, Тара шәһәрләрендә дә китапханәләр булуы алдагы фикергә җирлек булып тора [2].

Алда күрсәтелгән хезмәттә Р.Фәхретдин «...гыйльми язмаларны, ата вә баба ядкәрләрен саклауда, безнең Идел буе мөселманнары белән чагыштырганда, Себер мөселманнары гайрәтлерәк булганлыклары күренә», дип язса да, татар әдәбияты тарихында әдәби әсәрләре сакланып калган һәм җентекләп өйрәнелгән әдипләр арасында иҗат җирлекләре белән Себер якларына караганнары күпсанлы түгел. Шулай да аерым җирле тарихчылар Тобол губернасы, аерып алганда, Карагай йорты (Вагай районы), кайчандыр «суфичылык үзәге» үк булмаса да, Нәкшбәндия тәрикате белән бәйле «мөселман районының үзәге», «үзенә күрә бер себер-татар яки себер-бохар хаҗиләренең оешкан урыны» дип саныйлар [3].

Иҗаты XIX гасырның икенче яртысына караган Мәүлекәй Юмачык (хәзерге хезмәтләрдә Йомачиков дип тә бирелә) (1834-1910) — сакланып калган истәлекләргә караганда, Себер якларында туып-үсеп, иҗатка килгән шагыйрь, үз заманының танылган шәхесләреннән берсе. Ул хәзерге Төмән өлкәсе Төмән районы Ямбай авылында (элекке Тубыл губернасы Ялутор өязе Манчыл авылы) туган. Шагыйрьнең шушы авылның атаклы мәдрәсәсендә укытучы булуы да билгеле. Заманының күп кенә танылган шәхесләре кебек үк, М.Юмачык та туган татар теленнән башка гарәп, фарсы, рус, казах телләрен белгән. Төрки дөньяга мәгълүм булган XIV гасыр шагыйре Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанын казах теленә тәрҗемә итүче шагыйрь — танылган татар мәгърифәтчесе Х.Фәезханов билгеләп үткәнчә, дистәләгән поэтик әсәр авторы [4].

Шагыйрь турында кайбер мәгълүматларны шушы мәкаләдә каралачак «Эрбет ярминкәсе» әсәреннән дә күрә алабыз:

Атымдыр Мәүлекәй ибне Юмачев,
Ялутыр өязедер Тубыллык.
Торагым Манчыл илдәдер, Төмәнлек,
Ул илдә күрмәдем һич тә яманлык.



Шул рәвешле, автор, борынгы әдәби традицияләрне дәвам итеп, әсәр кысаларында үзе турында беркүпме мәгълүмат бирә. Гомерен, аеруча аның соңгы яртысын, туктаусыз юлда үткәрсә дә, туган авылында яшәп, шунда үлгән дип фараз кылына.

М.Юмачык Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмуллалар замандашы, ләкин аның әдәби иҗат эшчәнлеге алардан соңрак, XIX гасырның 70 нче елларында гына башлана. Шуңа да карамастан, ул заманының укымышлылары арасында бик тиз танылып өлгерә. Ул чор әдәби тәнкыйте бу хакта: «Шул сәгый (тырышлык) вә гыйрәте сәмарәсе (нәтиҗәсе) уларак, бу кешенең исеме, Кырым «Тәрҗеман» гәзитләрендә күрелгәннән соң, рус гәзитләрендә вә Гареб гәзитләрендә дәхи күрелде», — дип яза [5].

Шагыйрьнең зур күләмле әсәрләреннән берсе — «Эрбет бәете» (1881) үзенең төзелеше һәм эчтәлеге ягыннан үзенчәлекле. М.Юмачыкның бу әсәре билгесез авторның «Мәкәрҗә бәете» басылып чыкканнан соң, шул бәет калыбында, аның аерым юлларын файдаланып, әлеге вакыт өчен кайбер «шикле» фикерләрне «төзәтергә» омтылып язылган булуы белән укучыда кызыксыну уята.

Билгеле булганча, патша цензурасы, ике гасыр изелеп, басылып килгәннән соң, беркүпме аякка баса башлаган татар әдәбиятын зур игътибар белән карап бара, хөкүмәткә карата ышанычсызлык белдергән яки каршы фикер язылган әсәрләр, әлбәттә, цензура «иләген» үтә алмый. Тыю салынган әсәрләр басылмый, үз укучысына барып җитә алмый. Мәүлекәй Юмачык әсәре өчен җирлек булып торган «Мәкәрҗә бәете»н дә шул ук «язмыш» көтә. Татар китапларын бәяләргә һәм бастырырга рөхсәт бирергә тиешле цензор барон Виктор Розен отставкага киткәннән соң, аның урынына христиан динен кабул иткән гарәп Фадуллаһ Сарруф билгеләнә.

Эрбет ярминкәсендәге кибетләр. XIX гасыр ахыры

Китапның баштагы өлешендә тормышны Мәкәрҗә ярминкәсе белән чагыштырып, кешеләрне изгелек, яхшы эшләр генә кылырга чакырып, бу дөньяда яшәгәндә ахирәтне, тәмуг газапларын уйларга кирәклегенә каткат басым ясап язылган әсәрне басарга яңа цензор рөхсәт бирә. Әсәр авторы тормышта да ярминкәдәге кебек, үз эшен белеп, тырышып башкарганнар уңышка ирешә, гаиләсе, балалары бәхетле яши, ә Мәкәрҗәгә ни өчен килгәнен онытып, эчеп-исереп, акча туздырып йөрүчеләр оятка кала, гаиләсенең тамагын да туйдыра алмый, дигән нәтиҗәгә килә. Ходай кушканнарны гына эшләп, кушмаганнардан тыелып яшәгән кешегә мәңгелек җәннәт, ә яман эшләр кылучыларга мәңгелек газап булуын автор суфичылык традицияләре буенча тәфсилләп, үтемле итеп яза. Әсәр Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә. Цензор, күрәсең, бәетнең икенче өлешенә игътибар биреп җиткермәгәндер. Әсәрнең «Бу дөньяда әгәр син хаким улсаң» дигән юллар белән башланып киткән әлеге өлешендә автор мәрхәмәтсез, халыкка золым китерүче, кулында мөмкинлек, власть булуыннан файдаланып, гади халыктан ел дәвамында әллә ничә кат очсыз-кырыйсыз салымнар, бүләкләр җыйган, гаделсез приставларны, теләсә ни язып утырган надан писарьларны, контор головаларын угрылар, залимнәр дип атый. Соңга таба алдарак язылган:

Дәфгы кыйлмаса ул этнең бәласен,
Җавапны сорамаслар ул этдин,
Заманны һәм алмаслар ул этдин.
Хуҗасына килер аның ояты, —

дигән юлларның асыл мәгънәсе дә ачыклана, этнең әйләнә-тирә кешеләргә кылган начарлыклары өчен иясе җавап бирергә тиеш булган кебек, халыкка шушы газапларны кылган урындагы җитәкчеләр өчен

дә министрлар, патша хәзрәтләре җаваплы, дигән фикер җиткерелә. Әсәр ахырында яңгыраган «*...әгәр дә халыкның ничек яшәве турында алар кызыксынып, вак җитәкчеләрнең эшен-гамәлләрен тикшереп торсалар, мондый хәл булмас иде*», дигән фикер, әлбәттә, патша хөкүмәте өчен кирәкле әйбер түгел. Мондый игътибарсызлыгы, сәяси наданлыгы өчен цензор Ф.Сарруф эштән куыла, аның урынына В.Д.Смирнов билгеләнә. Басылган китаплар җыеп, юкка чыгарыла. Казан университеты типографиясе директоры Готвалд, конфискация вакытында «Мәкәрҗә бәете» китабының берничә нөсхәсен яшереп, тарих өчен саклап кала. Үзенең китапханәсен университетка бүләк итеп күчергәндә, башка бик күп китаплар белән бергә, шушы басма да кире уку йортына кайтарыла. Галимнәр «Мәкәрҗә бәете»н татар әдәбиятында яңа әдәби жанр формасына нигез салучы әсәр буларак та бәялиләр [6].

Шушы хәлләрдән соң ике ел үткәч, шагыйрь М.Юмачыкның «Эрбет бәете» исеме астында язылган әсәренә дә уңай мөнәсәбәт күрсәтелми. Беренче әсәрнең стиле сакланса да, яңа әсәрнең авторы эчтәлеккә үзгәрешләр кертә, алдагы әсәрдәге «ялгыш» фикерләрне «төзәтә». Сәяси яктан «дөрес» язылган булуга карамастан, цензор В.Смирнов бу әсәрне бастырырга рөхсәт бирми. «Эрбет бәете» әсәре дә сәяси яктан ышанычсыз, фанатик язучылар исемлегенә кертелә.

Әсәрнең эчтәлеге аның авторының «Мәкәрҗә бәете» белән таныш булуын раслый, язылу стиле, хәтта кайбер юлларның алдагы әсәрдән алынган булуы «Эрбет бәете»н нәзирә җанрына кертеп карарга мөмкинлек бирә. Әсәренә җирлек итеп М.Юмачык үзенә якыннан таныш булган Эрбет ярминкәсен ала. (Эрбет — Себер яклары өчен таныш булган, хәзерге Екатеринбург өлкәсенә караган шәһәр). Монда башкалар белән бергә татар сәүдәгәрләренең дә катнашуы мәгълүм.

«Мәкәрҗә бәете»ндә «Бу дөньяның мисале бер Мәкәрҗә» дигән юллар әсәрнең асыл фикерен аңлатуга юнәлдерелгән булса, М.Юмачыкның әсәре:

Бу дөнья мисале Эрбеткә охшар,
Ахыры һәм ахирәт юлга охшар,

— дип башлана. Әсәр башында ук эчтәлегенең нинди характерда булуына ишарә бар. Шагыйрь үз вакытында Эрбеткә патшабикә Екатерина килүен искәртә, шулай ук Александр Николаевич җәнапләренең исемен дә мактап телгә ала, патшага тугрылыклы хезмәт итүче сенатларны, хәтта цензура комитетына да туктала. Аерым игътибарны патша Александр Александрович һәм аның гаиләсенә бирә. Тарихи шәхесләрнең телгә алынуы әсәрнең реалистик характерда, чынбарлыкка нигезләнгән булуын билгели. Алдарак автор үзенең исемен атап үтә һәм берничә тапкыр Эрбет мәкәрҗәсендә булуын әйтә. «Мәкәрҗә бәете» авторы кебек үк, М.Юмачык та үз эшен белеп башкарган сәүдәгәрләрне мактый, сәүдә вакытын заяга уздырган эшлексез, байлыкларын сарыф итүчеләрне тәнкыйтьли. Ул да, замана таләпләре буенча, эшмәкәрлекне Ходай Тәгалә каршында кирәкле, изге гамәлләрнең берсе буларак тасвирлый, эчүче, акча туздыручыларны теге дөньяда җәза көтүен ассызыклый.

Әсәр эчтәлегендә автор аны «нәсыйхәт» — яхшы юлга үгетләү, өйрәтү дип бәяли һәм әсәренең төп максатын да шуннан гыйбарәт дип билгели.

Бу әсәрнең эчтәлеге дә ярминкә көннәрен тасвирлау белән башлана. Эрбет ярминкәсенә төрле яклардан бик күп сәүдәгәрләр килә. Алар арасында төрле кешеләр бар: әхлаксызлар, эчүчеләр, начар эшләр белән шөгыльләнүчеләр дә җитәрлек. Авторның үзе булып кабул ителгән герой кайчандыр шундыйлар арасында үзенең дә булганлыгына үкенү белдерә:

Ни өчен белмәдем һич килдегемне,
Танымадым көне-төн булдыгыны.
Сату өчен һич булмады сагышым,
Шуның өчен булмады
минем табышым.

Бу очракта, әлбәттә, М.Юмачык эшен уйламыйча, начар юлда акча туздырып йөрүчеләрне тәнкыйтьли, киресенчә, эшмәкәр, исәп-хисап эшен дөрес оештырган сәүдәгәрләрне мактый.

Рәхмәт яусын, Ходаем,
шул кешегә —
Сатып сәүдә кыйлып йөргән эшенә.

Шагыйрь Ходайдан гафу сорый һәм кешеләрнең холык-фигылен төзәтүне үтенә. Урта гасыр суфи шагыйрьләр кебек, М.Юмачык кеше тормышының чиксез түгеллеген искәртә: бу җиргә исәпсез-хисапсыз падишаһлар, пәйгамбәрләр килеп-киткән. Беркем дә үлемнән өстен түгел, барыбызга да Ходай каршына барасы. Шуңа күрә Ходайга баш ияргә, шәригать кануннары белән яшәргә кирәклегенә каткат басым ясый.

Шуның белән бергә «Эрбет бәете» авторы гади халыкка теләктәшлек белдерә, үзеңнән түбәннәргә мәрхәмәтле булу — кешене Ходай Тәгалә белән якынайта торган гамәл, дигән фикер җиткерә.

Төне-көн иҗтиһат кыл яхшылыкка,
Яманлык кыйлмагыл
һичбер халыкка.
Рәхим ит сән фәкыйрь —
мискин, гидайга,
Тәзарруг әйләгел даим Ходага.

Шагыйрь уенча, җирдә үзенең яшәү асылын аңлаган, акыллы кешеләр булган кебек, бу тормышта ахмаклар, яшәү мәгънәсен белмәгән наданнар да җитәрлек. Тормыш мәгънәсе турында уйланулар М.Юмачыкның бу әсәрен суфичылар иҗаты белән аваздаш итә. Бәетнең кайбер юллары XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьяр юлларын хәтерләтә:

Әгәр бу дөньяда кылсаң яманлык,
Бәс, ул көндә табарсың
һәм яманлык.
Кеше, богдай сачеп, арпа алалмас,
Яман эшдин дәхи файда табалмас.

Шушы урында автор тагын бер тапкыр исемен укучы исенә төшерә һәм кәгазьгә язылган сүзләре аша исеменең киләчәк буыннарга барып ирешүенә өмет белдерә:

Сәңа да ошбу вәгъдә бер киләчәк,
Кайда китте атаң синең Юмачык?
Үзең һәм бергә сән ошбу вәгазьдә,
Үзең үлсәң, хатың калыр кәгазьдә.

«Мәкәрҗә бәете» авторы әсәренең төп өлешендә халыкның авыр хәле, патша чиновникларының халыкны талавы, социаль тигезсезлек турында яза. Әсәренең ахырында М.Юмачык та идарә-патша темасына туктала, ләкин «Мәкәрҗә бәете»ннән аермалы буларак, аларны гадел идарә итәләр дип белдерә. Үзеннән алда язган авторның фикерләренә «төзәтмә» кертеп, бәет авторы: «Әгәр патша җәнаплары безнең балаларны

хезмәткә ала икән, бу бит безнең файдага гына, алар безне саклаячак», — дип яза. Алга китеп, шагыйрь тагын да: «Безнең патшабыздан гадел хөкемдар юк, безгә һәм безнең динебезгә бер начарлыгы да булмады; барыбызга да үз балаларына караган кебек карый, барчабызга — урысларга да, мөселманнарга да», — дип фикерен дәвам итә. Автор фикере буенча, судьялар да, конторда утыручылар да патша тарафыннан хаксызлык, караклык кебек эшләр булмасын өчен куелган.

Шул рәвешле, М.Юмачык алдагы әсәр эчтәлегендә бирелгән фикергә «төзәтмәләр» кертә. Аеруча сүз чиновниклар турында барганда, шагыйрь аларның эшчәнлеген матурлап, патша хөкүмәтенең гаделлегенә басым ясап яза, патшаның бөтен гамәлләре дә халык бәхете өчен, дигән фикерне үткәрергә тырыша.

М.Юмачык әсәренә кайбер юлларны турыдан-туры алдагы әсәрдән ала:

Янә бер мәхкәмәне ясамышлар,
Аны «Кантур» дәюбән атамышлар,
«Глава», диләр аның рәисе…
Халык үзрә хөкем кылгу хәсиятенә.

Ләкин аннан соң фикерне үзенчә дәвам итә: чиновниклар, бай яки ярлы булуына карамастан, бөтен кешегә дә бердәй тигез карыйлар, ди. Алар халык тыныч яшәсен өчен тырышалар, шуңа күрә аларга буйсынырга кирәк, дигән фикерне җиткерә. Шул рәвешле, М.Юмачык «Мәкәрҗә бәете» авторы белән бәхәс-полемикага керә.

Аларга тугры булмай һич ярамаз,
Шуның өчен бүләгеңә карамаз.
Баең, ярлыга бердәй булалар,
Сәнең акчаң белән ни кылсын алар.

Чиновниклар — закон яклы, әгәр дә халыкка карата дорфа булсалар, аларның мондый эшенә беркем дә түзеп тормас, алар җәзага тартылырлар иде, дип яза. Бөтен кеше дә, үзен дә, малын да кызганмыйча, бик шатланып патшага хезмәт итәргә әзер, чөнки бөтенебез дә уртак Ватаныбызның нык булуын, чәчәк атуын тели, дип үз фикерен ныгытып та куя. Шуңа күрә Коръәнгә таянып, бөек патшага хезмәт итәргә кирәк, дигән фикерне куәтли.

«Мәкәрҗә бәете»ннән аермалы буларак, үз әсәрендә М.Юмачык әсәренең тәнкыйди пафосын күпкә киметә, патша идарәсенә караган өлешләрне йомшартып, гел уңай яктан гына чагылдыра.

«Әгәр дә «Мәкәрҗә бәете» конторны һәм анда эшләүчеләрне М.Е.Салтыков-Щедрин рухында тәнкыйтьләгән булса, М.Юмачык исә күпкә саграк һәм алдан уйлап эш итә. Бер сүз белән әйткәндә, әсәр авторы шул вакыттагы консерватив карашлы, әле дә яхшы патшага һәм аның ышанычлы ялчыларына ышанучы патриархаль крестьяннар карашларын чагылдыра. Шуңа да карамастан, М.Юмачык бәете заманча рух белән сугарылган, аның авторы мәсьәләләрне куя һәм үзенчә чишелешләрен дә таба. Авторның симпатиясе, һичшиксез, гади халык ягында» [6].

Ләкин эчтәлеге белән турыдан-туры патша хөкүмәтен яклап язган әсәр дә патша цензурасын үтми. Күрәсең, властьларга патша идарәсенең бөтен асылын ачып салган «Мәкәрҗә ярминкәсе»н тагын бер кат халыкның исенә төшерү кирәкмәгәндер. М.Юмачыкның «Эрбет ярминкәсе» бары тик йөз елдан артык вакыт үткәннән соң, 2006 елда гына «Мин — себер татарымын» дип

аталган җыентыкта дөнья күрде. Китапны басмага әзерләүчеләр тәкъдим ителгән текстның кульязмасын язучы Ә.Фәйзинең шәхси архивында табуларын белдерәләр. (Язучы әсәрнең кайбер өзекләрен үзенең «Тукай» романында куллана). Бүгенге көндә әсәрнең оригиналы ТР Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар бүлегендә саклана.

Бу әсәренең эчтәлегенә караганда, М.Юмачык консерватив карашлы шагыйрь булган дип әйтергә мөмкин. Тик галимнәр бу карашларның үзәктән читтә яшәүче белемле кешеләрнең дөнья турында үзенчәлекле күзаллаулары чагылышы дип бәялиләр [6].

Кайбер галимнәр, бәлки автор шул юл белән тизрәк цензор рөхсәтен алырга тырышкандыр яки мондый караш социаль заказ нәтиҗәсе дә булырга мөмкин, дигән караштa торалар, чөнки авторның җәмәгать эшлеклеләре, сәүдәгәр-меценатлар бертуган Рәхмәтулла һәм Нигъмәтулла Сәйдуковларга багышлап шигырь язуы билгеле.

Икенче яктан, әле XVIII гасырда ук үзәкләштерелгән патша хөкүмәтен яклап, идеаллаштырып язылган әсәрләр күренә. Кадыр-Али Җалаер бәкнең «Җәмигъ әт-тәварих» әсәре шундыйлардан, монда да уртак Ватан идеясе күтәрелә.

Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүчеләр өчен әсәрнең ахыр ягы кызыклы. Башта ук үзе турында мәгълүмат биреп үткән автор тагын да үз шәхесенә кайта һәм инде тугыз китап язуы турында искәртә, шунда ук аларны бастыру һәм тарату мөмкинлеге булмавын да әйтеп үтә.

«Шәехе Бәркый», «Сәед Баттал»,
«Каракол»,
Дүртенчесе — «Мөнәҗәт»тер,
моны бел.
Будыр бишенчесе «Гокъбә» дигәндер.
Янә берсе «Васыятьнамә» дигәндер,
Йиденчесе — «Салсал кыйсса»
дирләр,
Янә берсе — «Әнмүзәҗ» аңа
дирләр...

1879 елда басылган «Кыйссаи Салсал» китабында автор санап үтелгән әсәрләренең инде дүртесе бастырылган булуын әйтә.

Әсәр кысаларында тагын бер исем искә алына, күрәсең, бу кеше шагыйрьнең китапларын бастырырга алына, ләкин моннан файда чыкмый:

Барын да бастырып
Шәмсетдин алды,
Согубәт мәнкуләте үземә калды.

Әдәбиятыбызда XIX гасырның беренче яртысында Габделҗаббар Кандалый башлаган реалистик юнәлеш, гасырның икенче яртысындагы шагыйрьләр иҗатында, шул исәптән М.Юмачык әсәрләрендә дәвам иттерелә. Гади җир кызына мәхәббәт хисләренә багышланган лирик шигырьләре авторны хатын-кыз иреге турында фикер йөртүче мәгърифәтчеләргә якын итә. Кызларны укымышлы иргә кияүгә биреп, бәхетле итү теләге авторның шул заман әдипләре бәлән фикердәш булуын күрсәтә. Аның лирик әсәрләре халык иҗатына якынлыгы, шигъри теленең байлыгы белән аерылып тора. Башка мәгърифәтчеләр кебек үк М.Юмачык та муллаларны халыкны гыйлемле, мәдәниятле итәргә тиешле кешеләр дип саный, халыкның надан булып, авыр тормышта яшәвенә дә алар гаепле дигән фикер 1898 елда басылган «Мәрхабә, шәһре рамазан» җыентыгына кертелгән «Хуш

киләсең, рамазан ае» әсәрендә дә яңгырый.

Мактар, ялагайланыр
байлар каршында,
Ярлыларның игътибар итмәс сүзенә.
Вәгазь кылса, кылыр байга яраклы,
Ни дисә, дияр алар табигатенә лаек.
Күз дөнья гыйшкына батканга,
Вәгазь сүзе халыкка тәэсир итмәс.

Үз вакытында әдәбият белгече М.Гайнуллин да бу әсәрдә муллаларга каршы тәнкыйть фикере чагылыш табуына игътибар иткән иде [7].

1899 елда Казанда М.Юмачыкның кечкенә генә «Мәрхәбәи шәһри рамазан һәм тәварих тәсбихләре» китабы басылып чыга. Дини-дидактик эчтәлекле бу китап пәйгамбәрләр тарихына багышланган. Әсәрнең соңгы өченче өлеше шагыйрьнең үз заманы турында фикерләрен эченә ала. Автор бик ачынып изгеләр заманы үтүен, көнчел, ялганчы кешеләр заманы җитүен, хөсетлек, явызлык, денсезлек, оятсызлык төп сыйфатларга әйләнүен яза. Автор үз заманы байларының икейөзлелеген, байлык өчен иманын да бирергә әзер торуларын күрсәтә. Гади халык исә авыр эштән интегә, шул сәбәпле мәчет юлын онытып бара, дип чорының асылын ачып сала. М.Юмачык фикеренчә, замана чынбарлыгы нәкъ шуннан гыйбарәт.

Шул рәвешле, татар әдәбиятында Г.Утыз-Имәнидән башлап М.Акмулла иҗатына кадәр актуаль булган социаль-этик проблематика М.Юмачык иҗатының да асылын тәшкил итә.

Мифтахетдин Акмулла, Әхмәт Уразаев-Кормаши кебек ул да беркүпме гомерен казах далаларында балалар укытуга багышлый. Шул сәбәпле әсәрләрен татар, казах, башкорт кешеләре аңларлык уртак бер телдә яза. Төрки халыклар өчен уртак булган тел турында фикерләр 1860 елларда С.Кукляшев, К.Насыйри тарафыннан да күтәрелә. М.Акмулла, Ә.У.Кормаши, М.Юмачык иҗатларында аны гамәлгә ашыру үрнәкләрен күрергә мөмкин.

Шул рәвешле, бай тормыш биографиясе, актив иҗаты себер татарлары арасыннан чыккан шагыйрь М.Юмачыкны үз заманының үзенчәлекле шагыйре итеп таныта. Аның иҗади мирасы авторның дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра. Әсәрләренең тематик киңлеге, мәгърифәтчелек карашларын яклавы, тел үзенчәлекләре иҗатын XIX гасыр әдәбиятының игътибарга лаеклы күренеше итеп саналырга хаклы икәнен раслый.

Чыганак:

Юмачиков М. Эрбет бәете. Китапта: Мин — себер татарымын. Шигырьләр // Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Х.Корбан. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. — 160 б.

Әдәбият:

1. Фәхретдинов Р. Асар. — Казан: Рухият, 2006.— 359. — Б.35.
2. Гарифуллин И.Б. Себердә татар китапханәләре // Тумашевские чтения: Актуальные проблемы тюркологии: материалы Всероссийской науч.-практ. конф. — Тюмень: ТюмГУ, 2007. — С.52-55.
3. Белич И.В. Ханское кладбище // Сибирская столица. — Тобольск. — 1997. — №1. — С. 55-73.
4. Фәезханов Х. Мөхәррикәл-фикер. — Казан, 1893. — Б.22.
5. Миръат. СПб., 1900, 1 кисәк. Б. 25-26.
6. Татар әдәбияты тарихы: 6 т. Т. 2. XIX йөз татар әдәбияты. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. — Б. 143-145.
7. Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1968. — Б. 159.

ИДЕЛ ЯРЫНДА

РИНАТ МӘННАН

Утырам Идел ярында,
Кояштан күз камаша.
Дулкыннарның тавышларын
Аңларга мин тырышам.

Ничә гасыр үтеп киткән,
Тып-тын Болгар таулары.
Дулкыннарның иң-сыртында
Бабамның сораулары.

«Иманлымы сез бездән соң?
Язасызмы дастаннар?
Бәхетле булдымы безне
Кырып киткән дошманнар?

Җәйләр һаман да эссеме?
Бик кырысмы кышлары?
Ник чиркәүләр нигезендә
Безнең кабер ташлары?..»

Яшел таулар артларына
Инде яткан кояшы...
Дулкыннар шавында ерак
Болгар бабам тавышы.

ГАЗИЗ КАШАПОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

«ДӨНЬЯ ЯРЫП АТЛАП КИЛӘМЕН...»

(Г.Кашапов иҗатының кайбер үзенчәлекләре)

РАДИК САБИРОВ,
филология фәннәре кандидаты,
КФУ доценты

КЫЗГАНЫЧ КИ, ӘДӘБИЯТ ГЫЙЛЕМЕНДӘ НИНДИДЕР СӘБӘПЛӘРГӘ БӘЙЛЕ АЕРЫМ БЕР ӘДИПЛӘРЕБЕЗ ИҖАТЫ, ШӘХЕСЕ ҺАМАН ӨЙРӘНЕЛМИ, АЛАРНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЛАРЫ ДА КҮЛӘГӘДӘ КАЛА. КЕМНӘРДЕР ЧОР, ИДЕОЛОГИЯ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛМӘҮ СӘБӘПЛЕ ОНЫТЫЛГАН, ИҖАТЫ ДӨРЕС БӘЯЛӘНМӘГӘННӘРЕ ДӘ ҖИТӘРЛЕК, КАЙБЕРӘҮЛӘР ТОРМЫШТАН БИК ИРТӘ КИТҮ СӘБӘПЛЕ, ӨЙРӘНҮ-ТИКШЕРЕЛҮ БӘХЕТЕННӘН МӘХРҮМ КАЛГАН. ГАЗИЗ КАШАПОВ ДИГӘН ЯЗУЧЫНЫҢ ӘДӘБИ МИРАСЫ ӨЙРӘНЕЛМИ КИЛҮЕН ӘНӘ ШУЛ СОҢГЫ СӘБӘП БЕЛӘН БӘЙЛӘП КАРАРГА МӨМКИН. ӘДӘБИ ЭШЧӘНЛЕГЕН ЧАГЫШТЫРМАЧА СОҢ БАШЛАП ҖИБӘРГӘН ТАЛАНТЛЫ ӘДИП ФАНИЛЫКТАН БАКЫЙЛЫККА БИК ИРТӘ – НИБАРЫ 49 ЯШЕ ТУЛГАН КӨННӘРДӘ КИТЕП БАРА. КӨН КЕБЕК АЧЫК: ИҖАТ ДӘРЬЯСЫНДА УЛ ҮЗ СҮЗЕН ӘЙТЕРГӘ ӨЛГЕРМИ КИТӘ. БЫЕЛ ИСӘ АҢА 70 ЯШЬ ТУЛГАН БУЛЫР ИДЕ.

Газизҗан Салих улы Кашапов 1942 елның 21 августында Татарстанның Аксубай районы Яңа Үзи авылында туа. Әтисе сугышта һәлак була, әнисе Бану исә, кечкенә Газизҗанны әбисе кулында калдырып, авылдан китәргә мәҗбүр була. Малай әбисе тәрбиясендә үсә. 1957 елда ул туган авылының җидееллык мәктәбен, ә 1960 елда Иске Ибрай авылы урта мәктәбен тәмамлагач, ике ел колхозда хисапчы ярдәмчесе, тракторчы, клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә армиягә алына. Башта курсант, аннары гаскәри частьтә механик булып хезмәт итә, хәрби училище тәмамлый. Әтисе офицер булгангадыр инде, Газиз дә офицер шинелен кию турында хыяллана. Әмма 1969 елда һәлакәткә очрый, алган җәрәхәтләреннән каты авырып китә, бик озак госпитальдә дәвалана һәм, ахыр чиктә, хәрби хезмәттән китәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, балачактан килгән ике хыялның берсе чәлпәрәмә килә.

Икенче хыялын — язучы булу теләген тормышка ашыру өчен, Г.Кашапов 1973 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, бер үк вакытта, 1974-1982 еллар арасында Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы, Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакциясендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе, язучыларның Чаллы шәһәре оешмасында пропаганда бүлеге хезмәткәре һәм оешма җитәкчесе булып эшли. Кызганыч, 1991 елның 30 августында йөрәк өянәгеннән вафат була, үзенең васыяте буенча туган авылында җирләнә. Бүгенге көндә Яңа Үзидә аның истәлегенә музей эшләп килә.

Г.Кашаповның әдәбият дөньясына килеп керүенә нык тәэсир иткән вакыйганы атап үтәргә кирәктер. 1956 елда «Татарстан яшьләре» газета-

сында шул чорның күренекле язучысы Габдрахман Әпсәләмовның Аксубай районы Яңа Үзи җидееллык мәктәбе укучысы Газиз Кашаповка атап язылган ачык хаты басыла. Хат «Ничек язучы булырга?» дип атала. Әлеге хат-фатихада мондый юллар бар: «Әдәби әсәр язу, ул бит, Газиз дус, самолёт йөртүдән дә читенрәк, катлаулырак эш. Әдәбият әсәрләре кешеләрне яшәргә, тормышны аңларга өйрәтә, кешеләргә тәрбия бирә. Язучының тормыш тәҗрибәсе, белеме бай һәм тирән булырга тиеш. Әгәр Сезнең, яшьлегегез сәбәпле, тормыш тәҗрибәгез бөтенләй юк икән, белемегез кечкенә икән, Сез кешеләрне нәрсәгә өйрәтә аласыз? Иң элек, Газиз дус, Сезгә укырга, укырга һәм тагын бер тапкыр укырга кирәк. Уку белән беррәттән, тормышны, кешеләрне күзәтегез, тел җәүһәрләрен — халык җырларын, мәкальләрен, әйтемнәрен җыйнагыз, өйрәнегез...» Танылган әдип язган ике бит ярымлык ошбу хатның гапгади авыл малаена никадәр тәэсир ясаганлыгын чамалау кыен түгелдер.

Газиз Кашаповның иҗат гомере озын түгел, нибары унбиш еллап вакытны үз эченә ала. Әлбәттә, шушы кыска вакыт эчендә сүз сәнгате өлкәсендә үз сүзеңне әйтү, үз йөзеңне булдыру — шактый авыр эш. Ләкин Г.Кашаповның милли сүз сәнгате тарихында үз урыны бар, дип ышанып әйтергә мөмкин. Ул үз иҗатында беркемне дә кабатламый, үзенә генә хас тематик өлкәсе белән аерылып тора, образ-геройлары да истә калучан. Беренче чиратта, отставкадагы офицер Кашапов татар әдәбиятында Г.Әпсәләмов, Х.Камалов, Ш.Рәкыйповлардан соң онытылып торган хәрби теманы яңартып җибәргән язучы буларак танылу ала. Бөек Ватан сугышы темасына өстенлек биргән югарыда аталган язучылардан аермалы буларак, аның әсәрләре үз чоры армиясе хакында, әсәрләрендә хәрби тормыш та бөтен каршылыгы, яхшы яклары, начарлыклары белән сурәтләнә. Һәм алар ышандыра да, чөнки реалист язучы буларак, Г.Кашапов әсәрләренә бары тик үзе күргәннәрен, ишеткәннәрен генә чыганак итеп ала. «Әти йолдызы», «Әтием хатирәсе», «Сәмум җиле» кебек хикәя-повестьларын, гомумән, автобиографик характердагы әсәрләр дип атарга җирлек бар.

1976 елда Г.Әпсәләмов «Социалистик Татарстан» газетасында «Икенче ачык хат»ын яза. Бу юлы инде ул Кашаповның яңа гына «Казан утлары» журналында басылган «Сәмум җиле» повесте турында фикер йөртә, әсәргә «карт солдатның йөрәген айкап җибәрде» дип, үзенең җылы бәясен бирә, шунда ук әсәрне камилләштерү юлында киңәш-теләкләрен дә җиткерә.

«Сәмум җиле» әсәрендәге төп вакыйгалар, хәрби хезмәттәге приказны үтәгәндә каты яраланып, хәрби госпитальгә эләккән Рамиз Җәләевның язмышы тирәсендә оеша. Әлеге вакыйгалар ретроспектив вакыт ярдәмендә геройларның хатирәләре, эчке монологлары рәвешендә сурәтләнә. Икенче якта исә госпитальдәге врач Ирина Геева, Рамизның әнисе тора. Ирина мисалында автор гомере буе үз улын күрергә хыялланып яшәгән Ана образын гәүдәләндерә. Ләкин Кашаповның анасы башкаларныкы кебек түгел, ул хәрби кеше, аның язмышы да хәрбиләрчә: кайда кушалар — шунда бару, боерыкларны җиренә җиткереп үтәү, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртмау. Нәкъ

менә шундый иҗтимагый вакыйгалар тәэсирендә ана заманында улы Рамиз белән аерылыша.

Әсәрнең «Сәмум җиле» дип аталуы да очраклы түгел. Беренчедән, әсәрнең исеме Рамиз чүл уртасында юлыккан һәм шул якларга гына хас булган сәмум җиле дигән табигать күренеше белән бәйле. Әлеге өлеше төп сюжет линиясендәге вакыйгаларга фокус булып тора. Сәмум җиле — бик зур сынау, ком болытына бары тик иң көчлеләр генә каршы тора ала. Рамизның госпитальдә яраланып ятуы да — үлем белән көрәшү — сәмум җиле белән көрәшү буларак аңлашыла. Җилгә каршы тора алган Рамиз авыруны җиңеп чыга, үлемнән кала. Ахыр чиктә, аны сәмум җиле беткәндәге кебек тыныч тормыш — әниле тормыш көтә.

Кашаповның вакыйга һәм геройларны тормыштан алып язуына игътибар итеп, язучының университеттагы укытучысы, әсәрләренә тәүге фикер әйтүче Мөхәммәт Мәһдиев болай дип белдерә: «Солдат тормышын ул күргәннәреннән чыгып яза. Газиз — шинельне кайсы яктан төймәләсен, винтовканы яки автоматны пирамидага ничек куясын, иртәнге «подъём» командасында ятагыңнан сикереп төшкәч, иң башта нәрсә киясен яхшы белә. Китаплардан укып түгел... Дилетантлыкны теләсә кайсы өлкәдә гафу итеп була, ләкин әдәбиятта — булмый» [1]. Галим шулай ук Кашаповның әсәрләрендәге «салкынлыкның, нидер җитмәүлекне һәм аның сәбәбен» дә ачып сала: «Ни җитми? Соңрак аңладым: язучының тел-тасвирлау чараларына җылылык җитми. Моның сәбәбе бар: яшьлеге формалашкан чорга туры килгән казарма, строй, наряд — рәхимсез, кырыс устав таләпләре. Шулардан башка армия буламыни?» [1]. Мәһдиевнең әлеге фикерләре белән икенче бер олуг язучыбыз, шулай ук Кашаповның сирәк дусларыннан берсе Аяз Гыйләҗев тә килешә: «Безнең язучылар күргәннәре әзлектән, кичергәннәре сайлыктан җәфа чигә. Язучының иҗат биеклеген үзе кичергән язмыш та, әлеге кичерешләренә бирә алган бәянең гаделлеге дә билгели. Газиз үз чордашлары арасында иң бай тормыш кичергән шәхес иде» [2].

Татар әдәбиятында яңалык буларак яңгыраган «Убырут» повесте — Г.Кашапов иҗатында сыйфат үзгәреше барлыкка килүен раслаган әсәр. Үткәндәге гаепләре өчен шартлы образ — Ят Тавыш-Вөҗдан тарафыннан хөкем ителгән Мәүләви образын үзәккә алган «Убырут»та (мишәрләрдә шайтан таягын шулай атыйлар) беренче планга психологизм чыга. Реаль булмаган серле сихри образларга мөрәҗәгать итү, романтизм өчен хас булган эчке кичерешләр, әсәрне психологизм белән баетуда катнашкан теге яки бу күренеш-хисләрнең образ дәрәҗәсенә күтәрелүе егерменче гасыр ахыры татар әдәбиятында постмодернизм билгеләренең барлыкка килүенә ишарәли. Повестьтагы Вөҗдан тавышы, аның сөйләме әсәрнең гомуми структурасын барлыкка китерүдә дә төп рольне уйный.

Бу әсәрдә әдәби детальләр, символлар кулланылышы игътибарга лаек. Әйтик, песи образы, давыллы-яңгырлы төн, имән символы һәм әлеге меңьяшәр агачның урталай сыну күренеше, Ят Тавыш — Вөҗдан образы, үләт базы — бар да кичәге гөнаһлары өчен вөҗдан газабы

кичерүче төп геройның холкын ачу өчен кулланыла. Вөҗдан темасын үз эченә алган дип әйтергә мөмкин булган әлеге әсәрдә гөнаһ-җәза-тәүбә итү эволюциясе аша рухи чистарыну мотивы беренче планга чыга.

Газиз Кашапов «Убырут» әсәрендә урын һәм вакыт хронотопларын иркенләп эшкә җигә. Язучы юл хронотобына да нык игътибар бирә. Мәсәлән, Мәүләвинең авылга кайтып, чишмәгә бару юлы. Чишмә — чистарыну, гөнаһлардан арыну, тәүбә итү. Күпердә үзе рәнҗеткәннәрне очрату — үткәндәге Мәүләви белән вөҗданы уянган Мәүләви арасындагы күпер. Күперне кичкәч, ул аз гына булса да чистарына. Юл — Мәүләвинең хәрәкәт итүе буларак билгеләнсә дә, чынлыкта, чистарынуга таба ачыла барган юл. Авылдагы йортына килүе дә очраклы гына кермәгән, кеше гомере ахырында туган нигезендә таяныч эзли. Нигез йортка кайтып бәхиллек сорау — Аллаһ каршына килеп басканчы тәүбә итү. Ләкин... Ләкин Мәүләви гафу ителми. Һәм ул янә урманга юнәлә. Һәм шунда барганда гына үләт базын күрә. Әлегрәк шушы җирләрдә күпме йөрсә дә, Мәүләви үләт базы исен бер дә сизмәгән. Димәк, ул, ахыр чиктә, барыбер үз үлеменә таба бара.

«Убырут» Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повесте белән охшаш. Ике әсәрдә дә һәркемгә фани дөньялыкта кылган гамәлләре өчен җавап бирергә туры киләчәк дигән идея үткәрелә. Кеше гомере ахырын күз алдында тотып, А.Гыйләҗев өч аршын җиргә дә лаек булып яшәргә кирәк дип белдерсә, Г.Кашапов Мәүләви кебекләрнең урыны — үләт базында, дип нәтиҗә ясый.

Г.Кашапов иҗатындагы кызыл җеп булып баручы тагын бер юнәлеш — әдәби әсәрләрдә Хәсән Туфан образын гәүдәләндерү. Университетны тәмамлаган чорда язучы үзенең диплом эшен якташы иҗатын өйрәнүгә багышлый. Эшне яклау чарасында Туфан үзе дә катнаша һәм хезмәттән бик канәгать кала. Шуннан Кашапов Хәсән ага белән әдип үлгәнчегә кадәр аралашып яши, тормыш юлын, иҗатын өйрәнә. Аны бигрәк тә дәвер фаҗигаләрен үз җилкәләрендә шактый татыган шагыйрьнең биографиясе кызыксындыра, ул ничек тә булса әдипнең гаепсезлеген, чисталыгын расларга, тормышындагы ачылмаган «ак битләр»не бетерергә тырыша. Х.Туфан үзе дә эчкерсез күңелле, нечкә җанлы яшь якташына битараф булмый, аның белән теләп аралаша, хатлар алыша, тормышын ача (ул хатларның кайберләре Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында саклана).

Соңрак язучы Туфан эзләре буенча Пермь, Новосибирск, Томск шәһәрләрендә була, Себерне айкап кайта, сөргендә чакта Туфан яшәгән землянкаларда төн куна, Мәскәү, Казандагы архивларында казына, аны белгән кешеләр белән таныша. Зур тырышлыклар белән Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәрендә мемориаль такта куйдыруга ирешә. Туфан Миңнуллин белән берлектә анда Хәсән Туфанның юбилей кичәләрен үткәрә, иҗаты, тормыш юлы, татар әдәбиятында тоткан урыны хакында халыкка җиткерә. Шагыйрь иҗаты һәм биографиясе белән бәйле булган язмаларны уку өчен, тиз арада гарәп әлифбасын өйрәнә...

Романда Хәсән Туфанның балачагы, төгәлрәк итеп әйткәндә, тууыннан алып унөч яшьләренә кадәр булган

вакыты сурәтләнә. Иң элек, автор Хәсән Туфанның туган авылы Иске Кармәт тарихын тасвир итүгә алына. Биредә тарихи белешмә биреп китү үзмаксат түгел. Кашапов кешенең борынгы тамырларына, нәсел-нәсәбенә зур игътибар биргәндә генә Шәхес булып җитлегүен күрсәтергә уйлый кебек. Алай гына да түгел, кешенең фани тормышта тоткан урыны, ирешкән казанышлары күп очракта туган нигез, туган як белән бәйләнештә нык ачыла. Әсәр башында сурәтләнгән Карый Өммәт кабере турындагы вакыйга биредә яшәүче халыкның холык-гадәтен, менталитетын, үзенчәлекләрен ачуга корылган. Әлеге кабернең авыл уртасында булуы — элеккеге буыннарны, бабайларны ихтирам итү билгесе.

Автор шагыйрьнең тормышы ни өчен катлаулы булуына җавап табарга тырыша. Һәм шуңа мөнәсәбәтле укучыларны Чал колак кушаматлы бүре вакыйгасы белән таныштыра. Фәхри-Таһирның кешеләрне ашап, сарыкларны буып йөрүче бүреләргә ачуы чыга һәм ауга бара, бүреләр башлыгы Чал колакны үтерүгә ирешә. Бүренең үләр алдыннан уйланулары игътибарны җәлеп итә: «Туачак улыңа каһәр суксын! Аның бу дөньяда кичерешләре минекеннән ким булмасын. Күрмәгәне калмасын. Аны да үз ишләре ашасын, үз өерләреннән кусын, гомерен минем кебек караңгы өннәрдә үткәрсен».

«Киек каз юлы»ндагы бүре вакыйгасы тулы бер әсәргә фокус булып торуга дәгъва итә. Алга таба бу вакыйганың өлешләре белән башкача ракурста әсәр буена очрашабыз. Бу очракта бүреләр тормышын җентекләп тасвир итү Туфан гомер итәчәк җәмгыятьне сурәтләү буларак аңлашыла. Рәнҗетелгән җәнлек-хайваннарның каргышы дигән күренеш аучыларда гына түгел, гади кешеләрдә дә буыннан-буынга күчеп дәвам иттерелә, әдәби әсәрләрдә дә әлеге мотивка шактый урын бирелә. Әйе, шик тә юк, Чал колакның каргышы Хизбулла-Хәсәннең тормышында да үз ролен уйный. Димәк, бер яктан, бүре вакыйгасы ул әнә шул каргыш-рәнҗеш белән бәйләп каралса, икенче яктан, төп геройны, гомумән, кешелекне бүреләр җәмгыяте чолгап алганлыкны аңлата.

Роман булачак шагыйрьнең Уфага «Галия» мәдрәсәсенә барырга җыенып калуы белән тәмамлана. Бердәнбер үкенеч: әсәр тулысынча язылып бетми. «Туфан озын гомер кичергән, төрледән-төрле вакыйга-хәлләргә бай тормышлы шагыйрь, аның язмышы — татар әдәбияты язмышы, XX гасыр фаҗигасе... Г.Кашапов шагыйрьнең сөргенлек эзләреннән йөреп, биографиясенең четерекле буыннарын өйрәнеп, йомгакның очларын барлап кайткан иде. Туфан әлегә әдәбиятта сәләтле, сизгер җанлы, яшьтәшләреннән өстен, әмма малай булып калды. Кызганыч...», — дип белдерә бу уңайдан тәнкыйтьче, әдәбият галиме Тәлгат Галиуллин [3].

Газиз Кашаповның Туфан образын яктыртуны төп максат итеп куйган «Киек каз юлы» романы ике китаптан торырга тиеш була. Кызганыч, «Киек каз юлы» романының беренче өлеше — шагыйрьнең балачагын сурәтләгән китабы гына дөнья күрә алды, анысы да язучы үзе вафат булгач басылды. Аяз Гыйләҗев болай язган иде: «Газиз Кашаф-Үзиле гомеренең соңгы сулышына кадәр якташы Хәсән Туфанның гыйбрәтле язмышын роман битләрендә күрергә тырышып иҗат итте. Бу әсәр Хәсән Туфанга һәйкәл

буласы иде... Ул аның үзендә дә һәйкәл булыр дип кем уйлаган?» [2].

Г.Кашаповның менә дигән шагыйрь булганлыгын да онытырга ярамый. Кызганыч, авторның шигъри җыентыклары үзе исән чагында дөнья күрә алмаган. Ярый әле әдипнең дусты, язучы-публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Тәлгат Нәҗмиев бар. 2002 елда ул, Газиз Кашаповның тууына 60 ел тулу уңаеннан, бер шәлкем шигырьләрен туплап, «Мәхәббәт сүрәләре» исеме белән җыентык чыгаруга ирешт. Шушы китап Г.Кашаповны шагыйрь буларак ачты.

Газиз Кашапов шигъриятенең зур өлешен күңел лирикасы алып тора. Авторның лирик герое үз тормышындагы мизгелләре, хыяллары хакында сөйли, шәхси башлангычка өстенлек бирә. Геройның хис-кичереше, уйланулары еш кына табигать образлары, символлар аша белдерелә.

Мәхәббәт турында язмаган, мәхәббәт, ярату, сөю-сөелүне данламаган шагыйрь юктыр ул. Г.Кашапов та Ходай Тәгалә тарафыннан кешегә бүләк ителгән әлеге илаһи хис турында күп яза. Мәхәббәт темасына багышланган шигырьләренең кайберләре көйгә салынды, бигрәк тә «Бүген ярат мине» җыры популярлык казанды. Әлеге шигырендә Кашаповның лирик герое сөйгәненә бу дөньяда бер генә яшәвебезне искәртә һәм шуңа күрә сөйгәненә бүген яратырга кушып ялына. Шигырьнең һәр строфасының өченче юлында «Син яратсаң, бүген ярат мине» гыйбарәсе кабатлана. Әлеге алым шигырьнең тәэсирлелеген арттыра, андагы мәгънәви һәм хисси кыйммәтне көчәйтә, яңгыраш-аһәң гармониясен тудыра.

Кеше гомере бик кыска шул. Инде лирик герой да, аның сөйгәне дә яшьлек чорын үткән, чәчләргә көмеш төсе сибелгән, гөлләргә тәңкә карлар ява — көзләр җиткән, кайгылары да шактый күрелгән. Тик мәхәббәт — олысына-кечесенә карамый торган хис ул, яратырга беркайчан да соң түгел, шагыйрь тарафыннан шушы кыска гына гомердә дә яратылмыйча яшәп, үкенечкә калмасын иде дигән идея уздырыла:

Мәхәббәт ул —
мәңге сүнми торган,
Үлми торган тойгы кешедә.
Син яратсаң, бүген ярат мине,
Бүген төнлә кер син төшемә.

«Ачыш» шигырендә лирик герой үзенең мәхәббәтсез үткән гомерен гашыйклык хисендә янган чоры белән чагыштыра. Әйе, мәхәббәтсез дә тормыш бара, айлы төн айлы була, йолдызлар йолдыз булып ялтырый, күңел тыныч, көр. Башкалар мәхәббәт турында сөйләгәндә, мәхәббәт утларында янганда, лирик герой өчен болар барысы да сер булып кала бирә:

Син юк идең,
Сине белми идем,
Тыныч иде күңелем, көр иде.
Мәхәббәтнең утларында яну
Мин татыган олы сер инде.

Ләкин кешелек дөньясы шулай яратылган: мәхәббәтсез яшәү — яшәү түгел, ә бары тереклек итү, һәм, иртәме-соңмы, кеше барыбер бу хис утларында яна, аның серләренә төшенә. Лирик герой белән дә шундый ук хәл була: ул гашыйк. Аңа бөтен нәрсә үзгә булып күренә, бар дөнья яңа яктан ачыла. Лирик герой үзенең сөйгән яры өчен генә яши башлый:

Җаным бары сине көтә хәзер,
Синең өчен тибә йөрәгем.
Тик син генә минем Ышанычым,
Тик син генә минем Терәгем.

Һәм лирик герой шушы Ышанычы, шушы Терәге өчен генә яши. Ул бу олы хискә бик рәхмәтле, чөнки гашыйклык аны бу дөньяда «җитезләрдән-җитез» итә, алга барырга, яшәргә көч бирә. Лирик геройны мәхәббәтнең газаплы утларында яну да куркыта алмый.

Г.Кашапов шигъриятендә туган якка карата булган җылы мәхәббәт хисләре белән сугарылган иҗат җимешләре аерым урын алып тора. Әти-әнисен күрмичә, әбисе тәрбиясендә үскән кеше өчен туган як һәм мәхәббәт дигән төшенчәләрнең изгелек төсмере алуы гаҗәп тоелмый. Әле сөйгән яр да ташлап китәргә, хыянәт итәргә мөмкин, вакытлар узгач, яратмый башларга мөмкин. Ә туган як исә үзен шушы җир җимеше дип атаган кешене беркайчан да ялгыз калдырмый, ул һәрчак кешенең уй-фикерләре, яшәү рәвеше белән янәшә.

Газиз Кашапов шактый гына вакыт туган ягыннан аерылып яшәргә мәҗбүр була. Әлбәттә, андый язмышка дучар кешенең сагыш, сагыну хисләре кичерүе үтә тә табигый. Читтә йөри-йөри генә, вакытлар узгач, кешенең зиһене уяна: бары туган якның суы гына сусауны баса ала, бары туган як һавасы гына тынны кысмый, күкрәк тутырып суларга иркенлек бирә, бары туган як табигате генә кеше күңелендә кабатланмас соклану хисе уятырга сәләтле икән бит!

Газиз Кашаповның туган җиргә, туган якка булган мәхәббәтенең ачык бер чагылышы — «Үзием» шигыре. Биредә шигырьне шигырь иткән хис һәм аның элементларын бик ачык күрергә, шушы ноктадан килеп анализ ясарга мөмкин. Әлбәттә, беренче планга туган авылны ярату хисләре чыга. Сәбәбе дә ачык күренеп тора: лирик геройның авылдан чыгып китүе:

Мәрхәмәтсез чорга туры килдек,
Ташлап киттек сине, Үзием.
Җир тирәли ничә әйләнсәк тә,
Син барыбер безгә үз идең.

Яңа Үзи авылы Кашаповның соңгы еллардагы иң зур таянычы, ышанычы, киләчәккә өмете дә булып тора. Шагыйрьнең туган авылына кайтып йорт салырга, шунда төпләнергә теләгәнлеге мәгълүм. Әлеге шигырьне укыганда, янә бер тапкыр язмыш кая гына илтеп ташласа да, Яңа Үзинең Кашапов өчен һәрчак билгеле бер маяк булып торганлыгы аңлашыла: «Адымнарның зурын-кечкенәсен Синең исәп белән сиплибез».

Ә инде «Васыять» шигыре Газиз Кашаповны туган авылы белән мәңгелеккә бәйли. Әлеге шигырь һәрбер укучыны уйланырга мәҗбүр итәргә сәләтле. Гомер азагы якынлашкан вакытта, һәр кеше үткән тормышы турында ешрак уйлана башлый, үзенең бу дөньяда яшәвенең мәгънәсен эзли, хаталары өчен үкенә:

Каршылыклы булды минем яшәү,
Бер балкыды янып, бер сүнде.
Биек тауга басып көлде дә ул,
Урманнарга барып көрсенде.

Тик аңа хыялында яшәгән йолдызларга менеп җитү насыйп булмый, шуңа күрә шагыйрь күңеле үзенә урын тапмый, үткән тормышын кат-кат анализлап, кайсы вакытта ялгышканын

уйлый. Ачы үлемнең якасыннан тотып алганын яхшы сизенгән шагыйрь соңгы сүзен әйтеп калдырырга ашыга:

Мине белгәннәргә бер үтенеч,
Соңгы сүзем итеп белегез.
Җаным чыккач, мине Бикчабарның
Тау башына илтеп күмегез.

Янә биографик деталь, янә шагыйрь белән аның реаль яшәешен тоташтыра торган детальләр. Бикчабар дигәне Яңа Үзи авылындагы Югары як зиратын аңлата. Әдипнең васыяте үтәлә: Газиз Кашапов шушы зиратта күмелә.

Узган гомер турында уйлаганда, фәлсәфи мотивларның алгы планга чыгуы шулай ук табигый хәл. Газиз Кашапов «Язгы урман белән сөйләшү» шигырендә, беренче карашка, табигать күренешләре, урман турында яза кебек:

Ылыслардан көмеш тамчы тама
Умырзаяларның битенә.
Ялгыз болан улы чыгып баскан
Исе китеп алан читенә.

Урман буйлап атлый-атлый, лирик герой андагы җәнлекләр, кош-кортлар белән сөйләшеп бара. Чынлыкта моны лирик «мин»нең үз язмышы, тормышы буйлап атлап килүе, гомеренә билгеле бер нәтиҗә ясавы дип аңларга кирәктер. Шигырьнең башында һәм ахырында «Яңа гына яңгыр явып узды, Чистарынып калды тирә-юнь», дигән сүзләр кабатлана. Яңгыр, су әдәбиятта чистарыну дигәнне белдереп килә. Биредә автор күңел чисталыгы турында сүз алып бара. Яз көне табигать җанланган кебек, яңгыр яугач, шагыйрь күңеле дә җанланып, чистарынып кала. «Дөнья ярып атлап киләмен» дигән юллар да тормыш турында уйланып, үткәннәрне хәтердә барлап килүне тәгаенли. Ялгыз болан улы, сыерчык, кәккүк тә тормышның төрле мизгелләрендәге лирик геройның үзе буларак аңлашыла. Ялгыз болан улы — ятимлектә үткән бала-чагын, сыерчыкның «Сагыну» гимнын башкаруы — яшьлеген генә түгел, әтисен, әнисен сагыну, юксынуы буларак күз алдына килеп баса. Кәккүк — ул, әлбәттә, тормышның үтүенә ишарә.

Дөнья ямьле,
Шундый ямьле дөнья,
Әй яшисе килә, яшисе.
Мин сөйләшеп киләм урман белән
Тик нигә ул бер дә дәшми соң? —

дигән юлларда лирик геройның сорауларның күбесенә җавап таба алмавы турында сөйләнә кебек.

Газиз Кашапов бик күп иҗади хыялларын, туган төбәгенә, тормышка, сөйгәненә, халкына ихлас мәхәббәтен әйтеп бетерә алмыйча дөнья куйды. Бернәрсә ап-ачык: кылган гамәлләре, язып халыкка тапшырган әсәрләре, кешеләргә, җиргә-күккә мәхәббәте аша ул татар әдәбиятында лаеклы урын алырга хаклы.

Әдәбият:
1. Мәһдиев М. Газиз Кашапов әсәрләре турында // Кашапов Г. Вөҗдан хәтере: Повестьлар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. — Б.271-272.
2. Гыйләҗев А. Йөртә безне язмышлар... // Кашаф-Үзиле Г. Киек каз юлы (Туфан). — Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. — Б.350-352.
3. Галиуллин Т. Кызганыч... // Мәйдан. — 2002. — №8. — Б.204.

А.Эшкинин фотосы

МИРАС

НУР ӘХМӘДИЕВ

Саубуллашсак,
Ничә хушлашсак та,
Китеп булмый икән үткәннән.
Ә күзләргә тынгысызлык тулы
Иртәгәсе көннәр текәлгән.

Киләчәге өчен борчылудан,
Яну-көюләрдән кем азат?
Үткән өчен бер кат җавап бирсәк,
Иртәгәбез өчен — мең кабат.

Үлү белән Кеше онтыламы? —
Ял ителә еллар узгач та.
Дәвамчылар күңеленә керер
Ниләр кала бездән мираска?

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай,
«Уянгач беренче эшем»,
1913 ел, 14 март

КАДЕР КИЧ (1911), Коръән мотивларын чагылдырган шигырь. Композитор Мансур Мозаффаров истәлегенә караганда, ул Фатиха Аитованың кызлар мәктәбендә мөдир булып эшләүче әнисе — шагыйрә, мөгаллимә, журналист Маһруй Мозаффария (1873-1945) үтенече буенча языла. Көннәрнең берендә ул Тукайдан: «Менә кадер кич җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы синдә, Габдулла?» — дигән үтенечен белдерә. Берничә көннән соң ул «Бу кадер кич елда бер кич…» дип башланган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган ачык хат (открытка) китерә.

Җиде бәйттән гыйбарәт «Кадер кич» шигыре Коръәннең биш аятьтән торган 97 нче сүрәсенә нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгән. Шагыйрь үзе дә әсәрнең исеменнән соң «Сүрәи Кадердән» дип искәрткән. Голямәләр гоманынча, Кадер кич рамазан аеның соңгы атнасындагы 25, 27, 29 нчы кичләренә туры килергә мөмкин. Бу олуг кичәдә Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең нәбие һәм рәсүле итеп сайлана, Коръән сүрәләре һәм аятьләре индерелә башлый, тәкъва мөэмин-мөселманнар дөнья мәшәкатьләрен бер читкә куеп, мәчетләргә бикләнеп, Раббыбыздан бәндәләргә иминлек сорап, Аның барлыгына һәм берлегенә мәдех әйтеп, Коръәне-Кәрим укуга багышланган игътикяф кичәләре башлана. Мәсәлән, бездә Гаяз Исхакыйның әтисе Гыйлаҗетдин хәзрәт тә Мөхәммәд пәйгамбәр сөннәтенчә игътикяф кыла торган булган.

Утыз сүздән торган Коръән сүрәсенең эчтәлеге Тукайның «Кадер киче» шигырендә дә тулысы белән сакланган һәм шул ук вакытта заманга ярашлы байтак кына иҗтимагый, әхлакый фикерләр, әдәби-эстетик бизәкләр өстәлгән. Тукай да «Кадер киче»нең бөеклеген Коръәндәгечә сан белән белдерелгән гипербола ярдәмендә «Бу кадер кич елда бер кич / Барча кичләр изгесе» һәм «Тәңре каршында мең айдан изгерәк» дип, укучыга тәкъдим итә.

Голямалар исәпләвенчә, мең ай — 83 елга, я булмаса Мөхәммәд пәйгамбәрнең Җирдәге 23 еллык мөҗтәһидлек эшчәнлегенә, ягъни исляхчылык-реформаторлык миссиясенә туры килә.

Шагыйрь бу кичәнең ни өчен изге икәнлеге хакында язганда ислам фәлсәфәсендә киң таралыш алган нур теориясе турындагы карашларга таяна һәм үзенең җитди динн-әхлакый фикерләрен суфичылык тәгълиматында рухи кыйммәтләр тупламасын символлаштырган «күңел көзгесе» сурәте ярдәмендә үтемле итеп күз алдына китереп бастыра. Аныңча, бары тик бер мәртәбә, Кадер кичәсендә генә була торган «күк капусы шәүләсе» мөэмин-мөселманнарның җаннарындагы керле тапларны, гөнаһларны чистар-

та, яшен тизлегедәй ялтырап үткән мизгелдә аларның теләк-үтенечләрен, ялварулы өметләрен, күңел көзгесе» аша нурлар бәйләнеше рәвешендә чагылдырып, күкләргә илаһият хозурына кайтара, җир йөзендәге бәндәләрнең язмыш-тәкъдирләрен билгели. «Күңелләр көзгесе», «Күк капусы шәүләсе» янына килеп кушылган, нурлардан үрелгән Җәбраил фәрештә (шигырьдә ул үзенең икенче исеме белән — «Рух» дип атала) һәм меңләгән фәрештәләр төркеме, «тол, ятимнәр яшьләрен, барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын», рәнҗешләрен җыйнап, алардан «зур энҗеләр» ясаган, күкләрнең югары катларындагы тәхетне — гаршекөрсине бизәгән мәлаикләр образлары «Кадер кич» шигырендәге яктылык эстетикасына гүзәл гамьнәр өсти, күңелгә ятышлы дини йолаларын искә төшерә, җирдәге иҗтимагый-социаль гаделсезлекләр турында күкләр белән дә уртаклашып, «әл-Кадр» сүрәсенең дүртенче аятендәгечә, «барча мөэмингә, мөселманга сәлам!» әйтеп, җан тынычлыгы, иминлек, рухи яңарыш тели. Габдулла Тукайның «Кадер кич» шигыре — сәнгати нәфислекнең һәм дини лириканың классик үрнәге.

Шигырь аа бб вв рәвешендә рифмалашкан, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы 7 бәйттән тора; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кулъязмасы сакланмаган. Беренче мәртәбә «Вакыт» газетасының 1911 елгы 6 сентябрендә «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Балалар күңеле» (2 нче табгы, 1911), «Җан азыклары» (1912), «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре» (1914) исемле китапларына кертелгән.

Чыганак:
Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. — 1 том. — Б.197.
Әдәбият:
Салихҗан Х. «Кадер кич» һәм Тукай // Соц. Татарстан. — 1997. — 4 февр.; аныкы ук. Тукай вә ислам // Мәдәни җомга. — 2001. — 7 апр.; аныкы ук. Тукай иҗатында ислам аһәңнәре // Мәдәни җомга. — 2006. — 14 апр.; Абдуллина Д. Тукайның дини эчтәлекле шигырьләре // Ват. Татарстан. — 2001. — 22 июнь; Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. — 1997. — Б.47-53,129-135, 227-233.; Бареев Т. Поэта миссия от Бога // Молодежь Татарстана. — 1996. — 26 апр.

ВАСЫЯТЕМ (1909), мәрсия жанрында язылган шигырь. XIX гасыр азагында — XX гасыр башында искечә яшәү рәвешен яклаган кадимчеләр белән аурупалашырга өндәгән җәдидчеләр арасында тартышлар көчәя: иҗтимагый һәм рухи тормышта хөрлеккә, иҗтиһатка, тәрәккыяткә чакырган татар зыялыларына «тәкфир» мөһере сугу, ягъни алласызлыкта гаепләү киң таралыш ала. «Кяфер», «дәһри» дигән гайбәт сүзләре Тукай шәхесен дә читләтеп үтми. Даһиларның даһие булган гарәп шагыйре һәм философы әл-Мәгарри дә (973-1058) «тәкфир» тамгасыннан котыла алмаган. Мондый нахак сүз сөйләүче «әһле тәкфир» тарафдарларына, мөтәкәллимнәргә шагыйрь Алланың барлыгын, берлеген раслаган түбәндәге бәйт белән җавап бирә: *«Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем: / Күр, нә рәсма тулган иман берлә Корьән садремә!»* Шигырьдә Тукайның пәйгамбәрлек сыйфатлары да шактый ачык чагылган. Коръәндәге «Рум» («Римлеләр») сүрәсенең 30 нчы аятендә ислам дине — хак дин, Тәңреңә «йөзең белән борыл» дигән аятькә таянып язылган беренче бәйт — моңа ачык дәлил: *«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә; / Бирдең арканны моңарча, инде бир бит әмренә».* Дини тәгълимат буенча, Аллаһы Тәгалә халикъ иткән галәмдә, табигатьтә мәңгелек бер канун бар: анда һәрнәрсә кире үзенә әйләнеп кайта. Бу дөньяви философиядә дә шулай. Кешеләргә күкләрдән иңдерелгән

җаннар да, җир тормышында һәм тән читлегендә газап күреп аргач-талгач, сыкрану-сызланулар, сынаулар аша үткәч тә, кире Илаһияткә әйләнеп кайталар, «раҗигъ» булалар, «нәфсе мотмәинлек» — рухи тынычлык халәтен кичерәләр.

1913 елның 2 апрелендә 8 сәгать 15 минутта 27 яшьлек шагыйрьнең җаны тынычлана, «Кайт, и нәфсе мотмәиннәм...» икеюллыгы язылган ак ефәк тасма эленгән, чәчәкләргә күмелгән табуты 4 апрельдә Йунусовлар мәйданына китерелә, голямалар катнашында Зариф хәзрәт Әмирхани җеназа намазын укый һәм җәсәде меңнәрчә халык озатуында каберстанга илтелә. Күмү мәшәкатьләре тәмамлангач, «Тәбарәк» сүрәсе укылып, дога кылынгач, Касыйм хәзрәт Салихи, мәрхүмнең каберенә карап, «Васыятем» шигыренең беренче бәйтен укый. Шул рәвешчә, шагыйрь-пәйгамбәрнең *«Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтегез: / Бу ике юлны мине күмгәч, укырлар кабремә»,* дигән сүзләре Казанның Яңа Бистә зираты өстендә күкләрдә матәм реквиемен хәтерләтеп тирбәлә башлый.

Вафат булгач та тынычланып, җанның үз асылына — Раббысына кайту мотивын Тукай дөньяви эчтәлектәге сатира-юмор максатларында да файдалана. Реакция елларында бик күп матбугат басмалары ябыла, шул исәптән, Коръән сүрәләренә һәм аятьләренә тәфсир-аңлатмалар биреп барган «Әд-дин вәл әдәб» журналы да чыгудан туктый. Аңлатмалы сүзлек алымына мөрәҗәгать итеп, бу дини басманың «үлемен» шагыйрь җиңелчә генә көлү белән «Әддине вәл әдәб»: «Йа әйәтеһәл нәфсел мотмәинәте ирҗагый иля раббики» аятенең мәгънәләрен язды да, үзе дә Тәңресенә кайтты да китте», дип шәрехли. Муса Бигиев «Васыятем» шигыреннән дүрт юлны «Хөсәения» мәдрәсәсендә диннәр тарихы һәм Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте чиксезлегенә багышланган лекцияләрендә (1909), «Шура» журналындагы мәкаләләрендә (1909-1910), «Рәхмәте илаһия гомумияте хакында илаһия борханнары» китабында (1911) үз фикерләрен дәлилләү өчен мисал итеп китерә. Совет чорында, аеруча 1920-1930 елларда, Тукайның дини шигырьләре, шул исәптән, «Васыятем» тирәсендә кайнар бәхәсләр бара, социалистик җәмгыять төзүче пролетариат өчен аларның хаҗәте юк дип игълан ителә. Ислам мәдәнияте, Коръән фәлсәфәсе нигезендә халык шагыйре булып җитешкән Тукай мирасын дәһриләр һөҗүменнән саклап калуда Ф.Әмирхан, Җ.Вәлиди, Ф.Бурнаш, Г.Рәхимнәр зур тырышлык куялар.

Шигырь аа ба ва рәвешендә рифмалашкан, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы 3 бәйттән тора; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кулъязмасы сакланган (Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 9 ф., 1 тасв., 9 эш). Шигырь «Әльислах» газетасында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, 1909 елгы дәфтәр»нең икенче басмасына, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән, совет чорындагы биштомлыкның 2 нче томында (1985) урын алган.

Чыганак:

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. – 2 том. — Б.9.

Әдәбият:

Бигиев М. Избранные труды. В двух томах. Т. 1 — 2005. — С.90-91, 97; Салихҗан Х. А.Пушкин һәм Тукай иҗатында Коръән аһәңәре. — Казан: Иман, 2001. — Б.22; Абдуллина Д. Тукайның дини эчтәлекле шигырьләре // Ват. Татарстан. — 2001. — 22 июнь.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

25 АВГУСТ — ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ КӨНЕ

КАҺАРМАННАРГА МИРАС – МӘХӘББӘТ

РӘДИФ ГАТАШ,
Татарстанның халык шагыйре

Әйе, җәлилчеләр мирас иткән үлемсезлек, димәк, ил, яшәү тойгысы, халкың өчен «елмаеп үлү» батырлыгы еллар узган саен бөтен мәгънәсендә ачыла бара. Аларның шәһит киткәненә дә тиздән 70 ел тулачак, ә үзләре, гомерләре, кылган эшләре, калдырган бәһасез мираслары — иҗатлары, шигырьләре — һаман безгә якыная, ачыла гына бара. Чыннан да шулай бит: «Эш күрсәткән ирне ил онытмас, каберенә эзне суытмас…» Гомерләр белән яулап алынган хакыйкать үзе тудырган шигъри юллар! «Ил кырында чәчәк ат»кан үлемсез гөл — шигырьләр!

Илкүләм генә түгел, бөтендөнья мөнбәренә күтәрелгән бу бөек бер шигъри сүз, әлбәттә, буш урында тумаган. Нигезе, зәмине — халык күңелендә, тарихында, милли аң һәм хәтер әледән-әле уятып торган батырлык, ил — халык өчен яшәү — гомернең мең еллар буе расланган әдәп-әхлак, ирлек кодексында! Ул — «Идегәй»ләрдә, халык җырларында, әкият-дастаннарда, Идел-Йорт, Урал, Оренбурглар биргән кабатланмас

моңнарда! Ул — Җик мәргәннәр васыяте, мәңгелек яшәү авазы... Илнең төрле төбәкләреннән — борынгы Болгар, Казан, Кырым, Себер, Әстерхан ханлыкларыннан, милли хәтер булып, утлы сүз булып, әнә шул тарихи моң берләштергән дә инде халыкның иң асыл улларын. Укыгыз сез Мусаның иң беренче, үзенең нинди юл сайлавын әйтеп, хәтта үлемен дә күзаллап язган шигырьләрен яки кече яшьтән зур эшләргә, мәхәббәткә, илгә, халыкка хезмәткә ничек әзерләнүен тасвир иткән шигъри автобиографик повестен — «Булачак иптәшемә хатлар»ны... Саелмыш, Сакмарлардан көч, матурлык, мәхәббәт алып үскән егет үзенең миссиясен ничек төгәл аңлаган! Һәм тагын әһәмиятле бернәрсә: чын шагыйрьләргә хас булганча, мәхәббәтне олылау, хатын-кызга табыну, шигъриятне, яшәүне шушы илаһи хис белән бәйләү таланты да ярылып ята Җәлилдә. Һәм нинди табигый, самими бу бөеклеккә илткән юлда чын таяныч булган Олуг Мәхәббәт! Бу — Алишта да шулай, Гайнан Кормашта да, Әхмәт Симаев белән Рәхим Саттарда да. Илгә мәхәббәт, әнкәйләргә, гаиләләргә, туган телгә, халкыңның киләчәгенә ышаныч... Шул ышаныч белән барган алар гильотинага. 11 ил улының йөрәгендә, һичшиксез, үз халкының үлемсезлегенә ышаныч иң соңгы дога булып әверелгән: Коръәнгә кул куеп, дөнья белән саубуллашканда, бәхилләшкәндә дә соңгы сүзләре Туган телдә булган, әлбәттә. Бу — үзе үлемсез шигырь! Кая монда төрле мәзһәпләр, төрле чордагы дин аермалары, ваһабчылар, салафитлар атлы иблис оештырган провокацион агымнар? Юк, алар изге пәйгамбәрләр, әүлияларның күккә ашкан, халкына багышланган җан авазларында. Моңа дөнья шаһит, һәрхәлдә Европаның төрле милләт, дин белән дә бөек үлемгә барган татарларның батырлыгын, рухи көчен, иманын раслаган Патер Фрытко, Андре Тимерманс, Ланфреди Ени һәм башка бик күпләр... Рейхның махсус мәхкәмәсе каршында да үз сүзен өзеп әйтә алган татарларым! «Татарга башкача булмый!» дип кат-кат тәкрарлады бу хакта Сибгат Хәкимебез. Ул да рухта безнең җәлилчебез, аның дәвамы иде... Язмышын Җәлил белән, Моабит, Плецензеелар белән чагыштырып, соңгы сулышынача Җәлил исеменә таянган бөек Туфаныбыз да шундый иде. Бөек яугир Ф.Кәрим дә! Иң мөһиме шул: «Моабит дәфтәре» илгә, халыкка кайтарылганчы, ничектер, җай гына, уртача гына ачышта яшәп яткан әдәбиятыбыз нинди зур стимул алды 50 нче елларда! Шигъриятнең үсеш чорларын, зур исемнәребезне без, һичшиксез, Җәлил яулаган биеклек — аның ориентирына карап алга бару дип бәялибез. Һәм бу бүген дә дәвам итә. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең соңгы көннәре турында гына да нинди көчле сәхнә әсәрләре язылды бит. Т.Миңнуллин, И.Юзеев пьесаларын хәтерләгез. Ә күпме шигырь, поэма? Романнар? Һәм бу дәвам итә, әдәбиятта Җәлил премиясе булдырылган еллардан — бүгенгәчә... Бу юлда үзе зур бер әдәби батырлык юлын үткән Рафаэль Мостафинның Җәлилгә багышлаган илле еллык хезмәтен генә искә алу да җитәдер. Соңгы көненәчә Җәлил исемен керсез, пакь саклау өчен көрәшкән әдип ул. Пәйгамбәребезнең гомере буе изге эшенә, сүзенә шик белдергән Әбүҗәһил, Әбүләһаб кебек дошманнары булган бит... Һәм пәйгамбәребез соңгы сүзне аларга үзе әйтә дә: Әбүҗәһил аңа дип казыган тирән чокырга үзе килеп төшә; ә Әбүләһабның ике кулы да корый...

Сүз пәйгамбәребезнең саф раушандай исемендә, шәхесендә казынучы бүгенге затлар, әлеге Әбүләһаб токымы булмас дисезме әллә? Әмма бөек Сүз, шигъри сүз, гомерләр белән яулап алынган халык мәхәббәте — үлемсез ул. Шандор Петёфиның үлеме, шәхесе турында, төрле имеш-мимешләр таратып, бульвар матбугат активлашкач, XX гасыр башында аның бөек каләмдәше Эндрес Ади шул сүзләрне язып чыга: «Петефи үзе булып, бөек булып кала!» Мусабыз белән дә шулай булачак һәм аның көрәштәшләре белән дә. Шигърият барысын да җиңәчәк, туган телебез дигән алмаз да һичкайчан югалмаячак... Без әнә шул ышаныч белән яшибез. Һәм моннан 68 ел элек безнең өчен, халкыбыз, шигъриятебезнең үлемсезлеге өчен баш салган җәлилчеләр рухы алдында әлегә исән башларыбызны тагын бер кат иябез, аларга мәхәббәтебезне кабат-кабат тәкрарлыйбыз.

Бу хис — тарихыбыз кебек борынгы һәм һәркөнне яңарып торган, «изге кан һәм изге сөт» аша бездә бөекләребезгә карата яшәүче мәхәббәт хисе — инде мирас хис!

ҖӘЛИЛЧЕ РӘХИМ САТТАРНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

«ИЛГӘ ТУГРЫЛЫКЛЫ БУЛЫП КАЛАМ!..»

ШАҺИНУР МОСТАФИН,
язучы-публицист,
эзтабарларның «Хәтер яктысы»
берләшмәсе җитәкчесе

Чал Казан Кремле каршында каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәш дусларына – халкыбызның йөз аклыгын, намусын, фидакарьлеген һәм тугрылыгын гәүдәләндерүче асыл ир-егетләргә багышланган мемориал үзәктә тирән уйларга чумып басып торам. Август кояшы мәгърур Муса һәйкәленә һәм барельефтагы җәлилче батырларның сурәтләренә үзенең тылсымлы җылы нурларын мулдан сибә.

Август ае – җәлилчеләр, кормашчылар ае. Алар бакый дөньяга – үлемсезлеккә! – моңлы бер җыр булып күчкән изге ай. Хәтеремдә үткәннәрне яңартам…

…Үзебезнең Казан дәүләт университетын тәмамлагач, 1972-1973 елларда миңа Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә зенитчы-артиллерист һәм биредә чыга торган «Со-

ветская Армия» газетасында хәрби хәбәрче булып хезмәт итәргә туры киле. Шул чорда көндәлекләр дә алып барган идем. Җәлилчеләр белән очрашуга барыр алдыннан, шул язмаларны яңадан күздән кичердем. 1973 елның августында, мәсәлән, Берлин янәшәсендәге Вустрау дигән урынга килгәч, көндәлегемә, күңелемдә кайнаган хисләрне чагылдырып, менә мондый шигъри юлларны язып куйганмын:

Без – Җәлилләр каны
тамган җирдә...
Туфрак көлсу
монда... Йөргәндә,
Крематорийларда
янганнарның
Гәүдәсеннән
калган көлләргә
Басыла кебек...
Алар хәтерен саклап
Пышылдаша бары
кылганнар...
...Рухыгызны зурлап,
баш иябез –
Тыныч йоклагыз сез,
туганнар!..

Мәгълүм булганча, Вустраудагы хәрби әсирләр лагеренда әлеге язмабызның төп каһарманы Рәхим Саттар үзенең Казандагы якын дуслары Муса Җәлил, Абдулла Алиш белән очрашкан һәм тора-бара яшерен антифашистик оешманың иң актив әгъзаларының берсе булып киткән.

Әлеге легендар легионерның үткән тормыш юлы, иҗаты, яшерен оешмадагы эшчәнлеге һәм сүтелеп бетмәгән серле йомгакны хәтерләткән гомеренең соңгы мизгелләре бик күптәннән инде күңелемне кызыксындыра, төрле эзләнүләргә этәрә. Заманында Рәхим Саттар турында күренекле язучыларыбыздан Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Самат Шакир, Нәби Дәүли, Мәхмүт Хөсәен, Юныс Әминов, Галимҗан Латыйп, Барлас Камалов, Госман Садә, әтиле-уллы Хәйдәр, Айдар Басыйровлар һәм башкалар матбугат битләре аша халыкка үзләренең ялкынлы хак сүзләрен ирештерделәр, якты истәлекләре белән бик теләп уртаклаштылар. Соңгы елларда бу өлкәдә Рәхим Саттарның тугрылыклы улы, лаеклы дәвамчысы – фәлсәфә фәннәре кандидаты Ил Саттаров (1933-2001) һәм аның сөекле хәләл җефете – югары категорияле табибә Сания Исхакова аеруча нәтиҗәле эшләделәр.

Сулдан беренче – Рәхим Саттар. Хезмәттәш дуслары белән. Даурия. 1935 ел

Ире озак авырып ятканнан соң вафат булгач, Сания Гасыйм кызы үзенең хәләл акчасына, Рәхим Саттарга һәм аның иҗатына багышлап, аз тираж белән булса да, биш китап бастырып чыгарды. Менә аларның исемнәре: «Бүленгән җыр» (2004), «Завещание» (2004), «Безнең буын» (2006), «Рухым гали» (2007), «Тоткынлыкта» (2008). Хәзер исә без әлеге үтә тырыш, искиткеч тыйнак һәм гаҗәеп кешелекле ханым белән

Рәхим Саттарны бөтен тулылыгы белән яктырткан күләмле китап әшлибез. Безгә бу өлкәдә Казандагы 165 нче мәктәпнең мактаулы укытучысы Зәйнәп Исмәгыйлева һәм тугандаш Башкортстаннан танылган галим, популяр җырчы, халык артисты Марат Шәрипов та бик теләп булыша...

Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында Башкортстан Республикасының Чишмә районындагы Түбән Хаҗәт авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Балачактан ук әдәбиятка гашыйк малай дүртенче сыйныфта укыганда шигырьләр дә яза башлый. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, туып-үскән төбәгендә төрле эшләрдә эшли, шигырьләр язуын дәвам итә. Шул елларда Башкортстан һәм Татарстан көндәлек матбугатында аның яшьлек хисләре белән сугарылган беренче лирик парчалары да басылып чыга.

Урта мәктәпне Р.Саттар Уфа шәһәрендә тәмамлый. Татар теле һәм әдәбияты буенча биредә аларга дәресләрне булачак мәшһүр язучы һәм галим Нәкый Исәнбәт бирә. Аның белән якыннан аралашу Рәхим күңелендәге иҗат ялкынын тагын да көчлерәк итеп дөрләтеп җибәрә.

Тормышны бөтен нечкәлекләре белән белергә, дөнья белән ныклап танышырга тырышкан егет, язарына рухи азык табар өчен, Донбасс шахталарында, Казан заводларының берсендә һәм Башкортстанда урманчы булып эшләргә дә өлгерә.

1932 елда Р.Саттар гаилә корып җибәрә. Бераздан ул армия сафларына алынып, 1933-1937 елларда Ерак Көнчыгышта чик буе гаскәрләрендә хезмәт итеп кайта. Үзен оста мәргән (төз атучы), ат чабышларында, спорт ярышларында җиңүче итеп таныткан, хәрби һәм сәяси яктан яхшы хәзерлекле егетне кече командирлар әзерли торган курсларда укытып та чыгаралар. Срогы тулгач та, тагын бераз вакыт армиядә хезмәт итә әле Рәхим.

Шуннан соң Р.Саттар гаиләсе белән Казанга, әдәбият «казаны»нда кайнарга ашкынып кайта. Биредә «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасында эшли башлый. Шул чорда газет-журнал битләрендә дә байтак шигырьләре, очерклары, әдәби тәрҗемәләре басылып чыга.

Ак финнар белән сугыш башлангач, Р.Саттар үзе теләп фронтка китә. Чаңгычылар эскадронында отделение командиры булып хезмәт итә Рәхим.

1941 елның җәендә Бөек Ватан сугышы башлангач, Рәхим, дошманга каршы көрәшү өчен, тагын алгы сызыкка ашкына. Десантчы сыйфатында ул фашистлар тылында үткәрелгән күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша. 1942 елның 27 июнендә Вязьма тирәсендә булган шундый операцияләрнең берсендә, чолганышта калып, илбасарлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге хәрби әсирләр лагеренда газап чиккәннән соң, 1942 елның 16 сентябрендә Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла. Шунда ул Муса Җәлил һәм аның көрәштәш дуслары белән очраша. Р.Саттар әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында антифашистик хәрәкәттә бик актив катнаша. 1943 елның июнь аенда ул, яшерен оешма кушуы буенча, совет командованиесе белән элемтәгә керү өчен, берничә иптәше белән лагерьдан кача. Әмма бу төркем фронт сызыгы аша үтә алмый – фашистларның засадасына юлыга... Р.Саттарның һәм аның иптәшләренең язмышы хәзергә кадәр төгәл билгеле түгел. Эзләнүләр дәвам итә...

Р.Саттар 1942-1943 елларда Смоленск, Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагеренда

чагында да шигырьләр яза. Ватанны, туган җирне сагыну, фашистларга нәфрәт хисләре белән сугарылган шундый шигырьләрнең егерме дүрте («Ант», «Шөһрәт», «Әнкәмә хат», «Әсирләр», «Халкым өчен», «Бүленгән җыр», «Очрашу» һ.б.) «Тоткынлыкта» исемле кулъязма җыентык рәвешендә Туган илгә дә кайтып ирешә һәм берничә тапкыр матбугатта басылып чыга. Әдипнең зур булмаган шигъри мирасыннан үрнәкләр «Җыр дәвам итә» (1966, 1985) исемле җыентыгында, шулай ук рус теленә тәрҗемәдә «Три поэта-воина» (1979) һәм «Каһарман каләме» (2010) исемле китапларда да нәшер ителә.

...Үзенең улы Ил Саттаровка язган хатында Рәхим Саттар: «Илгә тугрылыклы булып калам!.. Син дә шулай ук тугрылыклы бул! Юл бер генә», – дип яза. Әнә шундый көчле рухлы, тоткан кыйбласына тугрылыклы чын ватанпәрвәр шәхесне – уникенче җәлилчене! – онытырга безнең һич тә хакыбыз юк!

Каһарман әдипнең тууына 100 ел тулган көннәрдә без укучыларыбыз игътибарына аның тоткынлыкта язган ике шигырен тәкъдим итәбез.

РӘХИМ САТТАР

ХАЛКЫМ ӨЧЕН

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң...
Күккә калкып таулар күренә —
Гүя калкан!

Алга карыйм. Анда ята
Томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.

Коралдашлар — яу кырында!
Кайда соң мин?
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!!!

Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.

Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем,
Синең өчен,
Туган илем,
Синең өчен!

АНТ

Мин читлеккә япмам сандугачны, —
Мин гомеремдә чебен үтермәм!
Мин яшьлекне зинданнарга ябып,
Һич беркемгә газап китермәм!

Мин бу антны ОСТ лагерен күреп,
Аның соры ташы өстендә
Бирәм киләчәккә, бирәм илгә,
Коллык сөйрәп йөргән бер көндә.

Ләкин дошман белсен минем көчне,
Дошман белсен минем ачуны.
Мөмкин түгел, дуслар, мөмкин түгел
Халык нәфрәтеннән качуы!

Дошман белсен минем күкрәгемдә
Нинди ачу, нәфрәт ятканын,
Мин сизәмен шушы нәфрәтемнең
Нәфис булып чәчәк атканын!

Мин читлеккә япмам сандугачны,
Яшәрмен мин чебен үтерми.
Тешем китмәс дошман бугазыннан,
Аның канын эчеп бетерми!..



ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Заманнарны кисәр көйгә
Ни җырламас ул моңлы баш?!

Рөстәм Мингалим

ДАСТАНИ МИРАСЫБЫЗ ЧИЧӘННӘР ИҖАТЫМЫ?

(Жанрга теоретик караш)

ЛИЛИЯ МӨХӘММӘТҖАНОВА,
Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

ҖЫРУЧЫ-ЧИЧӘН ШАГЫЙРЬ ХАЛЫК ДАСТАНЫ ДИГӘН РУХИ КЫЙММӘТНЕ ТЫҢЛАУЧЫГА ҖИТКЕРҮДӘ ТӨП ВАЗИФА БАШКАРА. ЭПОСНЫ ХАЛЫККА ТАРАТУЧЫ МОНДЫЙ КЕШЕЛӘРНЕ ТӨРЛЕЧӘ АТЫЙЛАР. ӘЙТИК, БОРЫНГЫ ГРЕКЛАР АЛАРНЫ АЭДЛАР ДИП, РУСЛАР СКАЗИТЕЛЬ, УКРАИННАР КОБЗАРЬ, МОНГОЛ ТЕЛЕНДӘ АРАЛАШУЧЫ БУРЯТЛАР УЛИГЕРШИН ЯИСӘ ГЕСЕРШИН, АЛТАЙДА ЯШӘҮЧЕ ТӨРКИ БУЛМАГАН ХАЛЫКЛАР ХАЙДЖИ, КӨНБАТЫШ ЕВРОПАДА ШПИЛЬМАН, КӨНБАТЫШ АФРИКАДА ГРИОТЛАР ДИП АТАП ЙӨРТКӘННӘР.

Төрки халыкларда да эпос-дастан фольклор әсәрен таратучылар олонхосут, шагыйрь, җомакчы, ашуг, бахшы, сәсән яки кобайырчы, акын, манасчы, кыйссахан, кайчы һ.б. исемнәр белән аталулары билгеле.

Эпос-дастанны халыкка җиткерүдә импровизация сәнгате ярдәмгә килә. Импровизация дип әсәрне тудыру процессын, ягъни сәхнәдә уйнау барышында алдан әзерләнмичә туган

сөйләмне әйтәбез. Ә күп халыкларда «эпос» сүзе халык алдында күләмле эпик текст башкаручы сүз остасы иҗаты буларак кабул ителә.

Эпосны телдән әйтү күчмә тормыш алып барган халыкларда ешрак очраган. Күләмле эпик текстны башкарган вакытта аерым бер йолаларны үтәүдән «эпос» үсеп чыккан дип карала. Алга таба күп вакыйгалар турында рәттән сөйләү фольклорда дастан (эпос) жанры булып ныгыган.

«Эпос-дастан» барлыкка килсен өчен, башкаручы чичәнне тыңлаучы, ягъни кабул итүче булу да зарур. Чичән-импровизатор иҗаты — ул сөйләм сәнгатенең бер төре. Чичән сөйләгән вакытта кем дә булса язып алган текстының бүгенге көнгә килеп җитүе — сөйләм сәнгатенең теркәлеп калган тарихи мирасы. Силлабикага нигезләнгән әлеге халык иҗаты тезмә, чәчмә һәм катнаш төрдә була. Чичән-импровизатор аваз яңгырашына бәйле сүзләрне махсус сайлап текст төзи. Сөйләм аһәңлеге килеп чыксын өчен, аваз охшашлыгына мөрәҗәгать итә. Әйтик, билгеле бер авазга башлана торган аллитерацион (alliteratio — лат., яңгыраш) шигырьгә мисал итеп кыргызларның «Манас»ын китерергә мөмкин. Шул дастаннан бер өзек китерик:

Баздышам тентушка соога ыргыткан,
Беежинге барса жол салган,
Баздышам беш жуз киши косшу алган.
Байбише калды сарайда,
Балдарын асар далайда.
Жоомокто сиздей кимде бар.
Саната Манас болбосо,
Сайганы сиздей кимде бар.

(Тәрҗемәсе:

Боеручым байлыгын суга ташлаган,
Бәженгә барырга юл салган,
Боеручым биш йөз кешене яралы иткән.
Байбичәсе калды сарайда,
Балаларын асрар далада.
Дастанда сездәй кем булыр
Данлыклы Манас булмаса,
Дошманын кырып җиргә салмаса...) [1]

1. Өзек түбәндәге чыганактан алынды: Ауэзов М. Собрание сочинений. В пяти томах. Т. 5. Литературно-критические и публицистические статьи 1936-1961 годов. Перевод с казахского. — М: «Художественная литература», 1975. С. 393-394. Татарча текст автор тәрҗемәсендә тәкъдим ителә.

Алтай, саха-якут халыклары эпосы да нәкъ шушы рәвештә төзелгән. Чичән сөйләм уңайлыгын, истә калдыру җаен, шигъри яңгырашның камиллеген игътибар үзәгенә ала, ул бер үк авазга башланган юлларны, бер-берсе белән җиңел ярашырдай сузык авазлардан торган сүзләрне тезә-тезә дә башка авазга күчә:

Былыргы дыылым
Быстар мындаатын
Быдан ынараа өттүгэр,
Урукку дылым
Охсуһуулаһ уоргатын
Отой аннараа өттүгэр,
Ааспыт дьылым
Анысханнаах айдааннаах күнүн
Адьас анараа таһаатыгар...

(Тәрҗемәсе:

Далада йөреп,
Тауларга менеп
Үткән гомерем еракта.
Чит-ят якларда
Яуларда үткәргән
Ялкынлы көннәрем артта.
Далада югалган,
Еракта калган,
Эзсез югалган көннәрем [2]...

2. Памятники фольклора народов Сибири и Дальнего Востока. Якутский героический эпос. «Могучий Эр Соготох». — Новосибирск: Наука. Сибирская издательская фирма РАН, 1996. С.76-77. (Әдәби тәрҗемә — авторныкы).

3. Өзек кыргызларның «Кедейкан» дастаныннан китерелде: Кедейкан. Эр табылды. Эпостар. — Фрунзе: «Кыргызстан» басмасы, 1970. — Б.40. (тәрҗемә — авторныкы).

Язмачылыкка күчкәнче, эпик текстны төзү — юлларда иҗекләр саны төрле булып та, сүзләр саны тигез булган сүз-буын (слово-стопа), сан-иҗек, такмаза шәкеленә нигезләнә. Шушындый традицион ысуллар аша халык дастанында халык фәлсәфәсе, чичән фикере җиткерелә:

Атсалому алейкум,
Амансызмы, жан бабам?
Арманын айтсын — мен балаң.
Мен — мусапыр, бир Кедай,
Мужун айтып зарлаган... [3]

Ягъни:

Әссәламегаләйкүм,
Иминмесез, җан атам?
Теләгәнен әйтсен — мин балаң.
Мин — мосафир, бер Кедай,
Зарын әйтеп елаган...

Башкорт, казах, үзбәк, азәрбайҗан, кыргыз, төрекмән, кырым татарлары, якут, алтай, себер татарлары, хакас, шор һ.б. төрки халыклар, бурят һ.б. кайбер төрки булмаган халыклар эпосы нигездә нәкъ шундый. Аларның атаклы чичәннәре эпос әйтүне берничә айларга сузган [4]. Чын җомакчы-импровизаторлар, халык иҗатына таянып, бер әйтелгәнне

бүтән кабатламыйча, айлар буе бер үк әсәрне башкарулары белән дан тотканнар [5].

Көньяк Себер һәм көньяк халыкларының күпчелегендә тормыш-көнкүреш шартларына бәйле үзгәреш кичергән дастанны элекке эзенә төшерергә омтылалар. Әлеге максатта үзбәк, каракалпак, башкорт h.б. халыклар чичәнлек мәктәпләрен ачып, эпос әйтү ярышларын даими уздыралар. Бу эш хөкүмәт дәрәҗәсендә алып барыла. Үзбәкстанда хәтта атаклы чичәннәргә «Үзбәкстанның халык бахшысы» дигән мактаулы исем бирү дә каралган [6]. Шулай ук себер татарларының казан татарлары белән аралашканга ислам йогынтысына кадәрге эпик мирасын борынгы форманы үзгәрешсез саклаган фольклор әсәрләре дип билгеләргә мөмкин.

Дастан жанрының силлабика, аллитерация, такмаза шәкеленә, сарынга — халык иҗатының төрле ысулларына, гомумиләштереп әйткәндә, традицион халык стиленә таянган текст буларак яшәве — халык хәтеренең тирән тамырларына мөрәҗәгать итүе кебек аңлашыла. Халык иҗатының ритуал-мифологик эчтәлекле, чагыштырмача саф борынгы жанры һәр халыкта булган һәм тиешле дәрәҗәдә сакланган дип әйтеп булмый. Шуңа күрә кыргызлар үзләренең «Манас»ын, каракалпак, казахлар «Идегәй» версияләрен, үзбәкләр «Алпамыш», казахлар, нугайлар «Кузы Көрпеш»не, якутлар «Олонхо»ларын, башкортлар «Түләк белән Һыуһылу»ларын h.б. төрле вариантта халыкка һәм фольклорчы галимнәргә тапшырган чичәннәре белән горурланалар [7].

Идел буе татарларына килсәк, импровизаторлык таланты белән аерылып торган кешеләр, әлбәттә, биредә дә булган һәм бар, андый кешеләрне бездә дә чичәннәр дип атаганнар.

Татар чичәне туй-мәҗлесләрдә көтелгән кунак булган, төрле вазгыятьтә оста сөйләве белән һәркемне җәлеп иткән. Кагыйдә буларак, ул — үзе яшәгән төбәкнең мөхтәрәм кешесе, күпьяклы талант иясе, һәм ул фольклор музыка уен коралларында да уйнавы белән аерылып торган. Н.Исәнбәт «чичән» сүзенең халыкта сүз остасы мәгънәсендә йөрүен әйтә. Үзебезнең татарны түгел, ә казахларны, башкортларны мисалга китереп, соңгыларда тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучы берничә халык шагыйренә «сәсән» исеме бирелүен искә ала һәм бу очракта «чичән» сүзенең «матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, тоткарлыксыз шигырь әйтүче-импровизатор мәгънәсен дә үз эченә» алуын күрсәтә. Татар халкының борынгы шагыйрь-чичәне образын исә ул түбәндәгечә сурәтли: «...аркасына думбрасын аскан хәлдә, авыл-шәһәрләр аша бик иркен гизә; кайда тагын шундый бер шагыйрь барын ишетсә, анда барып, мәҗлестә аның белән ярышка керә, кара-каршы хикмәт, шигырь әйтешеп җиңешә... Чичән ул туй-мәҗлесләр түренә генә түгел, ил эчендә барган дау-ызгышларны хәл итешүгә дә чакырып китерелә» [8].

4. Курманбек. Жаныш, Байыш (эпос). — Фрунзе: Кыргызстан, 1970. — С.5.

5. Жирмунский В.М. Некоторые итоги изучения героического эпоса народов Средней Азии // Вопросы изучения эпоса народов СССР. — М.: Изд-во АН СССР, 1958. — С.33.

6. Культура и искусство. URL: http://www.solvex.ru/article/?slug=kultura_i_iskusstvo (дата обращения: 11.11.2010.)

7. Бу турыда кара: Гацак В.М. Эпический певец и его текст // Текстологическое изучение эпоса. — М: Наука, 1971. — Б.7-8.

«Безнең чичән» алдарак карап үтелгән чичән образына тәңгәлме соң? Татар телендәге «чичән» төшенчәсен, башка халыклардагы кебек, телдән эпос әйтүче импровизатор-җыручы мәгънәсенә туры килә дип раслап буламы? Кайчандыр кем тарафыннандыр турыдан-туры чичән авызыннан язып алынган эпос-дастаннарын күрсәтә алабызмы?

Татар халкында Җирән чичән, Сыпра (Субра) җырау, Җамукай кебек гомумтөрки чичән образлары сакланган. Әмма Идел буе татарлары турыдан-туры дастан әйткән атаклы чичәннәре белән мактана алмый. Соңгы чорда Урта Идел татарларының талантлы чичәннәреннән Сабирҗан акын (Мәңгәр авылыннан), Байчыгави (Лаеш ягыннан), Кәшшәфетдин Шаһимәрдән Минзәләви (Минзәлә өязе Сөлек авылыннан), Хөсәен Нугай һ.б. халык җырлары, афоризмнар, әкиятләргә һәм хикмәткә бай чыгышларында дастаннар булмаган. Яисә Идел-Урал төбәге шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән Кайгы (XV гасыр), Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр ахыры — XVI гасыр башы), Чалгиз (Шалкиз) җырауны (XV гасыр ахыры — 1560 еллар) дастан җиткерүчеләр дип билгеләү шактый бәхәсле мәсьәлә, чөнки алар репертуарында да күләмле эпик әсәрләр күренми. Шулай итеп, татар чичәне дастан жанрына мөнәсәбәттә түгел, ә гомумән — зур мәгънәгә ия хикмәтле сүзне тәэсирле итеп әйтә белүче, халыкның үз арасыннан чыккан үзгә оста башкаручы булып күз алдына килә. Димәк, чичәнлек казан татарларында, иң беренче чиратта, дастан жанрында түгел, үзгә вазифада ачылган.

Идел буе татарларында тел остасы-чичәннәрнең дастан жанрыннан ерагаю сәбәпләренә килсәк, бу, иң беренче чиратта, биредә дастанның язма-китаби юнәлештә үсеш алган булуы белән аңлатыла. Фольклор тамырлы классик әдәбиятның борынгы һәм урта гасыр үрнәкләре халык иҗатына хас рәвешкә китереп эшкәртелгәннәр, нәтиҗәдә, алар язма формалы эпик мирас булып әверелгәннәр. Әйтик, мәгълүм сюжетлы «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннар Идел буе татарларында берничә төрдә таралганнар.

Идел буе татарларында дастаннарның язма әдәбиятка гына түгел, гомумән язмачылыкка, язма мәдәнияткә бәйлелеге, хәтта буйсынган булуы төрле факторлар аркасында гаять киң җәелеп, тора-бара халык дастаннары таралыш-яшәешендә киң колач алган. Китабилык Казан татарлары дастани мирасының иң зур күпчелегенә гомумән кагыла торган үзенчәлекле билгегә әверелгән. Мәсәлән, Чура батырга багышланган дастан, «Түләк китабы», «Бүз егет», һ.б. казан татарлары рухи тормышына, иң беренче чиратта, җыручы-чичән башкаруында түгел, ә язма әсәр булып кереп урнашканнар. Ә «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан нәселе

8. Татар халык мәкальләре. Җыючысы һәм төзүчесе Н.Исәнбәт. 3 томда. Т.1. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1959. — Б.67.

турындагы дастан» һ.б. авыз-тел иҗаты буларак таралганлыгы, гомумән, билгеле түгел, болар — фәкать язма китаби дастаннар.

Бераз соңгырак чорда исә бездә китаби дастаннарның өряңа тибы формалашкан. Бу — билгеле авторлар тарафыннан сөйләм характердагы эпик иҗатны эшкәртү нигезендә аңлы рәвештә махсус барлыкка китерелеп, алга таба яңа формалы халык мирасы булып әверелгән китаби дастаннар. Моның ачык мисалын без Х.Рәхмәтуллин, Н.Хәким (1919) эшкәрткән, шулай ук 1940 елда бер төркем галимнәр тарафыннан төзелеп, бүгенге көндә Н.Исәнбәт исеме белән халыкка кайтарылган атаклы «Идегәй» дастанында күрәбез.

Идел буе татарларына хас эпос жанрында борынгы чорлардан ук йоладан аерылганлык күзәтелә. Күләмле әсәрне халык алдында билгеле бер йолага бәйле рәвештә көйләп әйтү казан татарларында берничә гасыр элек үк инде бик сирәк күренеш булган. Тарихка мөрәҗәгать итсәк, Казанны яудан сакларга әзерләнгән вакытларда татарларның чичән-башкаручыдан эпос-дастан көйләтүләре документаль рәвештә беркайда да теркәлмәгән, бары П.Рычков мәгълүматларына караганда, әлеге чорда музыка уйнату гадәте генә гамәлдә булуы билгеле [9].

Бу уңайдан галим Ф.Урманчеевның түбәндәге фикере шактый әһәмиятле: «Билгеле булганча, татар халкы, бигрәк тә Урта Идел татарлары, элек-электән язма мәдәнияткә ия китаби халык булган. Идел буе татарларында, беренчедән, төрки дастаннарга тартым, зур күләмле тылсымлы һәм батырлык турындагы әкиятләре зур бер иҗади егәр белән үсеп китсәләр, икенчедән, китаби дастаннар киң урын ала» [10].

Татар дастаннарының тематика һәм формасын эчтәлекнең башлангыч чыганагы үти. Шулай ук Идел буе татарларында китаби дастан кайсы гына төренә карамасын, аның һәркайсының берничә күчермәсе бар. Ул язмаларны күчерүче-иҗатчылар да төрле кешеләр. Чичән-импровизатор вазифасы да мондый дастаннарда, нәкъ менә шушы күчереп таратучыларга йөкләнә. Әмма Казан татарлары дастанын башкаручы, кардәш халыкларның ашуг, бахшы, сәсән, манасчылары белән чагыштырганда, икенчел вазифа үти. Ул күбрәк — каләм иясе, иҗатчы-дастанчы, укымышлы кеше — мулла, мәдрәсә шәкерте яисә язма мәдәнияткә ия иҗат белән шөгыльләнүче шәхес. Бу — татар китаби дастаннарына хас иң зур үзенчәлек булып бәяләнә.

Әлбәттә, «тере» эпос белән чагыштырганда, китаби дастан текстының икенчеллеге үзен сиздерә. Әмма дастанны күчереп таратучы образы да үзенчә кызыклы бит. Күңеле белән ул — шундый ук чәчән-җыручы — сүз остасы, әмма башкаручы түгел. Ул тасвирлаган каһарманнар — күп вакыт җыр әйтешү осталары, ә күренешләр фольклор алымы белән сугарылган була. Күчерүче-иҗатчы үзе башкаручы белән сөйләүче, ягъни риваять кылучы арасында билгеле бер урынны алып тора.

9. Опыт Казанской истории с древнейших и средних времён, соч. Петром Рычковым. — СПб., 1767. — С.125.
10. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. 2 т. (Д — С). — Казан: Мәгариф, 2009. — Б.6-7.

Бер үк сюжетлы китаби дастанның берничә вариантта таралган булуы, эчтәлек һәм форма ягыннан аларның фольклор асылга туры килүе, эпик текст буларак камиллеге күп очракта нәкъ менә шушы күчерүче-иҗатчының иҗат мөмкинлекләренә, шулай ук аның белем һәм халык әсәрен тоя белү дәрәҗәсенә бәйле була.

Шулай итеп, Урта Идел татарларында эпик текстны тыңлаучылар алдында дәртләнеп әйтү-башкаруга игътибар бик нык кимегән, дастан жанрының барлык үзенчәлекләре шушы язма китап тукымасына сеңгән. Кайбер башка халыкларның яисә үзебезнең себер татарларының борынгырак чорга карый торган «тере» эпосы белән чагыштырганда, бездә дастаннарның башка юнәлештә үсүе Идел буе татарлары эпосының чичәне образына да сизелерлек үзгәрешләр керткән.

Безнең халык мондый шөгыль ияләрен ничек атау мәсьәләсенә әллә ни игътибар бирмәгән, шуңа да китаби дастаннарны күчереп яисә соңрак бастырып таратучы кешеләрне атау өчен махсус термин юк дәрәҗәсендә. Китаби дастаннарның кайберләре текстның «авторы» — күчерүчесе белән мәгълүм, кайбер күчермәләр исә бөтенләй авторсыз була.

Дастанчылар иҗаты Идел буе татарларында күп очракта коллектив рәвештә укыла-тыңлана торган булган. Мәсәлән, «Йосыф китабы», Түләк китабы», «Таһир белән Зөһрә» халыкта бик популяр булулары белән мәгълүм. Дастаннар еш кына аерым өлешләрне яисә эчтәлекне кыскача сөйләү формасында тел-авыз иҗатында очрый, әмма кагыйдә буларак, мондый күптөрле сөйләмнәр күпкә камилрәк язма рәвештә билгеле була яисә әсәр дастан жанры чикләрен ташлап әкиятләшә. Дастанны халыкка кычкырып укып бирүчеләр турында да безгә «дастанның шигырь өлешләрен көйләп әйтә», «эпик җыр өлешен яттан башкара», «дастанның шигъри өлешеннән берничә куплетны телдән әйтеп бирә» кебек бик кысан мәгълүматлар килеп ирешкән. Мондый фактлар төрки һәм төрки булмаган халыкларга хас музыкаль башкаруның китаби дастаннарга да бөтенләй үк ят булмавы турында сөйли. Бездә дә дастанның шигъри өлешен дутар, думбра белән көйләп әйтү гадәте булган [10].

Хәлбуки, бу традиция тулы бер эпик текстны халык алдында тереләй башкару белән чагыша алмый. Әйткәнебезчә, казан татарлары рухи тормышы өчен, телдән башкарылган эпоска караганда, китаби дастаннарга ихтыяҗ күпкә зуррак булган. Төрки һәм аерым очракларда төрки булмаган халыклар иҗаты аша безнең җирлеккә үтеп кергән дастаннар, китаби дастаннар булып таралган. Телдән башкарган эпос белән чагыштырганда, китаби дастаннарның язмышы куанычлырак та: алар, икенчел тексттан гыйбарәт булсалар да, күп сандагы кулъязмалар һәм басма китаплар булып, бүген дә яшиләр.

А.Эшкинин фотосы

КАЗАНЫМ

ФӘЙРҮЗӘ МӨСЛИМОВА

Иделем, Казаным —
Шатлыгым, газабым.
Дулкындай тирбәлер,
Йолдыздай янарым.

Яшьлегем сукмагы
Гомерем юлыдыр.
Моңнардан яралган
Кызымдыр, улымдыр.

Казаным, Иделем,
Тиңдәше юк илем.
Хыялны чын иткән
Җирләрем син минем.

Казаным, Иделем,
Синдәдер күңелем.
Өметле иртәгәм,
Кадерле бүгенем!

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Күп көтмә җай сүз әйтергә,
Җай табып, тиз әйт сүзеңне...

Рөстәм Мингалим

ИДЕЛ ЭЧЕ - ИМИН ЙОРТ *

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,
филология фәннәре кандидатлары

Дәүләт нигезе – хөрмәт ия шаһы.
Мәҗлиси

Хөкүмәт башында торучылар кәҗә тәкәсенә генә булса да гыйбадәт кылучы, динле булсыннар.
Ризаэтдин Фәхретдин

Яман булмаган сугыш юк.
Кәрим Тинчурин

Сугыш кешене, тереклекне генә түгел, хыялларны да үтерә.
Мөхәммәт Мәһдиев

Сугыш дигән нәрсә синең хисләреңне аяп тормый шул. Дусмы син, туганмы – аңа барыбер. Аерыйм дисә – каера да аера.
Габделхәй Сабитов

Кан кою өчен, акыл кирәкми.
Зәки Зәйнуллин

Ил булгач, түрәсе була, ә түрә янында бер булса да шымчы йөрер, диләр.
Мөсәгыйт Хәбибуллин

Кол булырга теләүчеләр барында, колбиләүчеләр һәрвакыт булачак.

* * *

Көрәш корбансыз гына булмый. Әмма ләкин гел корбаннардан гына торган көрәшнең мәгънәсе бар микән?

* * *

Акыллылар ахмак кубызына биегән илдә буза куба.
Туфан Миңнуллин

Сугыш – акылсыз кешеләрнең акылсыз эше.

* * *

Юләрләр хакимлек иткәндә,
Инсаннар әйләнә сарыкка.
Фәнис Яруллин

Казан сөйли, Мәскәү вакыты белән.
Рабит Батулла

Ил мантырга теләмәсә,
халкыннан дошман эзләр.
Равил Фәйзуллин

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

Керсә шагыйрь сәясәткә –
Әйбәт түгел, начар инде.
Сәясәттән качып булса,
Бөтен шагыйрь
Качар иде.

Рөстәм Мингалимов

Россия — гаҗәп ил, океан артында яшәп сагыныр өчен.

Марсель Галиев

Каешны ныграк будырткан дәүләт гәүдә зифалыгын түгел, ә билнең җиңелрәк бөгелергә тиешлеген күздә тота.

* * *

Үзенең халкын буыннан-буынга үчеккәндәй эзәрлекләп килгән хакимият йодрыгы белән күз яшьләрен сөртүче сабыйдан да шикләнә.

***

Салкын сугышлардан сәясәтчеләр җылына.

Зиннур Мансуров

Ил башы таякка таянса,
Иле дә таякка калыр.

* * *

Сугыш – уеннан чыккан уймак,
Шул уеннан юк туймак…

* * *

Сугыш – җан биреп дан алу,
Кан биреп казану.

Мөхәммәт Мирза

Сугыш – кешелеккә каршы иң зур җинаять.

Мөдәррис Вәлиев

Нинди кытлык заманда да халык
Хуҗаларга кытлык кичерми ул.

Газинур Морат

Рәсәйдә бер кешенең үлем кайгысын йөз мең кеше үтерүдән дә кайгылырак итеп күрсәтә беләләр.

* * *

Гомер буе хакимиятне мактап, мактау кәгазьләре, дәрәҗәләр алса да, кешечә яшәү өчен, фатирлы була алмады.

* * *

Дөнья көтәбез, ләкин көтүчеләре без түгел.

Нурулла Гариф

Милли сәясәт нигезендә һәрвакыт ялган яткан.

Рафаэль Хәкимов

Күрдек: тиран меңнәрчә җаннарны кыя да шул ук санда үзенә һәйкәл куйдыра.

* * *

Һәр хакимият җимерелмәс
ныгытмалар төзи
Һәм иң элек үз халкына каршы.

Шамил Анак

---

*Дәвамы.
(Башы журналның 2-4 саннарында.)

А.Эшкинин фотосы

ҮПКӘЛӘРМЕН КЕБЕК

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ

Хатамдырмы, юкмы,
һич сөйләмим көлеп:
миңа Татарстан —
Җир үзәге кебек...
Йөрим кайчак чыгып,
күп шәһәрләр күреп,
Казан — шәһәрләрнең
иң гүзәле кебек.
Сорасалар әгәр,
бирә алмам бүлеп:
Мәскәү — Татарстан
шәһәредер кебек.
Мин дөньяны сөйдем,
дөнья торсын белеп:
ул да Татарстанның
бер өлеше кебек!
Хаталанма, диеп
әйтсә кемдер көлеп —
шул кешегә мәңге
үпкәләрмен кебек.

ЯҢА КИТАПЛАР

ӘХМӘТҖАНОВ М.И.
ТАШБИЛГЕЛӘРГӘ ЯЗЫЛГАН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ. —
Казан, 2011. — 215 б. — Тиражы 300 данә.

Эпитафик язмалар урта гасыр җәмгыятендәге югары катлам вәкилләренең биографияләрен һәм анда хөкем сөргән иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, милли язма мирас традицияләрен, гасырлар дәвамында рухи мәдәният өлкәсендә барган үзгәрешләрне өйрәнүдә әһәмиятле тарихи чыганак булып тора. Соңгы елларда Татарстанда бу кыйммәтле мираска игътибар, беренче чиратта, авыллар һәм район тарихларын язу белән үрелеп барды. Кызганычка каршы, хәзергә кадәр эпитафик һәйкәлләрне барлау, саклану урыннарының картасын эшләү, тасвирламаларын һәм торышын теркәгән мәгълүмат базасын булдыру, рәсемнәрен һәм алардагы язуларның транскрипцион сурәтен бастыру буенча максатчан республика программасы юк. Бу өлкәдә эш аерым фидакарь галимнәр, төбәкне өйрәнүчеләр тарафыннан, кайбер фәнни оешмаларның җәйге чорда кыска вакытлы археографик экспедицияләре барышында

өлешчә тормышка ашырыла, яңа чыганаклар акрынлап фәнни әйләнешкә кертелә. Һәркем үзалдына эшли, тырыша.

Күренекле текстолог, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗановның соңгы кырык елда башкарган фәнни эзләнүләрендә бер нәтиҗә булып торган «Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре» исемле китабын укыгач, беренче туган уйлар шундый булды. Әйтергә кирәк, галим эпитафик текстларны тарих, тел тарихы, антропонимика, татар әдәбияты тарихы һәм мирасы буларак өйрәнә.

Бу хезмәт 1950 елларда Әхмәт Булатов, Һарун Йосыпов башлаган, 1970 елларда Фәрит Хәкимҗанов дәвам иткән, бүген Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев, Венер Усманов, Җәмил Мөхәммәтшин кебек фидакарь галимнәребез башкара торган фән юнәлеше үсешендә бер этап буларак кабул ителә.

Китапның «Кереш» сүзе эпитафия чыганаклары тарихын аңлау өчен зур әһәмияткә ия. Биредә автор ташбилгеләрдәге язуларның үзгәреше турында бәян итә. Аның традицияләре Төрки каһанлык чорыннан килә. Иң мәшһүр милли әлифбада, руникада һәм туган телдә язылган ташбилге язмасы булып 731, 734 еллардагы Күлтәгин баһадир һәм Билге каханның үз халыкларын кытайлар тарафыннан юк ителүдән коткарып калган «тарихлары» тора. Шуңа күрә Идел-Урал төбәгендә табылган ташбилге язуларын автор әлеге борынгы, Төрки каһанлык чорында руник язулар рәвешендә ташларга уелган текст үрнәкләре белән (Күлтәгин истәлеге — Кече язма) башлап җибәрә.

Автор фикеренчә, «төрки халыкларның бу эпитафик поэзиясе рухы соңрак татар кабиләләрендә балбаллар кую культурасында дәвам итә, алар да, үз чиратында, эпитафик һәйкәлләр бит, чөнки балбаллар җиңелгән дошманнарның рухын сындырып, аларның сыннары аркылы дошманнарны рухсыз итү символы булып торган» (Б.5). Ләкин кайбер халыклар төркиләшсәләр дә, аларда эпитафия традициясе кабул ителмәгән. Урта гасырларда казахларда, башкортларда, якутларда, уйгырларда, төркмәннәрдә балбал, ташбилге формалы һәйкәлләр кую традицияләре булмаган, дип билгеләп үтә М.И.Әхмәтҗанов (Б.6).

Ислам динен кабул итү бу традицияләрнең өзелүенә китермәгән. Инде XII гасырда Караханилар дәүләтендә кабер өсләренә гарәп әлифбасында язылган ташбилгеләр кую гадәте булган. Аларның бу традициясе Алтын Урдада яңадан кабынып киткән. Идел буеннан тыш, урта гасыр ташбилгеләре Дагыстанда, Кырымда, Кыргызстанда, Үзбәкстанда да очрый.

Автор Идел буенда табылган урта гасыр ташбилгеләрендәге форма үзгәрешләрен билгеләп үтә. Әйтик, Алтын Урда чорында

(XIII-XV гасырлар), күпчелек очракта алар вертикаль басып торган төзек дүртпочмак рәвешендә эшләнеп, тимпан урынына борынгы мәчет гөмбәзләре контурлары күпертеп калдырылып, гөмбәз эчендә кояш яки ромашка таҗы сыман сурәтләр эшләнсә, Казан ханлыгы чорында ташбилгеләрнең очлары гөмбәз яки сугышчы шлемы рәвешендә ясалган.

Китап азагында урнаштырылган «Сүзлекчә» ташбилгеләрдә кулланылган аерым сүзләрнең татарча мәгънәләрен аңларга ярдәм итә.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән ташбилге текстлары — йөзләгән зиратларда, меңләгән каберлекләрдә булып, бөртекләп җыйган материаллар. Китапта бирелгән 725 эпитафик язу үрнәкләренең туплану төбәкләре гаҗәп дәрәҗәдә киң: Санкт-Петербургтан алып Сәмәркандкача, хәзерге Татарстан, Мари Эл, Чувашстан, Башкортстан республикалары, Оренбург, Сембер, Курган, Екатеринбург, Рязань, Нижгар, Чиләбе өлкәләре. Алар арасында иң борынгы язма Татарстанның Биектау районы Урмат авылы янында табылган 1281 елгы ташбилгедә булса, иң «яшьләре» — 2010-2011 елларда куелган кабер ташлары язулары.

Хезмәттә Алтын Урда дәүләтенең Болгар олысында булган 11, Казан ханлыгы чоры — 12, Касыйм йорты вакытына караган 11 кабер ташы язуы, XVII-XVIII гасырларда куелган һәм хәзерге Чувашстан (6), Татарстан (62), элекке Уфа өязе (20), Оренбург ягы авыллары зиратларында сакланган (12) ташбилге текстлары бирелгән. Сан ягыннан караганда, күпчелек эпитафик язу үрнәкләре XX гасыр — XXI йөзнең беренче унъеллыгына карый. Кайбер кабер ташларына уелган юлларда Өмми Камал, Һибәтулла Салихов, Габдулла Тукай, Зариф Бәшири, Муса Җәлил, Сәхаб Урайский, Роберт Миңнуллин шигырьләреннән өзекләр укылуын әйтеп китү мөһим. Мәрхүм шагыйрьләребезнең кабер ташларына аларның популяр шигырьләреннән юллар язылган.

Бик зур вакыт аралыгын колачлаган (XIII-XXI гасыр башы) ташбилге язуларын укып танышкач туган кайбер күзәтүләрем белән уртаклашасым килә. Язылу ысулы буенча караганда, Идел-Урал төбәгендәге текстлар гарәп имласы һәм кириллицада язылганнар. 1927-1939 елларда ТАССРда кулланылышта булган латин язуының кабер ташларында ни дәрәҗәдә чагылышын әле махсус өйрәнәсе бар.

Мәрхүмнәрнең ташбилгеләргә уелган исемнәре исем кушу өлкәсендәге мәҗүси, ислам һәм атеистик җәмгыять традицияләренең берсен-берсе алыштырып килгәнлекләрен раслый.

Барлык кабер ташлары язуларында уртак күренеш — мәрхүмнең аты, атасының исеме, үлгән вакыты турында

мәгълүмат бирү, моңардан тыш урта гасырларда һәм патша заманында еш кына зиратка, кабергә килүчедән үлгән кеше үзе истәлегенә дога өмет итүен искәртә. Совет чоры язуларында исә олы кайгы — туганын, баласын, ата-анасын югалту кайгысы бер-ике сүз яки шигырь юллары белән әйтелгән.

Эчтәлекләре буенча ташбилге язулары китапның исеменнән киңрәк: аларның күбесен эпитафия өлкәсендә халык иҗаты үрнәкләре дип атап булыр иде. Шулай ук китаптагы урыслаша башлаган яки урыслашкан татарларның кайгылы русча ташбилге текстлары мөселман зиратларында соңгы утыз-кырык елда барлыкка килгән яңа күренеш буларак кабул ителә.

Хезмәттә урын алган эпитафик язу үрнәкләре тарихчылар, этнографлар, телчеләр, әдәбият галимнәре, социологлар өчен искиткеч бай тарихи чыганак булып тора. Әлеге язмалар бүген татар ташбилге язуы традицияләрен яңартуда мөһим, дигән фикердә торабыз.

ВКЛАД БАШКИРИИ В ПОБЕДУ РОССИИ В ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1812 ГОДА. **Сборник документов и материалов / сост. Р.Н.Рахимов [и др.]. — Уфа: Китап, 2012. — 488 с. — Тираж 2000 экз.**

Башкортстан Республикасының Архив эшләре буенча идарәсе, Башкортстан Республикасы Үзәк тарих архивы һәм Башкорт дәүләт университеты хезмәткәрләре һәм галимнәре Урал төбәгендә яшәгән халыкларның Россиянең 1812 елгы Ватан сугышында җиңүенә керткән өлеше турында до-

кументлар һәм материаллар җыентыгын әзерләп бастырдылар. Җыентыкта Башкортстан Республикасы Үзәк тарих архивы, Башкортстан Республикасы Иҗтимагый оешмалар архивы (Уфа), Россия дәүләт борынгы актлар архивы, Россия дәүләт хәрби-тарихи архивы (Мәскәү), Россия дәүләт тарих архивы (Санкт-Петербург) фондларыннан җыелган 300 чамасы документ, шулай ук төрле кануннардан, шул заман кешеләренең язмаларыннан өзекләр, истәлекләр урын алган.

«Башкортлар 1812 елгы Ватан сугышында» исемле I бүлектә төрле басмалардан аерым башкорт гаскәриләренең хәрби осталыклары турында язмалар, архив документлары нигезендә сугыш алды һәм сугыш башы вакыйгалары, башкорт полклары оешу һәм аларның сугыш хәрәкәтләрендә катнашулары турында 65 документ бирелгән.

II бүлек «Башкортларның 1813-1814 еллардагы Чит ил походларында катнашуы» дип атала. Биредә губерна администрациясе эш кәгазьләре, армия штабларына җибәрелгән рапортлар һ.б. язмалар (һәммәсе 104 чынагак) аша башкорт полкларының Рус армиясе составында күрсәткән батырлыклары, хәрби бүләкләре, шулай ук рус һәм чит ил кешеләренең башкорт полклары һәм җайдаклары турында фикерләре яктыртыла.

«Мишәрләр һәм типтәрләр 1812-1814 еллардагы Наполеон сугышларында» исемле III бүлектә 1 нче һәм 2 нче Типтәр полклары казакларының хәрби җитәкчеләр тарафыннан куелган сугышчан бурычларны үтәгәндәге батырлыклары, шулай ук 1 нче Мещеряк полкына кагылышлы хәбәрләр китерелә (21 документ).

Китапның IV бүлегендә Оренбург губернасы күпмилләтле крестьяннарыннан һәм мещаннарыннан оештырылган Уфа пехота полкының сугыш юлы яктыртыла. Биредә, шулай ук армиядә хезмәт иткән, яраланган һәм 1817 елны «1812 елгы истәлек» медаленә тәкъдим ителгән Оренбург, Стәрлетамак, Троицк, Чиләбе, Верхнеуральск, Бөгелмә, Богырыслан, Бөре, Минзәлә, Бозаулык өязләре крестьяннары, шул исәптән татарлар исемлеге дә бирелгән.

Наполеонга каршы сугышларда катнашкан Оренбург губернасы чиновникларының (күпчелеге дворяннар) 104 формуляр исемлекләрендә (алар 1830-1840 елларда төзелгән) һәм башка документларда (V бүлек) бу кешеләрнең нинди гаскәрдә, нинди чиннарда хезмәт итүләре, сугыш кырында күрсәткән батырлыклары, яраланулары, бирелгән хөкүмәт бүләкләре язылган. Күпчелеге рус милләтеннән булган чиновниклар арасында ике мөселман — III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнгән отставкадагы поручик, 5 нче башкорт полкы командиры Ибраһим Бекчурин һәм сугышта яраланган, армия хезмәтен 1790 елны солдат булып башлаган, 1813 елда Дрезден

астындагы дошман белән бәрелешләрнең берсендә аягы, кулы яраланган, хәрби хезмәттән штабс-капитан чинында отставкага чыккан татар Алюк Батыршин да бар.

VI бүлектә укучылар игътибарына тәкъдим ителгән документлар Оренбург губернасы авылларында һәм шәһәрләрендә яшәгән төрле катлам вәкилләренең ул гарасатлы елларда иганәчелек актларын — хөкүмәткә, армиягә акчалата һәм кием-салым белән ярдәм итүләрен тасвирлый.

VII бүлектә бирелгән документлар, алдагыларының дәвамы булып, Оренбург төбәгенә китерелгән хәрби әсирләрнең тормышын яктырта.

Соңгы VIII бүлек 1812, 1814 елларда Уфа төбәгендә рус армиясенең хәрби җиңүләрен бәйрәм итү, Ватан сугышының 100, 150 еллык юбилейларын тантаналы итеп уздыруга бәйле материаллар белән таныштыра. Биредә Россия Федерациясе һәм Башкортстан президентларының Россиянең 1812 елгы Ватан сугышында җиңүенең 200 еллыгын бәйрәм итү турындагы һәм Башкортстан хөкүмәтенең шушы уңайдан кабул иткән Карары да урын алган. Бу рәсми документлар гасырлардан килгән дәвамчылыкны ачык күрсәтеп тора.

Тарихи чыганакларда искә алынган аерым шәхесләр, вакыйгалар һ.б. турында өстәмә мәгълүматны «Комментарийлар» бүлегеннән алырга мөмкин. Ә китап кушымтасында 1814 елның 25 апрелендә төзелгән «1812 елгы Ватан сугышы истәлеге» медаленә лаеклы дип табылган, 1812 елда хәрби хезмәттә булган Уфа пехота полкының штаб-, обер-офицерлары һәм түбән чиннарының исемлеге урнаштырылган.

«Исемнәр күрсәткече» укучыга үзен кызыксындырган шәхес турындагы мәгълүматны документлардан тиз арада табарга ярдәм итә.

Бер сүз белән әйткәндә, бу документлар һәм материаллар җыентыгы Урал төбәге халыкларының, беренче нәүбәттә, башкорт һәм татарларның, күпмилләтле Россия дәүләте вәкилләре буларак, 1812-1814 еллардагы шанлы җиңүләргә керткән өлешләрен, күрсәткән хәрби батырлыкларын һәм сугыш елларындагы гражданлык актларын төрле тарихи чыганаклар аша яктырта. Китапта бирелгән документларның төп өлеше беренче тапкыр бастырыла.

Илдус Заһидуллин,
тарих фәннәре докторы

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

ИСКЕ КАЗАН ТҮГӘРӘК УЕНЫ

7-9 июль көннәрендә Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивале кысаларында Коркачык авылындагы Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубы мәйданында һәм Биектау районының Иске Казан дәүләт мәдәни-тарихи һәм табигый музей-тыюлыгында «Иске Казан түгәрәк уены» дип исемләнгән III Республика татар фольклор фестивале булды.

Мәгълүм булганча, түгәрәк уен — татар халкының барлык этник төркемчәләренә дә хас булган яшьләр уены. Аның тарихи нигезендә борынгы гореф-гадәтләр, милли йолалар ята. Фестивальнең максаты — татар халкының традицион мәдәниятен, фольклор традицияләрен борынгы формаларда саклап калу, шулар ярдәмендә сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләү, яшь талантларны һәм үзенчәлекле төркемнәрне барлау. «Иске Казан түгәрәк уены»нда Татарстанда яшәп иҗат итүче фольклор коллективлары җирле традицияләргә, милли гореф-гадәтләргә нигезләнгән аутентик формаларны күрсәтте. Фестивальгә Татарстанның төрле район-шәһәрләреннән фольклор коллективлары һәм аерым башкаручылар килгән иде. 350гә якын катнашучы Арча, Әтнә, Әгерҗе, Чүпрәле, Зәй, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе,

Саба, Чирмешән, Тукай, Сарман районнарыннан, Азнакай, Казан шәһәрләреннән килделәр. Фестиваль кысаларында «Курайда уйнауның үзенчәлекләре», «Традицион башкару үзенчәлекләре», «Милли бию», «Милли фольклорны сәхнәләштерү», «Музыкаль фольклор әсәрләрен җыйнау һәм аны татар фольклор ансамбльләре репертуарына кертү» дигән темаларга мастер-класслар, фәнни-методик һәм этнофильмнар карау, татар традицион музыка уен коралларын ясаучы осталарның презентацияләре оештырылды. Фестиваль үзешчән сәнгать коллективлары җитәкчеләренең һөнәри осталыкларын баетты, сәнгать өлкәсендә төрле тәҗрибә уртаклашулар булды. Ә яшь буын, үз чиратында, борынгы традицияләрне, гореф-гадәтләрне өйрәнде. Мәйданда җырлы-биюләр, уен-көлке, кич утыру мәҗлесләре, туй йолалары, борынгы уен кораллары моңнары, җырлары туктап тормады. Шулай ук Татарстанның төрле төбәкләрендә яшәүче халкыбызның милли киемнәре игътибарны җәлеп итте.

Әлеге мәдәни чара түбәндәге номенацияләр буенча барды һәм һәрберсенең җиңүчеләре мәгълүм булды:

1. «Иң яхшы фольклор-этнографик төркем» (җиңүчеләр: «Умырзая» фольклор ансамбле (Чирмешән районы), сәнгать җитәкчеләре Р.Г.Шакирова, Г.З.Локманова; «Сөмбелә» фольклор ансамбле (Чүпрәле районы), сәнгать җитәкчесе Ф.Г.Җаббарова; «Чулпы» фольклор ансамбле (Балык Бистәсе районы), сәнгать җитәкчесе Л.А.Кибякова).

2. «Иң яхшы фольклор-хореографик төркем» («Хәтфә» фольклор ансамбле (Тукай районы), сәнгать җитәкчесе Р.Ш.Гәрәева; «Җәүһәр» фольклор ансамбле (Яшел Үзән районы), сәнгать җитәкчесе Р.Н.Александрова).

3. «Иң яшы инструменталь коллектив һәм милли музыка уен коралларында башкаручы» (Р.Х.Хәсәнова (Кама Тамагы районы), сәнгать җитәкчесе Т.Г.Яруллина; «Көмеш телле гармун» ансамбле гармунчылары (Әгерҗе районы), сәнгать җитәкчесе М.А.Муллахмәтов; «Һәй, егетләр» ансамбле тальянчылары (Азнакай шәһәре), сәнгать җитәкчесе А.М.Махиянова).

4. «Иң яхшы вокаль коллектив»

(«Җанашым» фольклор ансамбле (Азнакай шәһәре), сәнгать җитәкчесе — Г.М.Әхмәтҗанова; «Сүнмәс йолдызлар» вокаль ансамбле (Әтнә районы), сәнгать җитәкчесе

Ф.Г.Шиһапов; «Бибинур» вокаль ансамбле (Лаеш районы), сәнгать җитәкчесе Р.С.Гайфуллина).

5. «Иң яхшы вокалист» (Наҗия Мусина (Казан), Венера Бариева (Арча районы), Тәлгать Җаббаров (Чүпрәле районы)).

6. «Бәет һәм мөнәҗәтләрне иң яхшы башкаручы» (Наҗия Талипова (Чирмешән районы); Миңгосман Мортазин (Чирмешән районы); «Сүнмәс йолдызлар» вокаль ансамбле солисты Дания Хәкимуллин (Әтнә районы), сәнгать җитәкчесе З.Р.Гыйниятуллин; Гаделҗан Газиев (Кама Тамагы районы), сәнгать җитәкчесе Г.Нәҗмиева.

7. «Иң яхшы балалар фольклоры коллективы» («Мирас» хореографик ансамбле (Казан шәһәре), сәнгать җитәкчесе А.И.Умерова, концертмейстры И.И.Сафин; «Каз канаты» фольклор төркеме (Саба районы), сәнгать җитәкчесе Ә.К.Шәйдуллин; «Сәйләннәр» фольклор ансамбле (Арча районы), сәнгать җитәкчесе Ф.Н.Хәнәфиева). Шулай ук махсус бүләкләр дә каралган иде.

КҮК КАПУСЫ АЧЫЛГАНДА

1 август көнне башкалабыз Казанның «Мир» кинотеатрында татар халкының бөек шагыйре Г.Тукайга багышланган «Күк капусы ачылганда» дип аталган тулы метражлы нәфис фильм тәкъдим ителде. Халык белән тулы залга күренекле татар зыялылары, галимнәр, әдәбият, сәнгать, театр белгечләре килгән иде. Бу киноны Үзбәкстан режиссёры, кинематографиягә саллы өлеш керткән шәхес — Фәрит Дәүләтшин төшергән. Ә сценарий авторы — танылган әдип, драматург Рабит Батулла. Фильмда төп рольләрне (артист Тукай) Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театры артисты, Татарстанның атказанган артисты Илфат Камалиев һәм Г.Камал исемендәге Татар ләүләт академия театры артисты Алмаз Сабирҗанов уйный. Зәйтүнә ролен Г.Кариев исемендәге Татар яшь тамашачылар театры артисты Гөлнара Мулланурова башкара. Сюжет буенча вакыйгалар XX йөз башында бара.

Фильмда төп тема Габдулла Тукайның тормыш юлы, аның шәхесе, иҗаты һәм мәхәббәте турында. Вакыйгалар агышы бүгенге һәм Тукайлар заманындагы Казан каласында бара. Иҗади кризис, рухи газаплар кичергән театр артисты Мират Борһановка, сәләтсезлеген сылтау итеп, сәхнәдә эт, куян рольләрен генә уйнарга тәкъдим итәләр. Егет мәхәббәт өлкәсендә дә уңышка ирешә алмый, яратканы Сәгъдия аннан китә. Әмма эштә һәм шәхси тормышында уңмаган Мират нечкә күңелле, ярдәмчел кеше була. Театрдан тиздән китәм дип йөргән артистка яңа режиссёр, нәкъ менә шул сыйфатларын күреп алып, куелачак спектакльдә Тукай ролен уйнарга тәкъдим итә. Башта ул Тукай образын тудыра алмый газаплана, хезмәттәшләре дә аның уйный алачагына ышанмыйлар. Әмма Мират Борһанов Тукайны шәхес һәм шагыйрь буларак өйрәнә башлый, китапханәләрдә казына, беркөнне Болгар номерларының өченче катында ут янганын һәм 40 нчы бүлмәдә шагыйрь Габдулла Тукай утырганын күреп ала. Шулай итеп, алар танышалар, дуслашалар. Мират Тукайга төшенә, аңа кушылып китә, аның белән бербөтен була, ул булып яши башлый. Алар 40 нчы бүлмәдә татар халкының ачы язмышы, милләт өстенә төшкән фаҗигаләр турында сөйләшәләр. Кинофильмда Казан күренешләре, шагыйрьнең Кабан күле буенда йөргәндә, Кырлай урманнарын сагынып искә алуы, Зәйтүнә белән

очрашулары игътибарны җәлеп итә. Шулай итеп, Мират, Тукай ролен уйнап, зур уңышка ирешә. Әмма яңадан Болгар номерларына килгәндә, артист 40 нчы бүлмәдә төзелеш материаллары, кирпеч калдыкларыннан башка берни дә тапмый, Тукайның рухы инде моннан киткән була.

Фильмны карарга килгән кунаклар режиссёр, артистлар һәм операторларның эшләренә югары бәя бирде, «әллә ни төер күрмәделәр». Белгечләр әйтүенчә, авторлар фильмның сюжет сызыкларын шактый мавыктыргыч, заманча алымнар белән тудырганнар. Тамашачы артистлар тудырган Тукайның камиллегенә сокланды. Гомумән, фильмны төшерүче иҗат төркеме Тукайны аңлый һәм аңлата алган.

Шунысын да әйтергә кирәк: киноның финанс чыгымнарын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы күтәргән, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов та ярдәм күрсәткән.

«Күк капусы ачылганда» фильмы Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең конкурстан тыш фильмнар номинациясенә кертелгән.

III БӨТЕНРОССИЯ ДЕРЖАВИН ФЕСТИВАЛЕ

13-15 июль көннәрендә бөек рус шагыйре, күренекле дәүләт эшлеклесе Г.Р.Державин туган көненә багышланган III Бөтенроссия Державин фестивале булды. Державин фестивале Казан Федераль университетында «Державин һәм мәдәниятләр диалектикасы» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция белән башланып китте. Конференциягә 80гә якын галим-голәмә һәм шагыйрь иҗатын сөючеләр җыелган иде. Кунаклар арасында Франциядән килгән

Державин токымының һәм дворян Панаевларның ерак туганнары Элен һәм Надин Бестужевлар да бар иде.

Фәнни форумда катнашучылар өчен шәһәребез буйлап экскурсия оештырылды. Алар А.Пушкин, Г.Тукай, Л.Гумилёв, М.Җәлил һәйкәлләренә чәчәк бәйләмнәре куйдылар, ТР Милли музеенда «Әй, арфа! Син яңгыра!» дигән әдәби-музыкаль, сәхнәләштерелгән тамаша карадылар. Ә Державин фестиваленең тантаналы ачылуы Гавриил Романович Державин һәйкәле янында булды. Бәйгене ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм РТ Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачып җибәрде. Фестивальгә килүче кунаклар каршында Олег Хлебников, Станислав Куняев, Ренат Харис, Наталья Гранцева, Лилия Газизовалар чыгыш ясады. Алар барысы да шагыйрьне тирән ихтирам белән искә алдылар.

Шигърият бәйрәме Лаеш шәһәренең үзәк мәйданында дәвам итте. Бәйрәм кысаларында Г.Р.Державин

Тверь каласыннан профессор М.В.Строганов чыгыш ясый.
Л.Газизова фотосы

әдәби премиясе иярәре, Татарстан һәм Россиянең танылган шагыйрьләре, әдәбият белгечләре, яшь каләм әһелләре катнашында шигъри бәйге булды. Шулай ук кунаклар сәхнәләштерелгән тамаша һәм эстрада артистларының чыгышларын карап хозурландылар. Күңелгә аеруча Рус Никольское авылыннан «Каравон» ансамбле чыгышы хуш килде. Ә бәйрәмнең иң гүзәл мизгеле булып, шагыйрьнең бюсты янында, Г.Р.Державин исемендәге Бөтенроссия әдәби примеясе лауреатларын тәкъдим итү булды. Бу премиягә быел Казан каласында яшәп иҗат итүче прозаик Айрат Сәхибзадинов һәм Мәскәү каласыннан «Наш современник» журналының баш редакторы, шагыйрь Станислав Куняев лаек булды. Шулай ук монда балалар әдәбияты конкурсында җиңүчеләргә бүләкләр өләшү тирән мәгънәгә ия булды.

Өченче көнне фестиваль Казанда В.Аксёновның музей-йортында дәвам итте. Анда Мәскәү шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь Олег Хлебников, «Нева» журналының баш мөхәррире Наталья Гранцева, «Независимая газета»ның китап кушымтасы мөхәррире Андрей Щербак-Жуков белән очрашу булды. «Коровин һәм Фагот» Андрей Коровин һәм Александр Александров дуэты элек «Комсомольская правда» газетасында корреспондент булып эшләүче шагыйрь Сергей Белозёров (1948-2002) иҗаты белән таныштырды, Г.Державин, Н.Гумилёв, А.Коровин, В.Прокошин иҗатлары буенча поэзоконцерт куйды.

Державин фестиваленең традицияләре калыплашып килә. Ул төрле милләт иҗат әһелләренең, әдәбият галимнәренең очрашу, аралашу, фикер алышу урыны, күренекле иҗат осталарын хөрмәтләү, үткән әдәби традицияләребезне, яшь талантларны барлау, пропагандалау һәм яңа буын иҗат әһелләрен мәйданга чыгару юлында мөһим мәдәни һәм иҗтимагый чарага әйләнә бара.

Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

ЯШӘҮ ХОЗУРЛЫГЫ ХӨРЛЕКТӘ,
ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ИРЛЕКТӘ.
ЛИШЬ В СВОБОДЕ ЖИЗНИ КРАСОТА!
ЛИШЬ В ОТВАЖНОМ СЕРДЦЕ ВЕЧНОСТЬ ЕСТЬ!

Индекс 54132